**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 16 сентябрендәге 3906 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендәге 3854 номерлы «Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүнең оклад системасын кертү чаралары планын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарын үтәү йөзеннән **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендәге 3854 номерлы «Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 мартындагы 869 номерлы, 2019 елның 29 октябрендәге 3921 номерлы, 2022 елның 28 февралендәге 563 номерлы, 2022 елның 6 апрелендәге 962 номерлы, 2023 елның 18 гыйнварындагы 110 номерлы, 2024 елның 9 февралендәге 453 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1-4 номерлы кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга;

1.2. әлеге карарга 1-4 номерлы кушымталарны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендәге 3854 номерлы карарына 1-4 номерлы кушымталар дип санарга.

2. Әлеге карар белән раслана торган нигезләмәләр Казан шәһәренең муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләре өчен 2024 елның 1 июленнән гамәлгә кертелә дип билгеләргә.

3. Казан шәһәренең муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең әлеге карар нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы, хезмәткәрләрнең вазыйфаи

бурычлары күләмен саклап калу һәм шул ук квалификациядәге эшләрне башкару шарты белән, хезмәт өчен түләүнең яңа шартларына күчү вакытына гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан кимрәк була алмый дип билгеләргә.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 13 октяббрендәге 5871 номерлы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 22 августындагы 3425 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) 1, 8, 9 һәм 10 номерлы кушымталарны көчләрен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru) һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнары рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Бу карар үтәлешен тикшерүдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 16 сентябрендәге
3906 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәткә түләү системасы – оешмалар хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне кертеп, тариф ставкалары, окладлар (вазыйфаи окладлар) күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

- төп оклад – башкарылган эшләрнең катлаулылыгына бәйле рәвештә, кызыксындыру, компенсация һәм социаль характердагы түләүләрне исәпкә алмыйча, гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәренең календарь ай өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен яисә хезмәт нормасы (хезмәт хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш сәгатьләре нормасы) өчен билгеләнгән оклады;

- вазыйфаи оклад – билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен календарь ай өчен фактта эшләнгән вакытка хезмәткәргә хезмәт өчен түләүнең компенсация, кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча билгеләнгән күләме;

- хезмәткәрнең хезмәт хакы (хезмәткә түләү) – хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарылган эшнең катлаулылыгына, санына, сыйфатына һәм шартларына карап хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру түләүләре;

- кызыксындыру характерындагы түләүләр – өстәмә түләүләр һәм

кызыксындыру характерындагы өстәмәләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре;

- компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр, шул исәптән нормаль шартлардагы эш өчен һәм компенсация характерындагы башка түләүләр.

1.3. Мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрнең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмалары медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба – мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре) хезмәт хакы (хезмәткә түләү) түбәндәге очраклардан чыгып билгеләнә:

- вазыйфаи окладлар;

- компенсация характерындагы түләүләр;

- кызыксындыру характерындагы түләүләр.

1.4. Хезмәткәрнең профиль буенча эш стажы артуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә, еллык яисә башка ялда булу чорында, аның вакытлыча эшкә сәләтсезлеге чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә хезмәт өчен түләү күләмен үзгәртү хокукы булганда, аның хезмәте өчен түләү күләмен үзгәртү күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң гамәлгә ашырыла.

1.5. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре:

- белем һәм педагогик эш стажы (белгечлек, билгеле бер вазыйфада эшләү буенча) турындагы документларны Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 26 августындагы 761н номерлы «Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеген, «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикалары» бүлеген раслау турында»гы боерыгы белән билгеләнгән квалификация характеристикаларына туры килү-килмәве буенча тикшерәләр;

- ел саен гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә тарификация исемлекләре төзиләр һәм раслыйлар;

- гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы булалар.

1.6. Казан шәһәре Башкарма комитетының мәгариф идарәсе (алга таба – Идарә) гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре эшчәнлегенең

нәтиҗәлелеген бәяли, шуның нигезендә кызыксындыру түләүләрен билгели.

## II. Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Аена төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Вожатый | 19515 |
| | Тәрбияче ярдәмчесе | |
| | Укыту бүлеге секретаре | |
| Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Режим буенча дежур торучы | 19625 |
| | Кече тәрбияче | |
| Икенче | Мәгариф оешмасы диспетчеры | 19825 |
| | Режим буенча өлкән дежур торучы | |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Хезмәт буенча инструктор | 20705 |
| | Физик культура инструкторы | |
| | Музыка җитәкчесе | |
| | Өлкән вожатый | |
| Икенче | Концертмейстер | 20800 |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | |
| | Педагог-оештыручы | |
| | Социаль педагог | |
| | Тренер-укытучы | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче | Тәрбияче | 20900 |
| | Производствода укыту мастеры | |
| | Педагог-психолог | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| | Өстәмә белем бирүнең өлкән педагогы | |
| | Өлкән тренер-укытучы | |
| | Методист | |
| Дүртенче | Укытучы (профессор-укытучылар | 21000 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Аена төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| | составына кертелгән укытучылар вазыйфаларыннан тыш) | |
| | Тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләрен укытучы-оештыручы | |
| | Физик тәрбия җитәкчесе | |
| | Укытучы | |
| | Өлкән тәрбияче | |
| | Өлкән методист | |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | |
| | Укытучы-дефектолог | |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |
| | Педагог-китапханәче | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Балаларга гомуми белем бирү программасын һәм өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм башка структур бүлекчәләр, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешма мөдире (башлыгы) (икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | 21050 |
| Икенче | Уку-укыту программасын һәм балаларга өстәмә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы), кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе, укыту | 21100 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Аена төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| | хуҗалыгы башлыгы (мөдире, директоры, җитәкчесе, идарәчесе) һәм башкалар | |

2.2. Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары мәдәният хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа атамасы | Аена төп оклад күләме, сум |
|---|---|
| «Урта буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 20862 |
| Культорганизатор | |
| «Әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Китапханәче | 21362 |
| Тавыш операторы | |
| Әйдәп баручы китапханәче | |
| Рәссам-бизәүче | |
| Баш китапханәче | |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Китапханәнең бүлек (сектор) мөдире | 22562 |
| Музейның бүлек (сектор) мөдире | |

2.3. Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмалары медицина хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Аена төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| «Беренче дәрәҗә медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Авыруларны карау буенча кече шәфкать туташы | 19242 |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 20163 |
| Икенче | Диета буенча шәфкать туташы | 20663 |
| Өченче | Шәфкать туташы | 21163 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Аена төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| | Физиотерапия буенча шәфкать туташы | |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Дүртенче | Фельдшер | 21863 |
| | Процедуралар буенча шәфкать туташы | |
| Бишенче | Өлкән шәфкать туташы | 22863 |
| | Сәламәтлек пункты мөдире – фельдшер (шәфкать туташы) | |
| «Табиблар һәм провизорлар» вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиблардан тыш) | 24563 |

## III. Мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакы ставкасы (төп оклад) өчен сәгатьләр нормасы

3.1. Эш вакытының озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш вакытының нормалары) Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 22 декабрендәге 1601 номерлы «Педагогик хезмәткәрләрнең эш вакыты озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары) турында һәм хезмәт килешүендә игълан ителә торган педагогик хезмәткәрләрнең укыту йөкләнешен билгеләү тәртибе турында»гы боерыгы белән билгеләнгән.

Гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре өчен эш вакытының озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен сәгатьләр нормасы) кыскартылган эш вакыты озынлыгыннан чыгып билгеләнә – атнага 36 сәгатьтән артмый, ул укыту (уку) эшен, тәрбия эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфаи бурычларны һәм эш вакыты режимында каралган башка педагогик эшне үз эченә ала.

3.2. Вазыйфасына һәм (яисә) белгечлегенә карап, педагогик хезмәткәрләргә эш вакытының түбәндәге озынлыгы яисә хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләренең нормасы билгеләнә:

3.2.1. атнага 36 сәгатьлек эш вакыты түбәндәгеләргә билгеләнә:

- мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы

оешмаларның һәм өстәмә эшчәнлек төре буларак белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бала йортларының өлкән тәрбиячеләренә;

- педагог-психологларга;

- социаль педагогларга;

- оештыручы педагогларга;

- производствода өйрәтү осталарына;

- өлкән вожатыйларга;

- хезмәт буенча инструкторларга;

- педагог-китапханәчеләргә;

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар методистларына һәм өлкән методистларына;

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тьюторларына, югары белемнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалардан тыш;

- урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның физик тәрбия җитәкчеләренә;

- тормыш иминлеге нигезләрен укытучы- оештыручыларга;

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның инструктор-методистларына, өлкән инструктор-методистларына;

3.2.2. атнага 30 сәгать буе эш вакытының озынлыгы өлкән тәрбиячеләргә (әлеге Нигезләмәнең 3.2.1 пунктында күрсәтелгән өлкән тәрбиячеләрдән тыш) билгеләнә;

3.2.3. хезмәт хакы ставкасы өчен атнага 20 сәгать күләмендә түбәндәгеләргә педагогик эш сәгатьләренең нормасы билгеләнә:

- укытучы-дефектологларга;

- укытучы-логопедларга;

3.2.4. хезмәт хакы ставкасы өчен атнага 24 сәгать күләмендә педагогик эш сәгатьләренең нормасы түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

- музыка җитәкчеләренә;

- концертмейстерларга;

3.2.5. хезмәт хакы ставкасы өчен атнага 25 сәгать күләмендә педагогик эш сәгатьләре нормасы сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны (тәрбияләнүчеләрне) турыдан-туры укытуны, тәрбияләүне, карап торуны һәм карауны гамәлгә ашыручы тәрбиячеләргә билгеләнә;

3.2.6. хезмәт хакы ставкасы өчен атнага 30 сәгать күләмендә педагогик эш сәгатьләре нормасы түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

- физик культура буенча инструкторларга;

- интернатта тәрбияләнүчеләргә яшәү өчен, шулай ук озайтылган көн төркемнәрендә балаларны карап тору һәм карау өчен шартлар тудырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның; ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның; туберкулез интоксикациясе булган укучылар (тәрбияләнүчеләр) өчен оешмаларның (төркемнәрнең), шул исәптән шифаханә оешмалары; медицина оешмаларының; өстәмә эшчәнлек төре сыйфатында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның; социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының (алга таба – медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары) тәрбиячеләренә (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары әлеге Нигезләмәнең 3.2.5 һәм 3.2.7 пунктларында каралган тәрбиячеләрдән тыш);

3.2.7. хезмәт хакы ставкасы өчен атнага 36 сәгать күләмендә педагогик эш сәгатьләре нормасы түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

- өстәмә гомуми белем бирү программалары, мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, урта һөнәри белем бирү мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, шулай ук балаларны карап тору һәм карауны гамәлгә ашыручы оешмалар тәрбиячеләренә (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары әлеге Нигезләмәнең 3.2.5 һәм 3.2.6 пунктларында каралган тәрбиячеләрдән тыш);

3.2.8. әлеге Нигезләмәнең 3.2.8 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән педагогик хезмәткәрләрнең эш хакы ставкасы өчен педагогик эш нормасына аларның педагогик эшенең нормалаштырыла торган өлеше булып торучы уку (укытучылык) эше нормасы (алга таба – уку (укытучылык) эше сәгатьләре нормасы) кабул ителә;

а) хезмәт хакы ставкасы өчен атнага 18 сәгать күләмендә уку (укытучылык) эше сәгатьләре нормасы түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

- төп гомуми белем бирү программалары (шул исәптән җайлаштырылган) буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар укытучыларына;

- сәнгать, физик культура һәм спорт өлкәсендә өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар укытучыларына;

- өстәмә белем бирү педагогларына һәм өстәмә белем бирүнең өлкән педагогларына;

- физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның тренер-укытучыларына һәм өлкән тренер-укытучыларына;

- медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары логопедларына;

- мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының чит тел укытучыларына;

- педагогик юнәлештәге урта һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар укытучыларына (әлеге оешмаларның хезмәт хакы ставкасы өчен елына 720 сәгать күләмендә уку (укытучылык) эше сәгатьләре нормасын кулланучы укытучыларыннан тыш);

б) хезмәт хакы ставкасы өчен елына 720 сәгать күләмендә уку (укытучылык) эше нормасы урта һөнәри белем бирү мәгариф программалары буенча, шул исәптән сәнгать өлкәсендә интеграцияләнгән мәгариф программалары һәм һөнәри белем бирүнең төп программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның укытучыларына (әлеге Нигезләмәнең 3.2.8 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән укытучылардан тыш) билгеләнә.

Биләгән вазыйфаларына бәйле рәвештә педагогик хезмәткәрләрнең эш вакытына уку (укытучылык) эше, тәрбия эше, укучылар белән индивидуаль эш, фәнни, иҗади һәм тикшеренү эшләре, шулай ук хезмәт (вазыйфаи) бурычлары һәм (яисә) индивидуаль план белән каралган башка педагогик эш керә: методик, әзерлек, оештыру, диагностика эше, мониторинг алып бару эше, укучылар белән уздырыла торган тәрбия, физкультура-савыктыру, спорт, иҗади һәм башка чаралар планында каралган, укучылар белән уздырыла торган эш.

Педагогик хезмәткәрләрнең әлеге Нигезләмәнең 3.2.3-3.2.7 пунктларында каралган хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш нормасы астрономик сәгатьләрдә билгеләнә. Әлеге Нигезләмәнең 3.2.8 пунктында каралган уку (укытучылык) эше нормалары кыска тәнәфесләрне (тәнәфесләрне), динамик паузаны исәпкә алып, астрономия сәгатьләрендә билгеләнә.

Әлеге Нигезләмәнең 3.2.5-3.2.7 пунктларында каралган хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы һәм әлеге Нигезләмәнең 3.2.8 пунктында каралган уку (укытучылык) эше нормалары педагогик хезмәткәрләргә, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан билгеләнгән атнага (елга) педагогик яисә укыту (укытучылык) эше күләмен исәпкә алып, бер ай өчен хезмәт хакы исәпләү күләме булып тора.

Педагогик хезмәткәр тарафыннан язма ризалыгы белән башкарыла торган педагогик эш яисә уку (укытучылык) эше өчен хезмәт хакы ставкасы өчен билгеләнгән сәгатьләр нормасыннан артыграк яисә хезмәт хакы ставкасы өчен билгеләнгән сәгатьләр нормасыннан түбәнрәк булган өчен түләү хезмәт хакы ставкасының билгеләнгән күләменнән педагогик яисә уку (укытучылык) эшенең

фактта билгеләнгән күләменә пропорциональ рәвештә түләнә, моңа хезмәт хакы ставкаларын атнага хезмәт хакы ставкасы өчен билгеләнгән уку (укытучылык) эше сәгатьләренең нормасына туры килә торган күләмендә уку йөкләнеше тәэмин итеlә алмаган укытучыларга тулы күләмдә хезмәт хакы ставкалары түләнә торган очраклар керми;

3.2.9. Атнага 40 сәгатьлек эш вакыты озынлыгы әлеге Нигезләмәнең 3.2.1-3.2.8 пунктларында күрсәтелмәгән хезмәткәрләргә, шул исәптән мәгариф оешмалары җитәкчеләренә, аларның урынбасарларына һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренә билгеләнә;

3.2.10. хезмәт хакы ставкасы өчен укытучылык (педагогик) эш сәгатьләре нормасы түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

- физик тәрбия җитәкчеләренә, тормыш иминлеге нигезләрен, хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр әзерлекне оештыручы укытучыларга – елына 360 сәгать күләмендә;

- укучылар саны 50 кешегә кадәр булган башлангыч гомуми белем бирү оешмалары (педагогика көллиятләре студентларының педагогик практикасын узу өчен беркетелгән башлангыч гомуми белем бирү оешмаларыннан тыш), укучылар саны 80 кешегә кадәр булган кичке (сменалы) гомуми белем бирү оешмалары (шәһәр тибындагы шәһәрләрдә һәм поселокларда – 100 кешегә кадәр) директорларына – атнага 10 сәгать күләмендә;

- бер-ике төркемле мәктәпкәчә мәгариф оешмалары мөдирләренә (балалар тәүлек буе була торган бер яки берничә төркемле оешмалардан тыш) – көненә өч сәгать күләмендә.

Мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең эш вакыты (хезмәт хакы ставкасы өчен эш сәгатьләре нормалары) дәвамлылыгы Россия Федерациясе Хезмәт кодексы белән билгеләнә.

3.2.11. туберкулез интоксикациясе булган укучылар (тәрбияләнүчеләр) өчен төркемнәрдә эшләүче оешмаларның (төркемнәрнең) кече тәрбиячеләренә һәм тәрбиячеләр ярдәмчеләренә эш хакы ставкасы өчен атнага – 30 сәгать, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләр өчен төркемнәрдә эшләүчеләргә 36 сәгать билгеләнә.

Оешмаларның (төркемнәрнең) кече тәрбиячеләренә һәм тәрбиячеләр ярдәмчеләренә хезмәт хакы ставкасы өчен эш вакыты озынлыгы атнага 40 сәгать билгеләнә (хезмәт хакы ставкасы өчен эш сәгатьләре нормалары әлеге Нигезләмәнең 3.2.11 пунктының 1 абзацында каралган кече тәрбиячеләрдән һәм тәрбиячеләр ярдәмчеләреннән тыш).

## IV. Гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең күләм күрсәткечләренең норматив саны

4.1. Хезмәт хакының (төп окладның) база ставкасы сәгате өчен мәгариф хезмәткәрләре күрсәтә торган күләм күрсәткечләренең норматив саны:

4.1.1. укытучыларга, хезмәт буенча инструкторларга, производствода белем бирү осталарына, физик тәрбия җитәкчеләренә, тормыш иминлеге һәм хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр әзерлек нигезләрен укытучы-оештыручыларга:

- 25 кеше – бер яисә берничә фән буенча укучыларны өстәмә (тирәнтен) әзерләүне тәэмин итә торган гомуми белем бирү программасын һәм гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы шәһәр гомуми белем бирү оешмаларының (шул исәптән гимназияләрнең, лицейларның, кичке (сменалы) гомуми белем бирү мәктәпләренең) сыйныфларында;

- 20 кеше – башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем интернаты булган гомуми белем бирү оешмалары, шул исәптән аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче, гимназия-интернатлар, лицей-интернатлар, интернаты булган шәһәр шифаханә-белем бирү оешмалары, шәһәр шифаханә-урман мәктәпләре, кадет мәктәпләре, интернаты булган кадет мәктәпләре сыйныфларында;

- 9 кеше – кичке (сменалы) гомуми белем мәктәпләрендә читтән торып уку формасы булган төркемнәрдә.

Туган телдә белем бирүче гомуми белем бирү оешмаларында (сыйныфларда) гомуми белем бирүнең беренче, икенче һәм өченче дәрәҗәләрендә чит тел, рус теле һәм әдәбияты буенча дәресләр уздырганда, гомуми белем бирүнең икенче һәм өченче дәрәҗәләрендә – хезмәт белеме буенча, гомуми белем бирүнең өченче дәрәҗәсендә – физик культура буенча, шулай ук информатика һәм хисаплау техникасы, физика һәм химия (практик дәресләр вакытында) буенча дәресләр уздырганда сыйныфның тулылыгы 25 кеше булса, сыйныфны ике төркемгә бүлү рөхсәт ителә.

Рус телендә белем бирүче гомуми белем бирү оешмаларында (сыйныфларда) гомуми белем бирүнең беренче, икенче һәм өченче дәрәҗәләрендә чит тел, рус теле һәм әдәбияты буенча дәресләр уздырганда, гомуми белем бирүнең икенче һәм өченче дәрәҗәләрендә – хезмәт белеме буенча, гомуми белем бирүнең өченче дәрәҗәсендә – физик культура буенча, шулай ук информатика һәм хисаплау техникасы, физика һәм химия (практик дәресләр вакытында) буенча дәресләр уздырганда сыйныфның тулылыгы

25 кеше булса, сыйныфны ике   төркемгә бүлү рөхсәт ителә.

Сыйныфлар 25 кешедән кимрәк булганда, төркемчәләргә бүлү, Идарә белән килештереп, конкрет гомуми белем бирү оешмасы буенча белем бирүнең федераль дәүләт стандартын гамәлгә ашыруга акчаларның норматив күләмен исәпкә алып билгеләнә.

Рус телле гомуми белем бирү оешмаларында туган телләрне өйрәнгәндә төркемнәр туплауның түбәндәге вариантын сакларга кирәк:

- әгәр параллельдә 2 һәм аннан да күбрәк сыйныф-комплектлар булса, ата аналар гаризасы нигезендә төрле сыйныфлардан туган телләрне өйрәнү төр кемнәрен мәгариф системасы биргән мөмкинлекләр чикләрендә, туган (рус) теле, туган (татар) теле – Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак (рус телле төркемнәр), туган (татар теле) татар телле һәм Россия Федерациясе халыклары телләре саныннан башка туган телләр принцибы буенча берләштерү мөмкин.

Шул ук вакытта туган телләрне өйрәнү буенча 25 укучыдан артык булмаган төркемнәр төзергә тәкъдим ителә;

-  параллельдә 1 сыйныф-комплект кына булган очракта, туган телләрне өй рәнгәндә мондый сыйныф ата-аналар гаризасы нигезендә, балаларның фактик бүленеше буенча, белем бирү системасы биргән мөмкинлекләр чикләрендә туган телләрне өйрәнү төркемнәренә бүленә.

4.1.2. сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән укучылар (тәрбияләнүчеләр) белән турыдан-туры эшләүче укытучыларга, хезмәт буенча инструкторларга, производствода белем бирү осталарына, физик тәрбия җитәкчеләренә, тормыш иминлеге һәм хәрби хезмәткә әзерлек нигезләрен оештыручы укытучыларга, өстәмә белем бирү педагогларына, укытучы-дефектологларга, укытучы-логопедларга, озайтылган көн төркемнәре тәрбиячеләренә:

5 кеше – гомуми белем бирү оешмаларында гомуми белем бирү оешмалары, махсус (коррекцион) сыйныфлар өчен:

I төр – психик үсеше тоткарланган яки акыл ягыннан артта калган саңгырау балалар өчен;

II төр – ишетү сәләте бозылу һәм акыл ягыннан артта калу сәбәпле сөйләме нык тоткарланган начар ишетүче һәм соң саңгырау балалар өчен;

II төр – ишетү сәләте бозылу һәм психик үсеше тоткарлану сәбәпле сөйләме нык тоткарланган начар ишетүче һәм соң саңгырау балалар өчен;

III төр – психик үсеше тоткарланган сукыр балалар өчен;

III төр – акыл ягыннан артта калган сукыр балалар өчен;

IV төр – начар күрүче һәм акыл ягыннан артта калган соң сукыр балалар өчен;

VI төр – терәк-хәрәкәт аппараты бозылган һәм акыл ягыннан артта калган балалар өчен;

6 кеше – гомуми белем бирү оешмаларында гомуми белем бирү оешмалары, махсус (коррекцион) сыйныфлар өчен:

I төр – саңгырау балалар өчен;

II төр – начар ишетүче һәм ишетү сәләте бозылу сәбәпле сөйләме нык тоткарланган, соңрак ишетми башлаган балалар өчен;

8 кеше – сукыр балалар өчен III төр гомуми белем бирү оешмалары өчен, иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән (психик үсешләрендә тоткарлык һәм акыл ягыннан артта калуның җиңел формалары булган) балалар һәм яшүсмерләр өчен гомуми белем бирү оешмалары өчен;

6 кеше – гомуми белем бирү оешмаларында гомуми белем бирү оешмалары, махсус (коррекцион) сыйныфлар өчен;

II төр – начар ишетүче һәм ишетү сәләте бозылу сәбәпле сөйләме җиңелчә тоткарланган соңрак ишетми башлаган балалар өчен;

VI төр – терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар өчен;

VIII төр – акылга нык артта калган балалар өчен;

12 кеше – гомуми белем бирү оешмаларында гомуми белем бирү оешмалары, махсус (коррекцион) сыйныфлар өчен:

IV төр – начар күрүче һәм соң сукырайган балалар өчен;

V төр – сөйләме нык бозылган балалар өчен;

VII төр – психик үсешләрендә тоткарлык булган балалар өчен;

VIII төр – акыл ягыннан артта калган балалар өчен;

20 кеше – шәһәр җирендәге озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә-белем бирү оешмалары өчен;

15 кеше – авыл җирлегендә озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә-белем бирү оешмалары өчен.

Хезмәттә укыту, социаль-көнкүреш юнәлеше буенча дәресләр, факультатив дәресләр үткәргәндә сыйныф (төркем) ике төркемчәгә бүленә. Сыйныфны (төркемне) төркемчәләргә бүлгәндә кызлар һәм малайлар өчен хезмәт белеменең профиле, шулай ук гомуми белем бирү оешмасының төре исәпкә алына;

4.1.3. мәгариф оешмаларының озайтылган көн төркемнәре тәрбиячеләренә – 25 кеше;

4.1.4. гомуми белем бирү оешмалары тәрбиячеләренә, интернаты булган мәгариф оешмаларында, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен мәгариф оешмаларында, гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда тәрбиячеләргә:

20 кеше – гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернатта, интернаты булган гомуми белем бирү оешмасында;

10 кеше – озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шәһәр шифаханә-белем бирү оешмасында;

7 кеше – озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен авыл шифаханә-белем бирү оешмасында;

5 кеше – махсус гомуми белем бирү мәктәбе (девиант тәртипле укучылар өчен укыту-тәрбия оешмасы), интернаты булган гомуми белем бирү оешмасы өчен:

I төр – психик үсеше тоткарланган яки акыл ягыннан артта калган саңгырау балалар өчен;

II төр – ишетү сәләте бозылу һәм акыл ягыннан артта калу сәбәпле сөйләме нык тоткарланган начар ишетүче һәм соң саңгырау балалар өчен;

II төр – ишетү сәләте бозылу һәм психик үсеше тоткарлану сәбәпле сөйләме нык тоткарланган начар ишетүче һәм соң саңгырау балалар өчен;

III төр – психик үсеше тоткарланган сукыр балалар өчен;

III төр – акыл ягыннан артта калган сукыр балалар өчен;

IV төр – начар күрүче һәм акыл ягыннан артта калган соң сукыр балалар өчен;

VI төр – терәк-хәрәкәт аппараты бозылган һәм психик үсеше тоткарланган балалар өчен;

VI төр – терәк-хәрәкәт аппараты бозылган һәм акыл ягыннан артта калган балалар өчен;

4 кеше – иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән (психик үсешләрендә тоткарлык һәм акыл ягыннан артта калуның җиңел формалары булган) балалар һәм яшүсмерләр өчен гомуми белем бирү оешмалары өчен;

6 кеше – интернаты булган гомуми белем бирү оешмасы өчен:

I төр – саңгырау балалар өчен;

II төр – начар ишетүче һәм ишетү сәләте бозылу сәбәпле сөйләме нык тоткарланган, соңрак ишетми башлаган балалар өчен;

8 кеше – сукыр балалар өчен III төр гомуми белем бирү оешмалары өчен;

10 кеше – гомуми белем бирү оешмаларында гомуми белем бирү

оешмалары, махсус (коррекцион) сыйныфлар өчен:

II төр – начар ишетүче һәм ишетү сәләте бозылу сәбәпле сөйләме җиңелчә тоткарланган соңрак ишетми башлаган балалар өчен;

VI төр – терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар өчен;

VIII төр – акылга нык артта калган балалар өчен;

12 кеше – интернаты булган гомуми белем бирү оешмасы өчен:

V төр – сөйләме нык бозылган балалар өчен;

VI төр – начар күрүче һәм соң сукырайган балалар өчен;

VII төр – психик үсешләрендә тоткарлык булган балалар өчен;

VIII төр – акыл ягыннан артта калган балалар өчен.

Мәктәпкәчә яшьтәге укучылар (тәрбияләнүчеләр) белән турыдан-туры эшләүче өлкән тәрбиячеләргә, тәрбиячеләргә, музыка җитәкчеләренә, укытучы-дефектологларга, укытучы-логопедларга, педагог-психологларга, кече тәрбиячеләргә, тәрбиячеләрнең ярдәмчеләренә:

гомуми үсеш юнәлешендәге төркемнәрдә (төрле яшьтәгеләрне дә кертеп):

ике айдан өч яшькә кадәр – 15 бала;

өч яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганчыга кадәр – 20 бала;

гаилә белеме рәвешендәге төркемнәрдә – 7 бала;

өч яшькә кадәрге һәм өч яшьтән өлкәнрәк балалар өчен компенсацияләү юнәлешендәге төркемнәрдә:

сөйләме нык бозылган балалар өчен – тиешенчә 6 һәм 10 бала;

сөйләмендә фонетик-фонематик тайпылышлар булган өч яшьтән өлкәнрәк балалар өчен – 12 бала;

саңгырау балалар өчен – ике яшь төркеме өчен дә 6 бала;

начар ишетүче балалар өчен – тиешенчә 6 һәм 8 бала;

сукыр балалар өчен – ике яшь төркеме өчен дә 6 бала;

начар күрүче, амблиопияле, кыек күзле балалар өчен – тиешенчә 6 һәм 10 бала;

терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар өчен – тиешенчә 6 һәм 8 бала;

психик үсеше тоткарланган балалар өчен, җиңел дәрәҗәдәге акыл ягыннан артта калган балалар өчен – тиешенчә 6 һәм 10 бала;

өч яшьтән өлкәнрәк булган уртача, авыр дәрәҗәдәге акыл ягыннан артта калган балалар өчен – 8 бала;

аутистик спектрында тайпылышлары булган балалар өчен – ике яшь төркеме өчен дә 5 бала;

катлаулы кимчелекләре булган (физик һәм (яисә) психик үсештә ике яисә

аннан күбрәк кимчелекләре булган) балалар өчен – ике яшь төркеме өчен дә 5 бала;

катнаш юнәлешле төркемнәрдә:

өч яшькә кадәрге – 10 баладан артык түгел, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән өч баладан артык түгел;

өч яшьтән өлкәнрәкләр:

10 баладан артык түгел, шул исәптән иң күбе өч саңгырау бала, яисә сукыр балалар, яисә терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар, яисә уртача, авыр дәрәҗәдәге акыл ягыннан артта калган балалар, яисә аутистик спектры бозылган балалар, яисә катлаулы дефектлы балалар;

15 баладан артык түгел, шул исәптән иң күбе начар күрүче дүрт бала, һәм (яисә) амблиопияле, һәм (яисә) кыек күзле балалар, яисә начар ишетүче балалар, яисә сөйләме бик нык бозылган балалар, яисә акыл ягыннан җиңелчә артта калган балалар;

17 баладан артык түгел, шул исәптән психик үсешләрендә тоткарлык булган биш баладан да күбрәк түгел;

өч яшькә кадәрге һәм өч яшьтән өлкәнрәк балалар өчен сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемнәрдә:

туберкулез интоксикациясе булган балалар өчен – тиешенчә 10 һәм 15 бала;

еш авыручы балалар һәм махсус сәламәтләндерү чаралары комплексы кирәк булган башка категориядәге балалар өчен – тиешенчә 10 һәм 15 бала;

4.1.5. өстәмә белем бирү педагогларына – 15 кеше.

## V. Гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

Гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_N} + P,$$

биредә:

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәренең төп оклады күләме;

$H_f$ – гомуми белем бирү оешмаларында эш сәгатьләренең фактик саны;

$H_N$ – әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән гомуми белем бирү

оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакының төп ставкасы өчен сәгатьләр нормасы;

P – китап нәшрияты продукциясе һәм вакытлы матбугат белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация педагогик хезмәткәрләргә укыту йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмый.

## VI. Кызыксындыру характерындагы түләүләр

6.1. Кызыксындыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне хезмәтнең сыйфат нәтиҗәләренә этәргеч бирүгә, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

Кызыксындыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- квалификация категориясе өчен түләүләр;
- мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләүләр;
- профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;
- хезмәтнең интенсивлыгы өчен түләүләр;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре;
- башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр.

6.2. Гомуми белем бирү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләрнең күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе:

6.2.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) педагогик хезмәткәрләрнең һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә квалификация категориясенең гамәлдә булу срогы чикләрендә аларның гамәлдәге квалификация категориясе булганда бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk}=O_d\times\frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә күләме 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмәләрнең күләмнәре**

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Квалификация категориясе** | **Өстәмә күләме, процент** |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче | 10,0 |
| | Югары | 22,0 |
| Икенче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 24,0 |
| Өченче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 24,0 |
| Дүртенче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 24,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 24,0 |
| Икенче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 24,0 |
| Өченче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 24,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән алып башкарыла.

6.2.2. Мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) беренче һәм икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал, педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен өстәмә күләме.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының,

Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасы (Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы) мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең ведомство бүләкләре, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасының ведомство бүләкләре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның ведомство бүләкләре булган өчен өстәмәләр күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) Мактау грамотасы булган өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) Мактау грамотасы булган өчен өстәмә Россия Федерациясе мәгариф министры (Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе мәгариф министры) боерыгы белән бүләкләнүче мәгариф хезмәткәрләренә Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының) ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә билгеләнә.

«Мәгарифтәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» аерымлык билгесе, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» аерымлык билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе булган өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. Татарстан Республикасының «Мәгарифтәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» аерымлык билгесе, «Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» аерымлык билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклап калган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе булган өчен өстәмә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләүләр

күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән алып башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәре һәм (яисә) ике һәм аннан да күбрәк ведомство бүләкләре булган хезмәткәрләргә түләү хезмәткәрнең үз ихтыяры буенча нигезләрнең берсе буенча билгеләнә.

6.2.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә стаж буенча төркемнәр буенча, профиль буенча эш озынлыгына бәйле рәвештә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Квалификация дәрәҗәсе** | **Стаж буенча төркеме** | **Өстәмә күләме, процент** |
|---|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче-икенче | 4 елдан 10 елга кадәр | 1,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,0 |
| | | 15 елдан артык | 3,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче-дүртенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 2,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 3,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | | 15 елдан артык | 4,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-өченче | 2 елдан 6 елга кадәр | 2,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 3,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | | 15 елдан артык | 4,0 |

6.2.4. Профиль буенча эш стажы үзгәргәндә эш стажы өчен түләү

күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) эш стажы үзгәргәндә эш стажы өчен түләү күләмен арттыруга хокук бирә торган стажга ирешү көненнән алып, әгәр стажын раслый торган документлар гомуми белем бирү оешмасында булса, яисә стажын раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән башлап башкарыла.

6.2.5. 3 нче таблица нигезендә мәгариф оешмаларында һәм башка оешмаларда педагогик, җитәкчелек һәм методик эш педагогик эш стажына кертелә.

3 нче таблица

**Алар буенча эш вакыты мәгариф хезмәткәрләренең педагогик стажына исәпләнә торган оешмалар һәм вазыйфалар исемлеге**

| Оешманың аталышы | Вазыйфа атамасы |
|---|---|
| Мәгариф оешмалары, шул исәптән югары белем бирү оешмалары, югары белем бирүнең хәрби мәгариф оешмалары һәм хәрби һөнәри белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү (белгечләрнең квалификациясен күтәрү) оешмалары; медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары: балалар йортлары, балалар шифаханәләре, клиникалар, поликлиникалар, хастаханәләр һ.б. | Укытучылар, мөгаллимнәр, укытучы-дефектологлар, укытучы-логопедлар (логопедлар), тормыш иминлеге нигезләрен, хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр әзерлекне оештыручы укытучылар, физик тәрбия җитәкчеләре, өлкән мастерлар, производствода өйрәтү (шул исәптән транспорт чараларын йөртүгә, авыл хуҗалыгы машиналарында эшләргә, язу машиналарында эшләргә һәм башка оештыру техникасында эшләргә өйрәтү) осталары, өлкән методистлар, методистлар, өлкән инструктор-методистлар, инструктор-методистлар (шул исәптән физик культура һәм спорт, туризм буенча), концертмейстерлар, музыка җитәкчеләре, өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр, сыйныф тәрбиячеләре, социаль педагоглар, педагог-психологлар, педагог-оештыручылар, өстәмә белем бирү педагоглары, өлкән тренер-укытучылар, тренер-укытучылар, өлкән вожатыйлар (пионервожатыйлар), физкультура, укыту, укыту-тәрбия, укыту-җитештерү, тәрбия, мәдәни-тәрбия эше, производствода укыту (эш), чит тел, укыту-очу әзерлеге, гомуми белем бирү әзерлеге, режим буенча хезмәт буенча инструкторлар, практика, уку-укыту, укыту-җитештерү, тәрбия, |

| Оешманың аталышы | Вазыйфа атамасы |
|---|---|
| | мәдәни-тәрбия эше буенча эшчәнлекләре белем бирү (тәрбия) процессына, методик тәэмин итүгә бәйле булган консультация пунктлары, логопед пунктлары, интернатлар, бүлекчәләр, бүлекләр, лабораторияләр, кабинетлар, секцияләр, филиаллар, курслар һәм башка структур бүлекчәләр директорлары (башлыклары, мөдирләре), директорларның урынбасарлары (башлыклары, мөдирләре), уку-укыту бүлеге мөдирләре, мөдирләре (башлыклары); режим буенча өлкән дежурлар, режим буенча дежурлар, аккомпаниаторлар, культорганизаторлар, экскурсоводлар; профессор-укытучылар составы |
| Барлык исемдәге методик (укыту-методик) оешмалар (ведомство буйсынуына карамастан) | Җитәкчеләр, аларның урынбасарлары, секторлар, кабинетлар, лабораторияләр, бүлекләр мөдирләре; эшчәнлекләре методик тәэмин итү белән бәйле булган фәнни хезмәткәрләр; өлкән методистлар, методистлар |
| Мәгарифкә идарә итү органнары һәм мәгариф оешмаларына җитәкчелек итүче органнар (структур бүлекчәләр) | Җитәкче, инспектор, методик вазыйфалар, инструктор, шулай ук белгечләрнең башка вазыйфалары (икътисадый, финанс, хуҗалык эшчәнлегенә, төзелешкә, тәэмин итүгә, эш башкаруга бәйле вазыйфаларда эшләүдән тыш) |
| Җитештерүдә кадрлар әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмаларның, министрлыкларның (ведомстволарның) бүлекчәләренең техник укыту бүлекләре (бюролары), кадрлар бүлекләре | Эшчәнлекләре квалификация әзерләү һәм күтәрү мәсьәләләре белән бәйле булган штатлы укытучылар, производствода эшчеләрне производствода укыту осталары, җитәкче, инспектор, инженер, методик вазыйфалар |
| РОСТО (ДОСААФ) һәм гражданлык авиациясе мәгариф оешмалары | Җитәкче, команда-очу, команда-инструктор, инженер-инструктор, инструктор һәм укытучылар составы, производствода укыту осталары, инженер-инструктор-методистлар, инженер-очучы-методистлар |
| Оешмаларның тулай тораклары, торак-эксплуатация оешмалары, яшьләр торак комплекслары, балалар кинотеатрлары, яшь тамашачы театрлары, курчак театрлары, балалар һәм | Тәрбиячеләр, педагог-оештыручылар, педагог-психологлар (психологлар), укытучылар, балалар һәм яшүсмерләр өчен өстәмә белем бирү педагоглары (түгәрәк җитәкчеләре), инструкторлар һәм инструктор-методистлар, тренер-укытучылар |

| Оешманың аталышы | Вазыйфа атамасы |
|---|---|
| яшүсмерләр белән эшләү буенча мәдәни-агарту оешмалары | һәм балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү буенча башка белгечләр, балалар бүлекләре, секторлар мөдирләре |
| Төзәтү колонияләре, тәрбия колонияләре, тикшерү изоляторлары һәм төрмәләре, дәвалау-төзәтү оешмалары | Педагогик белем булганда түбәндәге вазыйфаларда эш (хезмәт): тәрбия эше буенча җитәкче урынбасары, отряд башлыгы, өлкән инспектор, гомуми белем бирү эше (укыту) буенча инспектор, өлкән инспектор-методист һәм инспектор-методист, җитештерү-техник укыту буенча өлкән инженер һәм инженер, өлкән мастер һәм җитештерү укыту мастеры, саклау һәм режим буенча өлкән инспектор һәм инспектор, укыту-техник кабинет мөдире, психолог |

Педагогик эш стажына түбәндәгеләр кертелә:

- медицина оешмаларында һәм өлкәннәргә социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларда укытучы-дефектологлар, логопедлар, тәрбиячеләр, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау оешмаларының оештыру-методик бүлеге методистлары сыйфатында эшләү вакыты;

- башка оешмаларда эшләү, СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү, югары белем бирү мәгариф оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында урта буын белгечләрен әзерләү программалары буенча уку вакыты, түбәндәге тәртиптә:

а) педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына бернинди шартлар һәм чикләүләрсез кертелә:

- контракт буенча хәрби хезмәттә булу вакыты – бер көн хәрби хезмәт өчен бер эш көне хисабыннан, ә хәрби хезмәткә чакырылу буенча хәрби хезмәттә булу вакыты – хәрби хезмәтнең бер көне өчен ике эш көне хисабыннан;

- фильмотека мөдире һәм фильмотека методисты вазыйфасында эшләү вакыты;

б) педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына түбәндәге чорлар кертелә, әгәр аерым һәм тулаем алганда алынган бу чорларга педагогик эшчәнлек турыдан-туры алардан алда һәм аннан соң турыдан-туры гамәлгә ашырылган булса:

- СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә офицерлар, сержантлар, старшиналар составы, прапорщиклар һәм мичманнар (шул исәптән Эчке эшләр министрлыгы гаскәрләрендә, гаскәрләрдә һәм иминлек органнарында) вазыйфаларында хезмәт итү, контракт буенча һәм чакырылыш

буенча хәрби хезмәттә булу вакытыннан тыш;

- Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре һөнәр берлегенең (мәгариф, югары мәктәп һәм фәнни оешмалар) территориаль оешмалары аппаратларында (комитетларында, советларында) җитәкче, инспектор, инструктор һәм башка белгечләр вазыйфаларында эшләү;

- профсоюз органнарында сайланулы вазыйфаларда эшләү;

- педагогик җәмгыятьләрдә һәм балалар фонды идарәләрендә инструкторлык һәм методик вазыйфаларда эшләү;

- укытучы йорты директоры (мөдире) (халык мәгарифе, һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре) вазыйфасында эшләү;

- эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрендә яисә балигъ булмаганнарны социаль-хокукый саклау бүлекләрендә, хокук бозуларны кисәтү бүлекчәләрендә (балигъ булмаганнар эшләре буенча инспекцияләрдә, милициянең балалар бүлмәләрендә) эшчәнлек.

6.2.6. Аерым категория педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына оешмаларда эшләү вакыты һәм СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә белем бирү оешмасында эшләү профиленә яисә укытыла торган предмет (курс, дисциплина, түгәрәк) профиленә туры килә торган белгечлек (һөнәр) буенча хезмәт итү вакыты кертелә:

- тормыш иминлеге нигезләрен, хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр әзерлекне оештыручы укытучыларга;

- физик тәрбия укытучыларына һәм мөгаллимнәренә, физик тәрбия җитәкчеләренә, физкультура буенча инструкторларга, инструктор-методистларга (өлкән инструктор-методистларга), тренер-укытучыларга (өлкән тренер-укытучыларга);

- укытучыларга, хезмәт (һөнәри) укыту, технология, сызым, сынлы сәнгать, информатика, махсус дисциплиналар, шул исәптән аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче гомуми белем бирү оешмаларының (сыйныфларның) махсус дисциплиналары укытучыларына, мөгаллимнәренә;

- өстәмә белем бирү педагогларына;

- экспериментал белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә;

- педагог-психологларга;

- методистларга;

- музыка һәм сәнгать гомуми белем бирү оешмаларының махсус дисциплиналары укытучыларына.

6.2.7. Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының, бала йортлары тәрбиячеләренә

(өлкән тәрбиячеләренә) педагогик стажга мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының ясле төркемендә шәфкать туташы, бала йортларында пост шәфкать туташы вазыйфасында эшләү вакыты, ә ясле төркемнәрендә тәрбиячеләргә медицина вазыйфаларында эшләү вакыты кертелә.

Тәрбияче ярдәмчесе һәм кече тәрбияче вазыйфаларында эшләү вакыты, әлеге вазыйфаларда эшләү чорында хезмәткәр педагогик белем алган яки югары белем бирү мәгариф оешмасында яки һөнәри белем бирү оешмасында белем алган очракта, педагогик эш стажына кертелә.

Оешма хезмәткәрләренә мәгариф оешмаларында сәгатьлек түләү шартларында төп эштән тыш башкарыла торган педагогик эш вакыты, әгәр аның күләме (бер яисә берничә мәгариф оешмасында) уку елында кимендә 180 сәгать тәшкил итсә, педагогик стажга кертелә.

Шул ук вакытта педагогик эш башкарылган айлар гына педагогик стажга кертелә.

Оешмада, оешмаларда эшләүнең һәм СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итүнең эш профиленә, укытыла торган предметка (курс, дисциплина, түгәрәк) туры килүе турындагы конкрет мәсьәләләрне профсоюз органы белән килештереп, мәгариф оешмасы җитәкчесенә хәл итү хокукы бирелә.

6.3. Гомуми белем бирү оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләрнең күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе:

6.3.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{\text{kk}}$) белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә, алар тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләре бирүне күз алдында тота һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_{\text{d}}$ – гомуми белем бирү оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{\text{kk}}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә күләме 4 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (оешма) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

4 нче таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмәләр күләмнәре**

| Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|
| «Әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 5,0 |
| Югары | 8,0 |

6.3.2. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_{\mathrm{d}}$ – гомуми белем бирү оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{\mathrm{pz}}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада китерелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәре булган хезмәткәрләргә түләү хезмәткәрнең ихтыяры буенча аларның берсе буенча билгеләнә.

6.3.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_{\mathrm{s}}$) хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын үтәүне исәпкә алып, профиль буенча эшләү дәвамлылыгына карап, гомуми белем бирү оешмаларының

мәдәният хезмәткәрләренә һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә стаж буенча төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладЫ;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме 5 нче таблицада күрсәтелгән.

5 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Стаж буенча төркеме** | **Өстәмә күләме, процент** |
|---|---|---|
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең урта буын вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 1,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,0 |
| | 15 елдан артык | 2,5 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең әйдәп баручы буын вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | 15 елдан артык | 4,0 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) стажны раслаучы документлар гомуми белем бирү оешмасында булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукы бирә торган стажга ирешкән көннән яисә стажны раслаучы кирәкле документ тапшырылган көннән башкарыла.

6.4. Гомуми белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләрнең күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе:

6.4.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) гомуми белем бирү оешмаларының тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләре бирүне күздә тоткан белгечлекләр буенча эшләүче медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә күләме, ул 6 нчы таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (оешма) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

6 нчы таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмәләр күләмнәре**

| Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче | 3,0 |
| Беренче | 6,0 |
| Югары | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче | 6,0 |
| Беренче | 10,0 |
| Югары | 20,0 |

6.4.2. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче гомуми белем бирү оешмалары медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә

күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтада күрсәтелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәре булган хезмәткәрләргә түләү хезмәткәрнең ихтыяры буенча аларның берсе буенча билгеләнә.

6.4.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә стаж буенча төркемнәр буенча, профиль буенча эш озынлыгына бәйле рәвештә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме 7 нче таблицада китерелгән.

7 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Стаж буенча төркеме** | **Өстәмә күләме, процент** |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗә медицина һәм фармацевтика персоналы | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 4,0 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |

| | | |
|---|---|---|
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү) стажны раслаучы документлар гомуми белем бирү оешмасында булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукы бирә торган стажга ирешкән көннән яисә стажны раслаучы кирәкле документ тапшырылган көннән башкарыла.

6.4.4. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр ($B_{sr}$) урта медицина һәм фармацевтика персоналы, табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә вазыйфалар буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr} = O_d \times \frac{D_{sr}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sr}$ – хезмәтнең интенсивлыгы өчен өстәмәләр күләме 8 нче таблицада китерелгән.

8 нче таблица

**Хезмәтнең интенсивлыгы өчен өстәмәләр күләмнәре**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Квалификация дәрәҗәсе** | **Өстәмәләр диапазоны, процент** |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | Икенче | 1,5 |
| | Өченче | 3,0 |
| | Дүртенче | 4,5 |
| | Бишенче | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар | Беренче-икенче | 3,0 |

6.5. Премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре гомуми белем бирү оешмаларының төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча хезмәткәрләренә (укытучылар һәм укытучылар вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) юбилей даталарына, мактау билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, мактаулы исемнәр алуга бәйле рәвештә билгеле бер вакыт аралыгында (ай, квартал, ел) һәм локаль норматив актларда һәм гомуми белем бирү оешмасының күмәк шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча бирелә.

6.5.1. Эш йомгаклары буенча премия һәм башка кызыксындыру

түләүләренең күләмнәре, тәртибе һәм түләү шартлары гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

6.5.2. Гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә премия түләүләренә каралган хезмәт өчен түләү фонды күләме төп эш урыны һәм төп вазыйфа (укытучылар һәм укытучылар вазыйфасын биләгән хезмәткәрләрдән тыш) (хезмәт хакы, вазыйфаи оклад ставкалары), кызыксындыру характерындагы түләүләр (авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләүләрдән тыш), өстәмә эш төрләре өчен түләүләр, белем бирү программасы үзенчәлеге өчен түләүләр (укытучылар һәм укытучылар вазыйфасын биләгән хезмәткәрләрдән тыш) түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фондының кимендә 2 процентын тәшкил итә.

6.5.3. Гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 07 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Указы белән билгеләнгән ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, акчалар булган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү түләнә. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.

6.6. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр төп эш урыны буенча гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә (укытучылар һәм укытучылар вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) билгеле бер вакыт аралыгындагы хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тора.

6.6.1. Оешмалар хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары, гомуми белем бирү оешмасы белән идарә итүнең дәүләти-иҗтимагый характерын тәэмин итүче орган белән килештереп, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан раслана. Гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының әһәмияте һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары ел саен гомуми белем бирү оешмасы алдына куелган бурычлар нигезендә билгеләнә.

6.6.2. Гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре тарафыннан

башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләме, тәртибе һәм шартлары гомуми белем бирү оешмасының локаль норматив актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

6.6.3. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр ($B_{kj}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{k_j} = \frac{FOT_k}{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m}\left(I_{ij} \times K_i\right)} \times \sum_{i=1}^{n}\left(I_{ij} \times K_i\right),$$

биредә:

$FOT_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүгә каралган хезмәткә түләү фонды;

$I_{ij}$ – j-нче хезмәткәр буенча эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i-нче критерие;

$K_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең i-нче критериясенең чагыштырма үләчмле коэффициенты;

n – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

m – гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләре саны.

6.6.4. Эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийларын нормалаштыру төрле зурлыктагы нәтиҗәлелек критерийларын чагыштыруны тәэмин итә. Нормалаштыру эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критерие (иң яхшысы һәм иң начары) күрсәткечләренең диапазонын сайлаудан гыйбарәт, шуларның берсе – нульгә тигезләнгән критериягә, икенчесе бердәй күрсәткечкә туры килә. Чын мәгънәсе булганда эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критерие күрсәткечләре диапазоны чикләрендә нәтиҗәлелек критерие ачыкланганда эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерие нульдән алып берәмлекләргә кадәр билгеләнә. Нәтиҗәлелек критерие иң начар күрсәткечтән түбәнрәк булган фактик әһәмияткә ия булганда, норматив критерийның әһәмияте тигез нульгә тигез була, иң яхшыдан югары булса – бергә.

6.6.5. Эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген билгеләүдән чыгып, нормальләшкән критерий эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген билгеләүдән туры булырга мөмкин (уңай динамика критерийның мәгънәсен арттырып билгеләнә) һәм киресенчә (уңай динамика критерийның мәгънәсен киметеп билгеләнә).

6.6.6. Нормалаштырылган критерий, аның әһәмияте критерий кыйммәтенә турыдан-туры бәйле булганда ($I_i$), түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

биредә:

$FI_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериеның фактик әһәмияте;

$M_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериеның иң яхшы билгесе;

$L_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериеның иң начар билгесе.

6.6.7. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие ($I_i$), аның мәгънәсе критерий мәгънәсенә кире юнәлештә бәйле булганда, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = 1 - \frac{FI_i - L_i}{L_i - M_i},$$

биредә:

$FI_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериеның фактик әһәмияте;

$M_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериеның иң яхшы билгесе;

$L_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериеның иң начар билгесе.

6.6.8. Үлчәм коэффициентлары белән эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның өстенлеклек дәрәҗәсе билгеләнә. Иң өстенлекле критерийга иң зур коэффициент бирелә. Чагыштырма үлчәм коэффициенты ($K_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_i = \frac{VK_i}{\sum_{i=1}^{n} VK_i},$$

биредә:

$VK_i$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең i-нче критериясенең чагыштырма үләчмле коэффициенты.

6.6.9. Гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының гомуми иң чик күләме 9-11 таблицаларда китерелгән.

9 нчы таблица

**Мәгариф хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1 | Вожатый | 5 |
| 1.2 | Тәрбияче ярдәмчесе | 5 |
| 1.3 | Укыту бүлеге секретаре | 5 |
| 2. Икенче дәрәҗә ярдәмче персонал вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1 | Режим буенча дежур торучы | 35 |
| 2.2 | Кече тәрбияче | 35 |
| 2.3 | Мәгариф оешмасы диспетчеры | 40 |
| 2.4 | Режим буенча өлкән дежур торучы | 40 |
| 3. Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 3.1 | Хезмәт буенча инструктор | 45 |
| 3.2 | Физик культура инструкторы | 45 |
| 3.3 | Музыка җитәкчесе | 45 |
| 3.4 | Өлкән вожатый | 45 |
| 3.5 | Инструктор-методист | 50 |
| 3.6 | Концертмейстер | 50 |
| 3.7 | Өстәмә белем бирү педагогы | 50 |
| 3.8 | Педагог-оештыручы | 50 |
| 3.9 | Социаль педагог | 50 |
| 3.10 | Тренер-укытучы | 50 |
| 3.11 | Тәрбияче | 55 |
| 3.12 | Производствода укыту мастеры | 55 |
| 3.13 | Методист | 55 |
| 3.14 | Педагог-психолог | 55 |
| 3.15 | Өлкән инструктор-методист | 55 |
| 3.16 | Өстәмә белем бирүнең өлкән педагогы | 55 |
| 3.17 | Өлкән тренер-укытучы | 55 |
| 3.18 | Укытучы (профессор-укытучылар составына кертелгән укытучылар вазыйфаларыннан тыш) | 60 |
| 3.19 | Тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләрен укытучы-оештыручы | 60 |
| 3.20 | Физик тәрбия җитәкчесе | 60 |
| 3.21 | Өлкән тәрбияче | 60 |
| 3.22 | Өлкән методист | 60 |
| 3.23 | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | 60 |
| 3.24 | Укытучы | 60 |

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 3.25 | Укытучы-дефектолог | 60 |
| 3.26 | Укытучы-логопед (логопед) | 60 |
| 3.27 | Педагог-китапханәче | 60 |
| 4. Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 4.1 | Гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы): кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, уку (уку-җитештерү) остаханәсе һәм башка структур бүлекчәләр (икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | 65 |
| 4.2 | Белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы), башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү оешмасының кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (җитештерү) остаханәсе, укыту хуҗалыгы һәм (бүлекчә) башка структур бүлекчәләре башлыгы (мөдире, директоры, җитәкчесе, идарәчесе) (өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | 70 |

10 нчы таблица

**Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. Урта буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1 | Аккомпаниатор | 35 |
| 1.2 | Культорганизатор | 35 |
| 2. Әйдәп баручы буын мәдәният хезмәткәрләре | | |

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1 | Китапханәче | 40 |
| 2.2 | Тавыш операторы | 40 |
| 2.3 | Әйдәп баручы китапханәче | 42 |
| 2.4 | Рәссам-бизәүче | 45 |
| 2.5 | Баш китапханәче | 45 |
| 3. Мәдәният оешмасы җитәкче составы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 3.1 | Музейның бүлек (сектор) мөдире | 50 |
| 3.2 | Китапханәнең бүлек (сектор) мөдире | 50 |

11 нче таблица

**Медицина хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының гомуми иң чик күләме**

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. Беренче дәрәҗәдә медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1 | Авыруларны карау буенча кече шәфкать туташы (авыруларны карау буенча кече ир-ат шәфкать туташы) | 5 |
| 2. Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.1 | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 35 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.2 | Диета буенча шәфкать туташы (диета буенча ир-ат шәфкать туташы) | 37 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.3 | Шәфкать туташы | 40 |
| 2.4 | Физиотерапия буенча шәфкать туташы (физиотерапия буенча ир-ат шәфкать туташы) | 40 |
| 2.5 | Массаж буенча шәфкать туташы | 40 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.6 | Фельдшер | 45 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.7 | Өлкән шәфкать туташы | 50 |

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Үлчәм коэффициентларының чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 2.8 | Сәламәтлек пункты мөдире-фельдшер (шәфкать туташы [ир-ат шәфкать туташы]) | 50 |
| 3. Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 3.1 | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиблардан тыш) | 60 |

6.6.10. Гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең бер төр критерийлары, аларның үлчәм коэффициентлары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан раслана.

6.6.11. Гомуми белем бирү оешмасында башкарылган эшләрнең сыйфаты, күләме өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр фонды төзелә ($FOT_k$), аның күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_k = FOT_{do} \times \frac{D_k}{100\%},$$

биредә:

$FOT_{do}$ – төп эш урыны буенча хезмәткәрләрнең (укытучылар һәм укытучылар вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) вазыйфаи окладлары буенча гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләре хезмәтенә түләү фонды;

$D_k$ – башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелә торган хезмәткә түләү фонды күләме.

Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләргә хезмәткә түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме 16 процент күләмендә кабул ителә.

## VII. Компенсация характерындагы түләүләр

7.1. Гомуми белем бирү оешмаларында компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр;

- нормаль шартлардан читләшкән шартларда (төрле квалификация, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә), артык хезмәт башкарганда, төнлә

эшләгәндә һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда) эшләр башкарган өчен компенсация характерындагы түләүләр;

- педагогик хезмәткәрләргә өстәмә эш төрләре өчен компенсация характерындагы түләүләр;

- тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр;

- аерым гомуми белем бирү оешмаларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә эшләгән өчен (сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен гомуми белем бирү оешмаларында) компенсация характерындагы түләүләр;

- белем бирү программасы үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләр.

Аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, локаль норматив актлар, хезмәт шартнамәсе белән билгеләнә торган компенсация характерындагы түләүләр.

7.2. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = \left( O_b \times \frac{H_{fk}}{H_N} + P \right) \times \frac{D_{kh}}{100\%},$$

биредә:

$O_b$ – гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп окладлары күләме;

$H_{fk}$ – законнарда компенсация характерындагы түләү каралган фактта эшләнгән вакыт, сәгатьләрдә;

$H_N$ – гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә хезмәт хакы ставкасы өчен билгеләнгән сәгатьләр нормасы;

Р – китап нәшрияты продукциясе һәм вакытлы матбугат белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация педагогик хезмәткәрләргә укыту йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмый;

$D_{kh}$ – Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә торган зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләү өчен өстәмә күләме.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче

хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү, нормаль хезмәт шартлары булган төрле эш төрләре өчен билгеләнгән хезмәт өчен түләү белән чагыштырганда, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә арттырып билгеләнә.

Озак вакыт дәвалануга мохтаҗ, туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә турыдан-туры катнашкан һәм шөгыльләре туберкулез микобактерияләре йоктыру куркынычы белән бәйле балалар өчен шифаханә тибындагы дәүләт сәламәтләндерү гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләүгә зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары белән эшләгән өчен 25 процент күләмендә өстәмә билгеләнә.

7.3. Нормаль шартлардан читкә тайпылучы шартларда эшләгән өчен (төрле квалификацияле эшләр башкарганда, һөнәрләр (вазыйфалар) берләштергәндә, эштән тыш эшләгәндә, төнге вакытта эшләгәндә һәм нормаль шартлардан читкә тайпылучы башка шартларда эшләгәндә) компенсация характерындагы түләүләр төнге вакытта эшләгән һәр сәгать өчен нормаль шартлардагы эш белән чагыштырганда югарырак күләмдә, әмма законнарда һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән күләмнәрдән ким булмаган күләмдә билгеләнә.

Хезмәткәр үзенә билгеләнгән ял көнендә яисә эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшкә җәлеп ителгән очракта, эш өчен кимендә икеләтә күләмдә түләнә, шул ук вакытта вазыйфаи оклад алучы хезмәткәрләргә, әгәр ял һәм эш көне булмаган бәйрәм көнендә эш эш вакытының айлык нормасы чикләрендә башкарылса, окладтан тыш бер көнлек яки сәгатьлек төп ставка күләмендә һәм кимендә икеләтә күләмдә түләнә, әгәр эш айлык нормадан артык башкарылган булса, төп окладның кимендә ике сәгатьлек яки көнлек ставкасына арттырылган күләмдә түләнә.

Ял көнендә яки эшләми торган бәйрәм көнендә эшләгән хезмәткәр теләге белән аңа икенче ял көне бирелергә мөмкин. Бу очракта эш көне булмаган бәйрәм көнендә бер мәртәбә түләнә, ә ял көне өчен түләү түләнми.

7.4. Педагогик хезмәткәрләргә өстәмә эш төрләре өчен компенсация характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- гомуми белем бирүне оештыру һәм укучылар белән тәрбия эшен координацияләү буенча сыйныф җитәкчесе функцияләрен гамәлгә ашырган өчен компенсация характерындагы түләүләр;

- язма эшләрне (дәфтәрләрне) тикшергән өчен компенсация характерындагы түләүләр;

- уку кабинетлары, укыту остаханәләре, спорт заллары, лабораторияләр, укыту-тәҗрибә участоклары, музейлар белән идарә иткән өчен компенсация

түләүләре;

- предмет, методик яисә цикл комиссиясе, методик берләшмәләр белән җитәкчелек иткән өчен компенсация характерындагы түләүләр.

7.4.1. Гомуми белем бирүне оештыру һәм укучылар белән тәрбия эшен координацияләү буенча сыйныф җитәкчесе функцияләрен гамәлгә ашырган өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{nz}^{kr}$) уку елы башына елга бер тапкыр билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{nz}^{kr} = A + K_r \times Y_k ,$$

биредә:

А – гомуми белем бирүне оештыру һәм укучылар белән тәрбия эшен координацияләү буенча сыйныф җитәкчесе функцияләрен гамәлгә ашырган өчен түләүләрнең даими өлеше;

$K_r$ – гомуми белем бирүне оештыру һәм укучылар белән тәрбия эшен координацияләү буенча сыйныф җитәкчесе функцияләрен гамәлгә ашырган өчен түләүләрнең үзгәрүчән өлеше;

$Y_k$ – сыйныфта укучылар саны.

Гомуми белем бирү оешмасы һәм укучылар белән тәрбия эшен координацияләү буенча сыйныф җитәкчесе функцияләрен башкарган өчен түләүләрнең даими өлеше айга – 550 сум, күрсәтелгән функцияләрне башкарган өчен түләүләрнең үзгәрүчән өлеше айга 80 сум тәшкил итә.

7.4.2. Язма эшләрне тикшергән өчен (дәфтәрләрне тикшергән өчен) компенсация характерындагы түләүләр ( $B_{nz}^{pt}$ ) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{nz}^{pt} = \left( \sum O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P \right) \times \frac{D_{pt}}{100\%} ,$$

биредә:

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган гомумбелем бирү оешмасының педагогик хезмәткәренең төп оклады күләме;

$H_f$ – гомуми белем бирү оешмасында фән буенча педагогик эш алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

$Y_f$ – гомуми белем бирү оешмасында педагогик хезмәткәр башкара торган күләм күрсәткечләренең факттагы саны;

$H_N$ – әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең эш хакы ставкасы өчен сәгатьләр нормасы;

$Y_N$ – гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәре башкара торган күләм күрсәткечләренең норматив саны;

Китап нәшрияты продукциясе һәм вакытлы матбугат белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмый;

$D_{pt}$ – язма эшләрне тикшергән өчен (дәфтәрләрне тикшергән өчен) өстәмә күләме, ул 12 нче таблицада китерелгән.

Педагогик хезмәткәр төрле сыйныфларда һәм төрле фәннәр буенча язма эшләрне тикшергәндә язма эшләрне (дәфтәрләрне) тикшергән өчен түләүләр күләме һәр фән һәм сыйныф буенча түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

12 нче таблица

**Гомуми белем бирү оешмаларында язма эшләрне (дәфтәрләрне) тикшергән өчен өстәмә түләүләр күләмнәре**

| № т/б | Эшнең исеме | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | Башлангыч сыйныфларда, рус теле һәм әдәбияты, туган тел һәм әдәбият, математика буенча дәфтәрләрне тикшерү | 12,0 |
| 2 | Чит тел буенча язма эшләрне тикшерү | 7,0 |
| 3 | Информатика, җәмгыять белеме, биология, химия, физика, география буенча язма эшләрне тикшерү | 3,6 |

7.4.3. Гомуми белем бирү оешмаларында уку кабинетлары, укыту остаханәләре, спорт заллары, лабораторияләр, укыту-тәҗрибә участоклары, музейлар белән җитәкчелек иткән өчен компенсация характерындагы түләү:

- уку кабинетлары, лабораторияләр, музейлар мөдирлеге өчен – 444 сум;
- укыту остаханәләре, спорт заллары һәм укыту-тәҗрибә участоклары белән җитәкчелек иткән өчен – 833 сум.

Кабинетлар һәм укыту остаханәләре, спорт заллары, лабораторияләр белән мөдирлек итү булган укыту-методик, дидактик һәм күрсәтмә материалның белем бирү процессын җиһазландыруга карата расланган таләпләрнең 50 проценттан да ким булмау шарты белән уку кабинеты паспорты таләпләренә туры килү дәрәҗәсе нигезендә билгеләнә.

Педагогик хезмәткәр берничә уку кабинеты, укыту остаханәләре, спорт

заллары, лабораторияләр, укыту-тәҗрибә участоклары, музейлар эшен тәэмин иткәндә, әлеге эшне тәэмин итү өчен түләүләр күләме һәр уку кабинеты, укыту остаханәсе, спорт залы, лаборатория, укыту-тәҗрибә участогы, музей буенча түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

7.4.4. Предмет, методик яисә цикл комиссияләренә, методик берләшмәләргә җитәкчелек иткән өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{nz}^{rk}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{nz}^{rk} = O_b \times \frac{D_{rk}}{100\%},$$

биредә:

$O_b$ – гомуми белем бирү оешмалары педагогик хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп оклады күләме;

$D_{rk}$ – предмет, методик яисә цикл комиссияләре, методик берләшмәләр белән җитәкчелек иткән өчен өстәмә күләме 3 процент тәшкил итә.

Педагогик хезмәткәр җитәкчелекне берничә комиссия, берләшмәләр белән тәэмин иткәндә, күрсәтелгән очракта түләүләр күләме һәр комиссия, берләшмә буенча түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

7.5. Аерым мәгариф оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренә тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр бирелә.

7.5.1. Хезмәт хакы ставкасы өчен атнага педагогик эш сәгатьләре нормалары билгеләнгән педагогик хезмәткәрләргә тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = \left( O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P \right) \times \frac{D_{kh}}{100\%},$$

биредә:

$O_b$ – гомуми белем бирү оешмалары педагогик хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп окладты күләме;

$H_f$ – гомуми белем бирү оешмаларында педагогик эш алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

$Y_f$ – гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре башкара торган күләм күрсәткечләренең факттагы саны;

$H_N$ – әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән гомуми белем бирү

оешмалары хезмәткәрләренең эш хакы ставкасы өчен сәгатьләр нормасы;

$Y_N$ – гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре башкара торган күләм күрсәткечләренең норматив саны;

Р – китап нәшрияты продукциясе һәм вакытлы матбугат белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация педагогик хезмәткәрләргә укыту йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмый;

$D_{kh}$ – тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр күләме, ул 13 нче таблицада китерелгән.

7.5.2. Мәгариф хезмәткәрләре өчен (түләүләре әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында билгеләнгән педагогик хезмәткәрләрдән тыш) тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_d \times \frac{D_{kh}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kh}$ – 13 нче таблицада китерелгән компенсация характерындагы күләме.

Гомуми белем бирү оешмаларының педагогик һәм укыту-ярдәмче хезмәткәрләре билгеле бер категориядәге тәрбияләнүчеләр белән эшләгәндә компенсация характерындагы түләүләрне берничә нигез буенча бирү карала, түләүләр күләме һәр нигез буенча исәпләнә.

Әлеге гомуми белем бирү оешмасында, бүлекчәдә һәм вазыйфада эшләүнең конкрет шартларын исәпкә алып компенсация характерындагы өстәмәләр билгеләнә торган хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеге, сайланулы профсоюз органы яисә хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтле башка орган белән килештереп, һәр гомуми белем бирү оешмасында раслана.

13 нче таблица

**Тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен түләү күләмнәре**

| № т/б | Түләүне билгеләү нигезе | Түләүләр билгеләнә торган вазыйфалар | Түләү күләме, |
|---|---|---|---|

| | | **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Квалификация дәрәҗәсе** | **процент** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән психик үсеше тоткарланган) укучылар (тәрбияләнүчеләр) өчен гомуми белем бирү оешмаларында (бүлекләрдә, сыйныфларда, төркемнәрдә) эшләү | Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче | 5,5 |
| | | Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче-икенче | 5,5 |
| | | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче-дүртенче | 5,5 |
| | | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-икенче | 5,5 |
| 2 | Озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә-белем бирү оешмаларында (классларда, төркемнәрдә) эшләү | Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче | 7,3 |
| | | Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче-икенче | 7,3 |
| | | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче-дүртенче | 7,3 |
| | | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-икенче | 7,3 |
| 3 | Девиант тәртипле укучылар өчен махсус укыту-тәрбия оешмаларында эшләү | Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче-икенче | 55,0 |
| | | Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче-икенче | 55,0 |
| | | Педагогик хезмәткәрләр | Беренче-дүртенче | 55,0 |

| № т/б | Түләүне билгеләү нигезе | Түләүләр билгеләнә торган вазыйфалар | | Түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|---|
| | | **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Квалификация дәрәҗәсе** | |
| | | вазыйфалары | | |
| | | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-икенче | 55,0 |
| 4 | Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән психик үсешләрендә тоткарлык булган) укучылар (тәрбияләнүчеләр) өчен интернаты булган гомуми белем бирү оешмаларында, махсус (коррекцион) бүлекчәләрдә, сыйныфларда, төркемнәрдә эшләү | Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче | 7,0 |
| | | Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче-икенче | 7,0 |
| | | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче-дүртенче | 7,0 |
| | | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-икенче | 7,0 |
| 5 | Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен гомуми белем бирү оешмаларында эшләү | Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче | 12,0 |
| | | Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче-икенче | 12,0 |
| | | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче-дүртенче | 23,5 |
| | | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-икенче | 12,0 |
| 6 | Иректән мәхрүм итү рәвешендәге җинаять җәзаларын | Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал | Беренче-икенче | 55,0 |

| № т/б | Түләүне билгеләү нигезе | Түләүләр билгеләнә торган вазыйфалар | | Түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|---|
| | | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | |
| | үтәүче оешмалар каршындагы гомуми белем бирү оешмаларында эшләү | вазыйфалары | | |
| | | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче-дүртенче | 55,0 |
| | | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-икенче | 55,0 |
| 7 | Җинаять җәзасын иректән мәхрүм итү рәвешендәге, укучы, туберкулезның актив формасы белән авыручы оешмалар карамагындагы гомуми белем бирү оешмаларында эшләү | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче-дүртенче | 60,0 |
| | | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-икенче | 60,0 |
| 8 | Сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән балаларны өйдә индивидуаль укыту (медицина бәяләмәсе нигезендә) | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Дүртенче | 7,0 |
| 9 | Ишетү, күрү буенча мөмкинлекләре чикләнгән, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган, психик үсеше тоткарланган, аутистик үсеше бозылган, катлаулы кимчелекләре булган һәм акыл ягыннан артта калган балалар өчен җайлаштырылган | Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче | 5,5 |
| | | Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче-икенче | 5,5 |
| | | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче-дүртенче | 5,5 |

| № т/б | Түләүне билгеләү нигезе | Түләүләр билгеләнә торган вазыйфалар | | Түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|---|
| | | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | |
| | белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә төркемнәрдә эшләү | | | |
| 10 | Сөйләме нык бозылган тәрбияләнүчеләр өчен җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә төркемнәрдә эшләү | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Өченче | 4,0 |
| 11 | Стационар дәвалау оешмасында озак дәваланудагы балаларга индивидуаль һәм төркемле укытуны гамәлгә ашыру | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Дүртенче | 4,0 |
| 12 | Үсешләрендә тайпылышлары булган укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында эшләү | Әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | - | 4,5 |
| 13 | Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче-дүртенче | 28,0 |
| | | Структур бүлекчәләр | Беренче-икенче | 28,0 |

| №<br>т/б | Түләүне билгеләү нигезе | Түләүләр билгеләнә торган вазыйфалар | | Түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|---|
| | | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | |
| | ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында эшләү | җитәкчеләре вазыйфалары | | |

7.6. Аерым гомуми белем бирү оешмаларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә эшләгән өчен (сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен гомуми белем бирү оешмаларында) компенсация характерындагы түләүләр ($B_{\text{khm}}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{khm} = O_d \times \frac{D_{khm}}{100\%},$$

биредә:

$O_{\text{d}}$ – медицина хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{\text{khm}}$ – медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәгариф оешмаларында эшләгәнгә компенсация характерындагы түләү күләме, ул 15 процентка тигез.

7.7. Белем бирү программасы үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләр гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә бирелә.

7.7.1. Белем бирү программасы үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләр гомуми белем бирү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренә тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен бирелә.

7.7.2. Эш хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш сәгатьләре нормалары билгеләнгән педагогик хезмәткәрләр өчен белем бирү программасы үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{\text{sop}}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sop} = \left( O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P \right) \times \frac{D_{sop}}{100\%}$$
,

биредә:

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәрләренең төп оклады күләме;

$H_f$ – гомуми белем бирү оешмасының педагогик эшен алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

$Y_f$ – гомуми белем бирү оешмасының мәгариф хезмәткәрләре күрсәтә торган хезмәтләрнең факттагы саны;

$H_N$ – гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә хезмәт хакы ставкасы өчен билгеләнгән сәгатьләр нормасы;

$Y_N$ – гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәрләре күрсәтә торган хезмәтләрнең норматив саны;

Р – китап нәшрияты продукциясе һәм вакытлы матбугат белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация, ул педагогик хезмәткәрләргә укыту йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмый;

$D_{sop}$ – белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмә күләме, ул 14 нче таблицада китерелгән.

7.7.3. Мәгариф хезмәткәрләре өчен белем бирү программасы үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләр (түләүләре әлеге Нигезләмәнең 7.7.2 пунктында билгеләнгән педагогик хезмәткәрләрдән тыш) ($B_{sop}$) һәм алар түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sop} = O_d \times \frac{D_{sop}}{100\%}$$
,

биредә:

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sop}$ – белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмә күләме, ул 14 нче таблицада китерелгән.

7.7.4. Педагогик һәм укыту-ярдәмче хезмәткәрләр укучыларның (тәрбияләнүчеләрнең) аерым категорияләре булган мәгариф оешмаларында эшләгәндә белем бирү программасы үзенчәлеге өчен берничә нигез буенча түләүләр бирү күздә тотыла. Бу очракта белем бирү программасы үзенчәлеге өчен түләүләр күләме һәр нигез буенча исәпләнә.

7.7.5. Әлеге гомуми белем бирү оешмасында, бүлекчәдә һәм вазыйфада эшләүнең конкрет шартларын исәпкә алып, белем бирү программасы

үзенчәлегенә өстәмәләр билгеләнә торган хезмәткәрләрнең вазыйфалары исемлеге, сайланулы профсоюз органы яисә хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтле башка орган белән килештереп, һәр гомуми белем бирү оешмасында раслана.

14 нче таблица

**Белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмәләрнең күләмнәре**

| № т/б | Белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмә билгеләү нигезе | Белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган вазыйфалар | | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|---|---|
| | | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | |
| 1 | Интернаты булган гомуми белем бирү оешмаларында эшләү | Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче | 5,5 |
| | | Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче-икенче | 5,5 |
| | | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче-дүртенче | 5,5 |
| | | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-икенче | 5,5 |
| 2 | Лицей, гимназия сыйныфларында эшләү | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Дүртенче | 5,5 |
| | | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-икенче | 5,5 |
| 3 | Психологик-педагогик һәм медицина-педагогик комиссияләрдә, логопед пунктларында эшләү | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Икенче-дүртенче | 4,0 |
| 4 | Авыл җирендә һәм | Педагогик | Дүртенче | 5,0 |

| № т/б | Белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмә билгеләү нигезе | Белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган вазыйфалар | | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|---|---|
| | | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | |
| | шәһәр тибындагы бистәләрдә урнашкан, укыту рус телендә булмаган гомуми белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныфларда рус телен һәм 5-11 сыйныфларда рус әдәбияты укыту | хезмәткәрләр вазыйфалары | | |
| | | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-икенче | 5,0 |
| 5 | Авыл җирлегендә һәм шәһәр тибындагы бистәләрдә урнашкан рус телендә укытылмый торган мәктәпкәчә төркемнәрдә балаларга рус телен өйрәтү | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Өченче-дүртенче | 5,0 |
| 6 | Рус телендә белем бирүче гомуми белем бирү оешмаларында туган телне (татар, чуаш, мари һ.б. телләрне, рус теленнән тыш) һәм әдәбиятны укыту | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Дүртенче | 5,0 |
| | | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче | 5,0 |
| 7 | Рус телле мәктәпкәчә төркемнәрдә балаларга туган телен (татар, чуаш, мари һ.б.) укыту | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Өченче-дүртенче | 5,0 |
| 8 | Чит телне чит телне тирәнтен өйрәтүче гомуми белем бирү | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Дүртенче | 5,5 |

| № т/б | Белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмә билгеләү нигезе | Белем бирү программасы үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган вазыйфалар | | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|---|---|
| | | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | |
| | оешмаларында практик эштә куллану | Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-икенче | 5,5 |
| 9 | Гомуми белем бирү оешмаларында һәм мәктәпара уку комбинатларында эшләү | Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча өстәмә белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче | 14,0 |
| | | | Икенче | 16,0 |
| | | | Өченче | 18,0 |
| 10 | «Кадет корпусы» статусына ия гомуми белем бирү оешмаларында эшләү | Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче-дүртенче | 20,0 |

7.7.6. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләр мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасының җитәкче составы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә ($B_{\text{sd}}$) һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%},$$

биредә:

$O_{\text{d}}$ – гомуми белем бирү оешмаларының мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{\text{sd}}$ – эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә күләме, 9 процентка тигез дип кабул ителә.

7.7.7. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләр аерым гомуми белем бирү оешмаларында медицина һәм фармацевтика

хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә ($B_{sd}$) һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%}$$,

биредә:

$O_d$ – гомуми белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sd}$ – эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә күләме, ул 15 нче таблицада китерелгән.

7.7.8. Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазыйфада эшләүнең конкрет шартларын исәпкә алып, эшчәнлек үзенчәлегенә өстәмәләр билгеләнә торган хезмәткәрләрнең вазыйфалары исемлеге, сайланулы профсоюз органы яисә хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтле башка орган белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан расланa.

15 нче таблица

**Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләмнәре**

| Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү билгеләүгә нигез | Һөнәри квалификация төркеме исеме | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| Мәгариф оешмаларында эшләү | Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 17,0 |
| | Табиблар һәм провизорлар | 10,0 |

## VIII. Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең, оешма җитәкчесе урынбасарының, баш инженерның һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесенең хезмәт хакын билгеләү тәртибе

8.1. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш инженерларның хезмәт хакы вазыйфаи окладлардан, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрдән гыйбарәт.

8.2. Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең вазыйфаи оклады гамәлгә куючы тарафыннан, хезмәт өчен түләү төркеменә карап, уку елы башына елга бер тапкыр билгеләнә ($O_d$) һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_N},$$

биредә:

$O_b$ – җитәкченең төп окладының күләме;

$H_f$ – гомуми белем бирү оешмаларында эш сәгатьләренең факттагы саны;

$H_N$ – әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең эш хакы ставкасы өчен сәгатьләр нормасы.

Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең хезмәте өчен түләү төркеме укучылар санына карап билгеләнә.

8.3. Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш инженерларының вазыйфаи окладлары әлеге гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20-30 процентка түбәнрәк.

8.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе (гамәлгә куючы) гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә, аларның эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр билгели. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе боерыгы нигезендә билгеләнә. Сыйфат өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен түләнә.

Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә премия түләүләре ай саен, квартал, ел өчен эш йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен башкарылырга мөмкин. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә премия түләүләре Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе боерыгы нигезендә билгеләнә.

Финанс яктан тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына төзелә торган һәм календарь ел өчен исәпләнә торган мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы һәм мондый оешмалар хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакы (тиешле җитәкченең, аның урынбасарларының, баш бухгалтерның хезмәт хакын исәпкә алмыйча) нисбәтенең иң чик дәрәҗәсе өч тапкыр күләмендә билгеләнә.

Мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының календарь елда исәпләнә торган уртача айлык хезмәт хакы турындагы мәгълүмат Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе битләрендә урнаштырыла.

Урнаштырылырга тиешле мәгълүмат составында шул исәптән

учреждениенең тулы исеме, җитәкченең биләгән вазыйфасы, шулай ук фамилиясе, исеме һәм атасының исеме күрсәтелә.

Урнаштырыла торган мәгълүмат составында күрсәтелгән затларның яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка индивидуаль коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган белешмәләрне, шулай ук дәүләт серенә яисә конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән белешмәләрне күрсәтү тыела.

Мәгълүматны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында урнаштыру (www.kzn.ru) Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе тарафыннан «Бухгалтерлык хезмәте күрсәтү үзәге» МКУ биргән белешмәләр нигезендә хисап елыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр гамәлгә ашырыла.

8.5. Җитәкчеләр хезмәтенә түләү төркеме, гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен төп окладлар һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләме 16 нчы таблицада күрсәтелгән.

16 нчы таблица

**Җитәкчеләр хезмәтенә түләү төркеме, гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен төп окладлар һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәре**

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү төркеме | Күләм күрсәткеченең әһәмияте (уку елы башына укучылар, тәрбияләнүчеләр саны), кеше * | Төп оклад, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 1-15 | 28000 | 4000 |
| 2 | 16-50 | 30000 | 4000 |
| 3 | 51-100 | 34000 | 5000 |
| 4 | 101-200 | 35000 | 7000 |
| 5 | 201-400 | 38000 | 10000 |
| 6 | 401-600 | 40000 | 10000 |
| 7 | 601-800 | 43000 | 10000 |
| 8 | 801-1000 | 46000 | 10000 |
| 9 | 1001-1200 | 47000 | 12000 |
| 10 | 1201-1400 | 48000 | 13000 |
| 11 | 1401-1800 | 48000 | 16000 |
| 12 | 1801 һәм аннан күбрәк | 49000 | 19000 |

* Ябык типтагы үз-үзен девиант тотучы укучылар өчен гомуми белем бирү оешмасының, җинаять-үтәтү системасының төзәтү учреждениеләре каршындагы гомуми белем бирү оешмаларының, озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы гомуми белем бирү оешмаларының, җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларының укучылар контингенты 3 коэффициент белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда яшәүче укучылар контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмаларының мәктәпкәчә төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр контингенты 1,5 коэффициенты белән исәпкә алына.

Мәктәпара уку комбинатларында укучылар контингенты 0,5 коэффициенты белән исәпкә алына.

8.6. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе урынбасарларына, баш инженерына кызыксындыру характерындагы түләүләр, аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен җитәкче урынбасарларына, баш инженерга кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, еллык эш йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен башкарылырга мөмкин. Җитәкче урынбасарларына, баш инженерга кызыксындыру характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең кызыксындыру характерындагы түләүләренең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.

8.7. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре, җитәкчеләр урынбасарлары һәм баш бухгалтерлары эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең бер төр критерийлары һәм аларның үлчәм коэффициентлары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан раслана.

8.8. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр ($B_k$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_C \times K_{VK},$$

биредә:

$B_C$ – кызыксындыру характерындагы түләүләр күләме, ул әлеге Нигезләмәнең 16 нчы таблицасында китерелгән;

$K_{VK}$ – сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

8.9. Компенсация характерындагы түләүләр оешма җитәкчесе, аның урынбасарлары, гомумбелем бирү оешмасының баш инженеры өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

8.10. Тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек

буенча директор киңәшчесенең вазыйфаи окладары ( $O_{b_s}$ ) ) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_{d_s} = O_{b_s} \times \frac{H_f}{H_N},$$

биредә:

$O_{b_s}$ - тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесенең төп окладының күләме 21000 сум итеп билгеләнә;

$H_f$ – гомуми белем бирү оешмаларында эш сәгатьләренең факттагы саны;

$H_N$ – әлеге Нигезләмәнең III бүлеге белән билгеләнгән гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең эш хакы ставкасы өчен сәгатьләр нормасы.

8.11. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесенә бирелә ( $B_{sr_s}$ ) һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr_s} = O_{d_s} \times \frac{D_{sr_s}}{100\%},$$

биредә:

$O_{d_s}$ – тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесенең вазыйфаи окладары күләме;

$D_{sr_s}$ – тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесенең хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә күләме 100 процентка тигез дип кабул ителә.

8.12. Компенсация характерындагы түләүләр тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчесе өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы белән билгеләнә.

## IX. Гомуми белем бирү оешмасының хезмәткә түләү фондын булдыру һәм аннан файдалану тәртибе

9.1. Гомуми белем бирү оешмасының хезмәткә түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына гомуми белем бирү оешмасының нормативлар, күләм күрсәткечләре саны нигезендә билгеләнгән акчалары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм гомуми белем бирү оешмасының

финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

9.2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны исәпләү, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренә (эшче, эшче мәдәният, сәнгать һәм кинематография гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләрен дә кертеп) агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә гомуми белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган акчалар хисабына башкарыла.

9.3. Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, гомуми белем бирү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабыннан (сыйныфлар, укучылар санын киметүдән, уку программаларын үзгәртүдән, учреждениене контроль органнары күрсәтмәләре буенча капиталь ремонтка ябудан тыш) барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләү тиешле чорда (елда) гомуми белем бирү оешмасының әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлар нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелә ала.

Хезмәт өчен түләү фонды экономиясе булганда, кызыксындыру түләүләре алар буенча хезмәт өчен түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә (эшче, эшче мәдәният, сәнгать һәм кинематография гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен дә кертеп).

Хезмәт өчен түләү фондын тиешле чорда экономияләү хисабына башкарылган кызыксындыру түләвенең күләме, шул чорда хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәренә тиешле чорда башкарылган хезмәт өчен түләүнең агымдагы елның 1 гыйнварына 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән өч тапкырга арта алмый (педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәрен биләгән хезмәткәрләрдән, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесеннән тыш).

Хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә кызыксындыру түләвенең күләме гомуми белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Гомуми белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабыннан,

түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәткә түләү фонды экономиясеннән файдалану өчен җаваплылык гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.

Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә 1 номерлы кушымта

**Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исем һәм ведомство бүләге исеме |
|---|---|
| Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикалар дәүләт бүләкләре | |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Халык укытучысы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Атказанган укытучысы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең Атказанган фән эшлеклесе |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган җитештерү белеме бирү мастеры |
| 1.6 | Россия Федерациясенең Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.7 | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.8 | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 1.9 | Россия Федерациясенең Атказанган икътисадчысы |
| 2. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | СССР Халык укытучысы |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 3.2 | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 3.3 | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 3.4 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 3.5 | РСФСР Атказанган тренеры |
| 3.6 | РСФСР Атказанган мәктәп укытучысы |
| 3.7 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 3.8 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 3.9 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 3.10 | Атказанган укытучы |
| 3.11 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 3.12 | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 3.13 | Атказанган югары мәктәп эшлеклесе |
| 3.14 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |

| № т/б | **Мактаулы исем һәм ведомство бүләге исеме** |
|---|---|
| 3.15 | Атказанган фән эшлеклесе |
| | 3. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикаларның мактаулы исемнәре |
| 4.1 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.3 | Атказанган мәктәп эшлеклесе |
| 4.4 | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 4.5 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 4.6 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 4.7 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 4.8 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 4.9 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 4.10 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.11 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.12 | Атказанган фән эшлеклесе |
| | 5. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре |
| 5.1 | Татарстан Республикасының Халык укытучысы |
| 5.2 | Татарстан Республикасының Атказанган мәктәп укытучысы |
| 5.3 | Татарстан Республикасы Атказанган укытучысы |
| 5.4 | Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе |
| 5.5 | Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 5.6 | Татарстан Республикасының Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 5.7 | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.8 | Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы |
| | Алар булган өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының (Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы) ведомство (тармак) бүләкләре |
| | 1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) |
| 1.1 | Россия Федерациясе гомуми мәгарифенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.2 | Россия Федерациясе башлангыч һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.3 | Россия Федерациясе урта һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.4 | Россия Федерациясе югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясе фән һәм техника мактаулы хезмәткәре |
| 1.6 | Россия Федерациясе яшьләр сәясәте өлкәсендә мактаулы хезмәткәре |
| 1.7 | «Студентларның фәнни-тикшеренү эшен үстергән өчен» күкрәк билгесе |
| 1.8 | Россия Федерациясе мәгариф өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.9 | Россия Федерациясе балалар һәм яшьләр тәрбиясе өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.10 | «Мәгариф отличнигы» аерымлык билгесе |

| № т/б | Мактаулы исем һәм ведомство бүләге исеме |
|---|---|
| 1.11 | Россия Федерациясе тәрбия һәм мәгарифнең мактаулы хезмәткәре |
| 1.12 | Россия Федерациясе фән һәм югары технологияләр мактаулы хезмәткәре |
| 1.13 | Тәрбия һәм мәгариф өлкәсе ветераны |
| 1.14 | Л.С.Выготский медале |
| 1.15 | К.Д.Ушинский медале |
| 1.16 | «Россия Федерациясе һөнәри-техник белем отличнигы» күкрәк билгесе |
| 1.17 | «Шәфкатьлелек һәм хәйриячелек өчен» күкрәк билгесе |
| 1.18 | «Профессиягә тугрылык өчен» күкрәк билгесе |
| 1.19 | «Яшьлек һәм Профессиональлек» күкрәк билгесе |
| 1.20 | «Мактаулы остаз» күкрәк билгесе |
| 1.21 | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Ветеран» күкрәк билгесе |
| 1.22 | «Мактауга лаек хезмәт һәм аерымлык өчен» медале |
| 1.23 | «Мәгариф һәм фәнни-технологик үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга өлеш керткән өчен» медале |
| 1.24 | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Мактаулы хезмәткәр» исеме |
| 1.25 | «Яшь галим» күкрәк билгесе |
| 1.26 | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының Мактау грамотасы |
| 2. СССР (РСФСР) Халык мәгарифе министрлыгы, Мәгариф министрлыгы | |
| 2.1 | «СССР мәгариф отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.2 | «Халык мәгарифе отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.3 | «СССР һөнәри-техник белем отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.4 | «РСФСР һөнәри-техник белем отличнигы» күкрәк билгесе |

Казан шәһәре муниципаль гомуми
белем бирү оешмалары
хезмәткәрләре хезмәтенә түләү
шартлары турындагы нигезләмәгә
2 номерлы кушымта

**Кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнәрнең атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Халык артисты |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Халык рәссамы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең Атказанган артисты |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Халык артисты |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Халык язучысы |
| 2.3 | Татарстан Республикасының Халык шагыйре |
| 2.4 | Татарстан Республикасының Халык рәссамы |
| 2.5 | Татарстан Республикасының Атказанган артисты |
| 2.6 | Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.7 | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССР Халык артисты |
| 3.2 | СССР Халык рәссамы |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган пропагандачы |
| 4.2 | Халык артисты |
| 4.3 | Атказанган артист |
| 4.4 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.5 | Халык рәссамы |
| 4.6 | Атказанган рәссам |
| 4.7 | Халык язучысы |
| 4.8 | Атказанган язучы |
| 4.9 | Халык шагыйре |

| № т/б | **Мактаулы исемнәрнең атамасы** |
|---|---|
| 4.10 | Халык җырчысы |
| 4.11 | Халык акыны |
| 4.12 | Атказанган журналист |
| 4.13 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.14 | Атказанган мәдәни-агарту эше хезмәткәре |
| 4.15 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.16 | Атказанган китапханәче |
| 4.17 | Кулланма сәнгать мастеры |
| 4.18 | Атказанган халык иҗаты мастеры |
| 4.19 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган төзүче |
| 5.2 | Халык артисты |
| 5.3 | Атказанган артист |
| 5.4 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.5 | Халык рәссамы |
| 5.6 | Атказанган рәссам |
| 5.7 | Халык язучысы |
| 5.8 | Атказанган язучы |
| 5.9 | Халык шагыйре |
| 5.10 | Атказанган журналист |
| 5.11 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 5.12 | Атказанган китапханәче |
| 5.13 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.14 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.15 | Атказанган фән эшлеклесе |

Казан шәһәре муниципаль гомуми
белем бирү оешмалары
хезмәткәрләре хезмәтенә түләү
шартлары турындагы нигезләмәгә
3 номерлы кушымта

**Кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнәрнең атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Атказанган табибы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Атказанган табибы |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССР Халык табибы |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Халык табибы |
| 4.2 | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 4.3 | Атказанган табиб |
| 4.4 | Атказанган провизор |
| 4.5 | Атказанган фармацевт |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 5.2 | Атказанган табиб |
| 5.3 | Атказанган провизор |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 16 сентябрендәге
3906 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәткә түләү системасы – муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартларын һәм күләмнәрен, , шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне кертеп, тариф ставкалары, окладлар (вазыйфаи окладлар) күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

- төп оклад – башкарылган эшләрнең катлаулылыгына бәйле рәвештә, кызыксындыру, компенсация һәм социаль характердагы түләүләрне исәпкә алмыйча, мәктәпкәчә мәгариф оешмасы хезмәткәренең календарь ай өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен яисә хезмәт нормасы (хезмәт хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш сәгатьләре нормасы) өчен билгеләнгән окладлы;

- вазыйфаи оклад – билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен календарь ай өчен фактта эшләнгән вакытка хезмәткәргә хезмәт өчен түләүнең компенсация, кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча билгеләнгән күләме;

- хезмәткәрнең хезмәт хакы (хезмәткә түләү) – хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарылган эшнең катлаулылыгына, санына, сыйфатына һәм шартларына карап хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру түләүләре;

- кызыксындыру характерындагы түләүләр – өстәмә түләүләр һәм

кызыксындыру характерындагы өстәмәләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре;

- компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр, шул исәптән нормаль шартлардагы эш өчен һәм компенсация характерындагы башка түләүләр.

1.3. Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында (алга таба – мәктәпкәчә мәгариф оешмалары) мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба – мәгариф хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре) хезмәт хакы (хезмәт хакы) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

- вазыйфаи окладлар;

- компенсация характерындагы түләүләр;

- кызыксындыру характерындагы түләүләр.

1.4. Хезмәткәрнең профиль буенча эш стажы артуга, квалификация категориясе, мактаулы исем бирелүгә, еллык яисә башка ялда булу чорында, аның вакытлыча эшкә сәләтсезлеге чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә хезмәт өчен түләү күләмен үзгәртү хокукы булганда, аның хезмәте өчен түләү күләмен үзгәртү күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң гамәлгә ашырыла.

1.5. Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләре:

- белем һәм педагогик эш стажы (белгечлек, билгеле бер вазыйфада эшләү буенча) турындагы документларны Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 26 августындагы 761н номерлы «Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеген, «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикалары» бүлеген раслау турында»гы боерыгы белән билгеләнгән квалификация характеристикаларына туры килү-килмәве буенча тикшерәләр;

- ел саен мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә тариф исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

- мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында эшләүчеләрнең хезмәт хакы күләмен вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы булалар.

1.6. Казан шәһәре Башкарма комитетының мәгариф идарәсе мәктәпкәчә мәгариф оешмалары җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяли, шуның

нигезендә аларга кызыксындыру түләүләрен билгели.

## II. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Аена төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Вожатый | 19515 |
| | Тәрбияче ярдәмчесе | |
| Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Кече тәрбияче | 19625 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Физик культура инструкторы | 20705 |
| | Музыка җитәкчесе | |
| Икенче | Өстәмә белем бирү педагогы | 20800 |
| Өченче | Тәрбияче | 20900 |
| | Педагог-психолог | |
| | Методист | |
| Дүртенче | Өлкән тәрбияче | 21000 |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьюторлардан тыш) | |
| | Укытучы-дефектолог | |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Балаларга гомуми белем бирү программасын һәм өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм башка структур бүлекчәләр, белем бирү эшчәнлеген методик һәм | 21050 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Аена төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| | мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешма мөдире (башлыгы) (икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | |
| Икенче | Белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы), башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениесенең кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (җитештерү) остаханәсе, укыту хуҗалыгы һәм (бүлекчә) башка структур бүлекчәләре башлыгы (мөдире, директоры, җитәкчесе, идарәчесе) (өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | 21100 |

2.2. Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары медицина хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Аена төп оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| «Беренче дәрәҗә медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Авыруларны карау буенча кече шәфкать туташы | 19242 |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 20163 |
| Икенче | Диета буенча шәфкать туташы | 20663 |
| Өченче | Шәфкать туташы | 21163 |
| | Физиотерапия буенча шәфкать туташы | |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Дүртенче | Фельдшер | 21863 |
| Бишенче | Өлкән шәфкать туташы | 22863 |

| | | |
|---|---|---|
| | Сәламәтлек пункты мөдире – фельдшер (шәфкать туташы) | |
| «Табиблар һәм провизорлар» вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиблардан тыш) | 24563 |

## III. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы ставкасы (төп оклады) өчен сәгатьләр нормасы

3.1. Эш вакытының озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш вакытының нормалары) Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 22 декабрендәге 1601 номерлы «Педагогик хезмәткәрләрнең эш вакыты озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары) турында һәм хезмәт килешүендә игълан ителә торган педагогик хезмәткәрләрнең укыту йөкләнешен билгеләү тәртибе турында»гы боерыгы белән билгеләнгән.

Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләре өчен эш вакыты озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы) атнага 36 сәгатьтән артмаган кыскартылган эш вакыты озынлыгыннан чыгып билгеләнә, ул үз эченә педагогика (укыту) эшен, тәрбия эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфаи бурычлар һәм эш вакыты режимында каралган башка педагогик эшне ала.

3.2. Вазыйфасына һәм (яисә) белгечлегенә карап, педагогик хезмәткәрләргә эш вакытының түбәндәге озынлыгы яисә хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләренең нормасы билгеләнә:

3.2.1. атнага 36 сәгатьлек эш вакыты түбәндәгеләргә билгеләнә:

- мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның һәм өстәмә эшчәнлек төре буларак белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бала йортларының өлкән тәрбиячеләренә;
- педагог-психологларга;
- социаль педагогларга;
- оештыручы педагогларга;
- производствода өйрәтү осталарына;
- өлкән вожатыйларга;
- хезмәт буенча инструкторларга;

- педагог-китапханәчеләргә;

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар методистларына һәм өлкән методистларына;

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тьюторларына, югары белемнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалардан тыш;

- урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның физик тәрбия җитәкчеләренә;

- тормыш иминлеге нигезләрен укытучы- оештыручыларга;

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның инструктор-методистларына, өлкән инструктор-методистларына;

3.2.2. атнага 30 сәгать буе эш вакытының озынлыгы өлкән тәрбиячеләргә (әлеге Нигезләмәнең 3.2.1 пунктында күрсәтелгән өлкән тәрбиячеләрдән тыш) билгеләнә;

3.2.3. хезмәт хакы ставкасы өчен атнага 20 сәгать күләмендә түбәндәгеләргә педагогик эш сәгатьләренең нормасы билгеләнә:

- укытучы-дефектологларга;

- укытучы-логопедларга;

3.2.4. хезмәт хакы ставкасы өчен атнага 24 сәгать күләмендә педагогик эш сәгатьләренең нормасы түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

- музыка җитәкчеләренә;

- концертмейстерларга;

3.2.5. хезмәт хакы ставкасы өчен атнага 25 сәгать күләмендә педагогик эш сәгатьләре нормасы сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны (тәрбияләнүчеләрне) турыдан-туры укытуны, тәрбияләүне, карап торуны һәм карауны гамәлгә ашыручы тәрбиячеләргә билгеләнә;

3.2.6. хезмәт хакы ставкасы өчен атнага 30 сәгать күләмендә педагогик эш сәгатьләре нормасы түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

- физик культура буенча инструкторларга;

- интернатта тәрбияләнүчеләргә яшәү өчен, шулай ук озайтылган көн төркемнәрендә балаларны карап тору һәм карау өчен шартлар тудырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның; ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларның; туберкулез интоксикациясе булган укучылар (тәрбияләнүчеләр) өчен оешмаларның (төркемнәрнең), шул исәптән шифаханә оешмалары; медицина оешмаларының; өстәмә эшчәнлек төре сыйфатында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның; социаль хезмәт күрсәтү

оешмаларының (алга таба – медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары) тәрбиячеләренә (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары әлеге Нигезләмәнең 3.2.5 һәм 3.2.7 пунктларында каралган тәрбиячеләрдән тыш);

3.2.7. хезмәт хакы ставкасы өчен атнага 36 сәгать күләмендә педагогик эш сәгатьләре нормасы түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

- өстәмә гомуми белем бирү программалары, мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, урта һөнәри белем бирү мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, шулай ук балаларны карап тору һәм карауны гамәлгә ашыручы оешмалар тәрбиячеләренә (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары әлеге Нигезләмәнең 3.2.5 һәм 3.2.6 пунктларында каралган тәрбиячеләрдән тыш);

3.2.8. әлеге Нигезләмәнең 3.2.8 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән педагогик хезмәткәрләрнең эш хакы ставкасы өчен педагогик эш нормасына аларның педагогик эшенең нормалаштырыла торган өлеше булып торучы уку (укытучылык) эше нормасы (алга таба – уку (укытучылык) эше сәгатьләре нормасы) кабул ителә;

а) хезмәт хакы ставкасы өчен атнага 18 сәгать күләмендә уку (укытучылык) эше сәгатьләре нормасы түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

- төп гомуми белем бирү программалары (шул исәптән җайлаштырылган) буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар укытучыларына;

- сәнгать, физик культура һәм спорт өлкәсендә өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар укытучыларына;

- өстәмә белем бирү педагогларына һәм өстәмә белем бирүнең өлкән педагогларына;

- физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның тренер-укытучыларына һәм өлкән тренер-укытучыларына;

- медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары логопедларына;

- мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының чит тел укытучыларына;

- педагогик юнәлештәге урта һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар укытучыларына (әлеге оешмаларның хезмәт хакы ставкасы өчен елына 720 сәгать күләмендә уку (укытучылык) эше сәгатьләре нормасын кулланучы укытучыларыннан тыш);

б) хезмәт хакы ставкасы өчен елына 720 сәгать күләмендә уку

(укытучылык) эше нормасы урта һөнәри белем бирү мәгариф программалары буенча, шул исәптән сәнгать өлкәсендә интеграцияләнгән мәгариф программалары һәм һөнәри белем бирүнең төп программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның укытучыларына (әлеге Нигезләмәнең 3.2.8 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән укытучылардан тыш) билгеләнә.

Биләгән вазыйфаларына бәйле рәвештә педагогик хезмәткәрләрнең эш вакытына уку (укытучылык) эше, тәрбия эше, укучылар белән индивидуаль эш, фәнни, иҗади һәм тикшеренү эшләре, шулай ук хезмәт (вазыйфаи) бурычлары һәм (яисә) индивидуаль план белән каралган башка педагогик эш кертелә: методик, әзерлек, оештыру, диагностика эше, мониторинг алып бару эше, укучылар белән уздырыла торган тәрбия, физкультура-савыктыру, спорт, иҗади һәм башка чаралар планында каралган, укучылар белән уздырыла торган эш.

Педагогик хезмәткәрләрнең әлеге Нигезләмәнең 3.2.3-3.2.7 пунктларында каралган хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш нормасы астрономик сәгатьләрдә билгеләнә. Әлеге Нигезләмәнең 3.2.8 пунктында каралган уку (укытучылык) эше нормалары кыска тәнәфесләрне (тәнәфесләрне), динамик паузаны исәпкә алып, астрономия сәгатьләрендә билгеләнә.

Әлеге Нигезләмәнең 3.2.5-3.2.7 пунктларында каралган хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы һәм әлеге Нигезләмәнең 3.2.8 пунктында каралган уку (укытучылык) эше нормалары педагогик хезмәткәрләргә, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан билгеләнгән атнага (елга) педагогика эшенең яисә уку (укытучылык) эшенең күләмен исәпкә алып, бер ай өчен хезмәт хакы исәпләү күләме булып тора.

Педагогик хезмәткәр тарафыннан язма ризалыгы белән башкарыла торган педагогик эш яисә уку (укытучылык) эше өчен хезмәт хакы ставкасы өчен билгеләнгән сәгатьләр нормасыннан артыграк яисә хезмәт хакы ставкасы өчен билгеләнгән сәгатьләр нормасыннан түбәнрәк булган өчен түләү хезмәт хакы ставкасының билгеләнгән күләменнән педагогика эшенең яисә уку (укытучылык) эшенең фактта билгеләнгән күләменә пропорциональ рәвештә түләнә, моңа хезмәт хакы ставкаларын атнага хезмәт хакы ставкасы өчен билгеләнгән уку (укытучылык) эше сәгатьләренең нормасына туры килә торган күләмендә уку йөкләнеше тәэмин ителә алмаган укытучыларга тулы күләмдә хезмәт хакы ставкалары түләнә торган очраклар керми;

3.2.9. Атнага 40 сәгать эш вакыты озынлыгы әлеге Нигезләмәнең 3.2.1-3.2.8 пунктларында күрсәтелмәгән хезмәткәрләргә, шул исәптән мәгариф оешмалары җитәкчеләренә, аларның урынбасарларына һәм структур бүлекчәләр

җитәкчеләренә билгеләнә;

3.2.10. хезмәт хакы ставкасы өчен укытучылык (педагогик) эш сәгатьләре нормасы түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

- физик тәрбия җитәкчеләренә, тормыш иминлеге нигезләрен, хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр әзерлекне оештыручы укытучыларга – елына 360 сәгать күләмендә;

- укучылар саны 50 кешегә кадәр булган башлангыч гомуми белем бирү оешмалары (педагогика көллиятләре студентларының педагогик практикасын узу өчен беркетелгән башлангыч гомуми белем бирү оешмаларыннан тыш), укучылар саны 80 кешегә кадәр булган кичке (сменалы) гомуми белем бирү оешмалары (шәһәр тибындагы шәһәрләрдә һәм поселокларда – 100 кешегә кадәр) директорларына – атнага 10 сәгать күләмендә;

- бер-ике төркемле мәктәпкәчә мәгариф оешмалары мөдирләренә (балалар тәүлек буе була торган бер яки берничә төркемле оешмалардан тыш) – көненә өч сәгать күләмендә.

Мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең эш вакыты (хезмәт хакы ставкасы өчен эш сәгатьләре нормалары) дәвамлылыгы Россия Федерациясе Хезмәт кодексы белән билгеләнә.

3.2.11. Туберкулез интоксикациясе булган укучылар (тәрбияләнүчеләр) өчен төркемнәрдә эшләүче оешмаларның (төркемнәрнең) кече тәрбиячеләренә һәм тәрбиячеләр ярдәмчеләренә эш хакы ставкасы өчен атнага – 30 сәгать, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләр өчен төркемнәрдә эшләүчеләргә 36 сәгать билгеләнә.

Оешмаларның (төркемнәрнең) кече тәрбиячеләренә һәм тәрбиячеләр ярдәмчеләренә хезмәт хакы ставкасы өчен эш вакыты озынлыгы атнага 40 сәгать билгеләнә (хезмәт хакы ставкасы өчен эш сәгатьләре нормалары әлеге Нигезләмәнең 3.2.11 пунктының 1 абзацында каралган кече тәрбиячеләрдән һәм тәрбиячеләр ярдәмчеләреннән тыш).

## IV. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең күләм күрсәткечләренең норматив саны

Мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакының (төп окладының) төп ставкасы өчен күләм күрсәткечләренең норматив саны тәшкил итә.

Мәктәпкәчә яшьтәге укучылар (тәрбияләнүчеләр) белән турыдан-туры эшләүче өлкән тәрбиячеләргә, тәрбиячеләргә, музыка җитәкчеләренә, укытучы-дефектологларга, укытучы-логопедларга, педагог-психологларга, кече

тәрбиячеләргә, тәрбиячеләрнең ярдәмчеләренә:

а) гомуми үсеш юнәлешендәге төркемнәрдә (төрле яшьтәгеләрне дә кертеп):

- ике айдан өч яшькә кадәр – 15 бала;

- өч яшьтән алып белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганчыга кадәр – 20 бала;

- гаилә белеме рәвешендәге төркемнәрдә – 7 бала;

б) өч яшькә кадәрге һәм өч яшьтән өлкәнрәк балалар өчен компенсацияләү юнәлешендәге төркемнәрдә:

- сөйләме нык бозылган балалар өчен – тиешенчә 6 һәм 10 бала;

- сөйләмендә фонетик-фонематик тайпылышлар булган өч яшьтән өлкәнрәк балалар өчен – 12 бала;

- саңгырау балалар өчен – ике яшь төркеме өчен дә 6 бала;

- начар ишетүче балалар өчен – тиешенчә 6 һәм 8 бала;

- сукыр балалар өчен – ике яшь төркеме өчен дә 6 бала;

- начар күрүче, амблиопияле, кыек күзле балалар өчен – тиешенчә 6 һәм 10 бала;

- терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар өчен – тиешенчә 6 һәм 8 бала;

- психик үсеше тоткарланган балалар өчен, җиңел дәрәҗәдәге акыл ягыннан артта калган балалар өчен – тиешенчә 6 һәм 10 бала;

- өч яшьтән өлкәнрәк булган уртача, авыр дәрәҗәдәге акыл ягыннан артта калган балалар өчен – 8 бала;

- аутистик спектрында тайпылышлары булган балалар өчен – ике яшь төркеме өчен дә 5 бала;

- катлаулы кимчелекләре булган (физик һәм (яисә) психик үсештә ике яисә аннан күбрәк кимчелекләре булган) балалар өчен – ике яшь төркеме өчен дә 5 бала;

в) катнаш юнәлешле төркемнәрдә:

- өч яшькә кадәрге – 10 баладан артык түгел, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән өч баладан артык түгел;

- өч яшьтән өлкәнрәкләр:

10 баладан артык түгел, шул исәптән иң күбе өч саңгырау бала, яисә сукыр балалар, яисә терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар, яисә уртача, авыр дәрәҗәдәге акыл ягыннан артта калган балалар, яисә аутистик спектры бозылган балалар, яисә катлаулы дефектлы балалар;

15 баладан артык түгел, шул исәптән иң күбе начар күрүче дүрт бала, һәм (яисә) амблиопияле, һәм (яисә) кыек күзле балалар, яисә начар ишетүче балалар,

яисә сөйләме бик нык бозылган балалар, яисә акыл ягыннан җиңелчә артта калган балалар;

17 баладан артык түгел, шул исәптән психик үсешләрендә тоткарлык булган биш баладан да күбрәк түгел;

г) өч яшькә кадәрге һәм өч яшьтән өлкәнрәк балалар өчен сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемнәрдә:

- туберкулез интоксикациясе булган балалар өчен – тиешенчә 10 һәм 15 бала;

- еш авыручы балалар һәм махсус сәламәтләндерү чаралары комплексы кирәк булган башка категориядәге балалар өчен – тиешенчә 10 һәм 15 бала.

## V. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

Мәктәпкәчә мәгариф оешмасы хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_N} + P$$
,

биредә:

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган мәктәпкәчә мәгариф оешмасы хезмәткәрләренең төп оклады күләме;

$H_f$ – мәктәпкәчә мәгариф оешмасында эш сәгатьләренең факттагы саны;

$H_N$ – мәктәпкәчә мәгариф оешмасы хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә хезмәт хакы ставкасы өчен билгеләнгән сәгатьләр нормасы;

P – китап нәшрияты продукциясе һәм вакытлы матбугат белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация педагогик хезмәткәрләргә, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә укыту йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмый.

## VI. Кызыксындыру характерындагы түләүләр

6.1. Кызыксындыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне хезмәтнең сыйфат нәтиҗәләренә этәргеч бирүгә, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

Кызыксындыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- квалификация категориясе өчен түләүләр;

- мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләүләр;

- профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;

- хезмәтнең интенсивлыгы өчен түләүләр;

- башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр;

- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

6.2. Мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләрнең күләмнәре һәм тәртибе:

6.2.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) педагогик хезмәткәрләрнең һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә квалификация категориясенең гамәлдә булу срогы чикләрендә аларның гамәлдәге квалификация категориясе булганда бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – мәктәпкәчә мәгариф оешмасы мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә күләме, ул 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмәләр күләмнәре**

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Квалификация категориясе** | **Өстәмә күләме, процент** |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче | 25,0 |
| | Югары | 30,0 |
| Икенче | Беренче | 26,0 |
| | Югары | 31,0 |
| Өченче | Беренче | 27,0 |
| | Югары | 32,0 |
| Дүртенче | Беренче | 28,0 |
| | Югары | 33,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче | 28,0 |
| | Югары | 34,0 |
| Икенче | Беренче | 28,0 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| | Югары | 34,0 |
| Өченче | Беренче | 28,0 |
| | Югары | 34,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән алып башкарыла.

6.2.2. Мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) беренче һәм икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал, педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - мәктәпкәчә мәгариф оешмасы мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре өчен өстәмә күләме.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә күләме – 7 процент.

Татарстан Республикасы (Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы) мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең ведомство бүләкләре, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасының ведомство бүләкләре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның ведомство бүләкләре булган өчен өстәмәләр күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) Мактау грамотасы булган өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) Мактау грамотасы булган өчен өстәмә Россия Федерациясе мәгариф министры (Россия

Федерациясе мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе мәгариф министры) боерыгы белән бүләкләнүче мәгариф хезмәткәрләренә Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының) ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә билгеләнә.

«Мәгарифтәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» аерымлык билгесе, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» аерымлык билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе булган өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. Татарстан Республикасының «Мәгарифтәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» аерымлык билгесе, «Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» аерымлык билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклап калган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе булган өчен өстәмә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең 1 номерлы кушымтасында китерелгән.

9.3. Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләү, төркемнәр санын киметүдән, төркемнәр төрен үзгәртүдән, контроль органнары күрсәтмәләре буенча учреждениене капиталь ремонтка ябудан тыш, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, тиешле чорда (елда) әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән мәктәпкәчә мәгариф оешмасының локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фонды экономиясе булганда, кызыксындыру түләүләре алар буенча хезмәт өчен түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә (эшче, эшче мәдәният, сәнгать һәм кинематография гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен дә кертеп).

Хезмәт өчен түләү фондын тиешле чорда экономияләү хисабына башкарылган кызыксындыру түләвенең күләме, шул чорда хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, мәктәпкәчә мәгариф оешмасы хезмәткәренә тиешле чорда башкарылган хезмәт өчен түләүнең агымдагы елның 1 гыйнварына 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» федераль законда

билгеләнгән минималь күләменнән өч тапкырга артык була алмый (педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәрен биләгән хезмәткәрләрдән, мәктәпкәчә мәгариф оешмасы җитәкчесеннән тыш).

Хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына мәктәпкәчә мәгариф оешмасы җитәкчесенә кызыксындыру түләвенең күләме мәктәпкәчә мәгариф оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабыннан, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәткә түләү фонды экономиясеннән файдалану өчен җаваплылык мәктәпкәчә мәгариф оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.

Казан шәһәре муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә
1 номерлы кушымта

**Мәктәпкәчә мәгариф оешмасы хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре исемлеге**

| № т/б | Бүләк һәм мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикалар дәүләт бүләкләре | |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Халык укытучысы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Атказанган укытучысы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең Атказанган фән эшлеклесе |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган җитештерү белеме бирү мастеры |
| 1.6 | Россия Федерациясенең Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.7 | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.8 | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 1.9 | Россия Федерациясенең Атказанган икътисадчысы |
| 2. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | СССР Халык укытучысы |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 3.2 | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 3.3 | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 3.4 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 3.5 | РСФСР Атказанган тренеры |
| 3.6 | РСФСР Атказанган мәктәп укытучысы |
| 3.7 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 3.8 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 3.9 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 3.10 | Атказанган укытучы |
| 3.11 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 3.12 | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 3.13 | Атказанган югары мәктәп эшлеклесе |

| № т/б | Бүләк һәм мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 3.14 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 3.15 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.3 | Атказанган мәктәп эшлеклесе |
| 4.4 | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 4.5 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 4.6 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 4.7 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 4.8 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 4.9 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 4.10 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.11 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.12 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Татарстан Республикасының Халык укытучысы |
| 5.2 | Татарстан Республикасының Атказанган мәктәп укытучысы |
| 5.3 | Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы |
| 5.4 | Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе |
| 5.5 | Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 5.6 | Татарстан Республикасының Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 5.7 | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.8 | Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы |
| Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының (Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы) ведомство (тармак) бүләкләре | |
| 1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) | |
| 1.1 | Россия Федерациясе гомуми мәгарифенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.2 | Россия Федерациясе башлангыч һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.3 | Россия Федерациясе урта һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.4 | Россия Федерациясе югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясе фән һәм техника мактаулы хезмәткәре |
| 1.6 | Россия Федерациясе яшьләр сәясәте өлкәсендә мактаулы хезмәткәре |
| 1.7 | «Студентларның фәнни-тикшеренү эшен үстергән өчен» күкрәк билгесе |
| 1.8 | Россия Федерациясе мәгариф өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.9 | Россия Федерациясе балалар һәм яшьләр тәрбиясе өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |

| № т/б | Бүләк һәм мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 1.10 | «Мәгариф отличнигы» аерымлык билгесе |
| 1.11 | Россия Федерациясенең тәрбия һәм мәгарифнең мактаулы хезмәткәре |
| 1.12 | Россия Федерациясенең фән һәм югары технологияләр мактаулы хезмәткәре |
| 1.13 | Тәрбия һәм мәгариф өлкәсе ветераны |
| 1.14 | Л.С.Выготский медале |
| 1.15 | К.Д.Ушинский медале |
| 1.16 | «Россия Федерациясе һөнәри-техник белем отличнигы» күкрәк билгесе |
| 1.17 | «Шәфкатьлелек һәм хәйриячелек өчен» күкрәк билгесе |
| 1.18 | «Профессиягә тугрылык өчен» күкрәк билгесе |
| 1.19 | «Яшьлек һәм Профессиональлек» күкрәк билгесе |
| 1.20 | «Мактаулы остаз» күкрәк билгесе |
| 1.21 | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Ветеран» күкрәк билгесе |
| 1.22 | «Мактауга лаек хезмәт һәм аерымлык өчен» медале |
| 1.23 | «Мәгариф һәм фәнни-технологик үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга өлеш керткән өчен» медале |
| 1.24 | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Мактаулы хезмәткәр» исеме |
| 1.25 | «Яшь галим» күкрәк билгесе |
| 1.26 | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының Мактау грамотасы |
| 2. СССР (РСФСР) Халык мәгарифе министрлыгы, Мәгариф министрлыгы | |
| 2.1 | «СССР мәгариф отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.2 | «Халык мәгарифе отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.3 | «СССР һөнәри-техник белем отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.4 | «РСФСР һөнәри-техник белем отличнигы» күкрәк билгесе |

Казан шәһәре муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә
2 номерлы кушымта

**Кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Атказанган табибы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Атказанган табибы |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССРның Халык табибы |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Халык табибы |
| 4.2 | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 4.3 | Атказанган табиб |
| 4.4 | Атказанган провизор |
| 4.5 | Атказанган фармацевт |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 5.2 | Атказанган табиб |
| 5.3 | Атказанган провизор |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 16 сентябрендәге
3906 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмә**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Казан шәһәренең өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәт өчен түләү системасы – федераль законнар, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне кертеп, хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;
- төп оклад – башкарылган эшләрнең катлаулылыгына карап, кызыксындыру, компенсация һәм социаль характердагы түләүләрне исәпкә алмыйча, өстәмә белем бирү оешмасы хезмәткәренең календарь ай өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен яисә хезмәт нормасы (эш хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш сәгатьләре нормасы) өчен билгеләнгән окладзы;
- вазыйфаи оклад – билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен календарь ай өчен фактта эшләнгән вакытка хезмәткәргә хезмәт өчен түләүнең компенсация, кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча билгеләнгән күләме;
- хезмәткәрнең хезмәт хакы (хезмәткә түләү) – хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарылган эшнең катлаулылыгына, санына, сыйфатына һәм шартларына, компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен дә кертеп, хезмәт өчен түләү;
- компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы

өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, шул исәптән нормаль шартлардан читләшә торган шартларда эшләгән өчен, һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

- кызыксындыру характерындагы түләүләр – кызыксындыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Казан шәһәренең өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында (алга таба – өстәмә белем бирү оешмасы) мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, авыл хуҗалыгы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба – мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре) хезмәт хакы (хезмәт хакы) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

- вазыйфаи окладлар;

- кызыксындыру характерындагы түләүләр;

- компенсация характерындагы түләүләр.

1.4. Хезмәткәрнең профиль буенча эш стажы артуга, квалификация категориясе, мактаулы исем бирелүгә, еллык яисә башка ялда булу чорында, аның вакытлыча эшкә сәләтсезлеге чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда ведомствоның аерымлык билгеләре белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә хезмәт өчен түләү күләмен үзгәртү хокукы булганда, аның хезмәте өчен түләү күләмен үзгәртү күрсәтелгән чорлар тәмамлангач гамәлгә ашырыла.

1.5. Өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләре:

- белем, педагогик эш стажы (белгечлек, билгеле бер вазыйфада эшләү буенча) турындагы документларны Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 26 августындагы 761н номерлы «Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеген, «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикалары» бүлеген раслау турында»гы боерыгы белән билгеләнгән квалификация характеристикаларына туры килү-килмәве буенча тикшерәләр;

- ел саен өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә тариф исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

- өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен

вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы булалар.

1.6. Өстәмә белем бирү оешмаларын гамәлгә куючылар өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяли, алар нигезендә аларга кызыксындыру түләүләрен билгели.

## II. Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакының төп окладларын билгеләү

2.1. Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакының төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазыйфа атамасы** | **Аена төп оклад күләме, сум** |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Укыту бүлеге секретаре | 19515 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Хезмәт буенча инструктор | 20705 |
| | Физик культура инструкторы | |
| | Музыка җитәкчесе | |
| Икенче | Тренер-укытучы | 20800 |
| | Концертмейстер | |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | |
| | Педагог-оештыручы | |
| | Социаль педагог | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче | Производствода укыту мастеры | 20900 |
| | Педагог-психолог | |
| | Методист | |
| | Өстәмә белем бирүнең өлкән педагогы | |
| | Өлкән тренер-укытучы | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| Дүртенче | Укытучы (профессор-укытучылар составына кертелгән укытучы вазыйфасыннан тыш) | 21000 |
| | Физик тәрбия җитәкчесе | |
| | Өлкән методист | |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | |

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазыйфа атамасы** | **Аена төп оклад күләме, сум** |
|---|---|---|
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Балаларга өстәмә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы): кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, уку (уку-житештерү) остаханәсе һәм башка структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы) | 21050 |
| Икенче | Балаларга өстәмә белем бирүнең уку-укыту программасын һәм уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 21100 |

2.2. Өстәмә белем бирү оешмаларында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазыйфа атамасы** | **Аена төп оклад күләме, сум** |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Ветеринария фельдшеры | 20818 |
| Икенче | Үсемлекләрне саклау буенча урта квалификацияле агроном | |
| Беренче | Агроном | 20868 |
| | Зоотехник | |
| | Ветеринария табибы | |
| Икенче | II категорияле агроном | 20923 |
| | II категорияле зоотехник | |
| | II категорияле ветеринария табибы | |
| Өченче | I категорияле агроном | 20978 |
| | I категорияле зоотехник | |
| | I категорияле ветеринария табибы | |
| Дүртенче | Әйдәп баручы агроном | 21033 |
| | Әйдәп баручы зоотехник | |

| | | |
|---|---|---|
| | Әйдәп баручы ветеринария табибы | |
| Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Баш агроном | 21759 |

2.3. Өстәмә белем бирү оешмаларында медицина хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазыйфа атамасы** | **Аена төп оклад күләме, сум** |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче | Шәфкать туташы | 21163 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Бишенче | Өлкән шәфкать туташы* | 22863 |
| «Табиблар һәм провизорлар» вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиблардан тыш) | 24563 |

* Вазыйфа оешмада, буйсынуда өч һәм аннан да күбрәк шәфкать туташы булганда, билгеләнә.

2.4. Өстәмә белем бирү оешмалары мәдәният хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Вазыйфа атамасы** | **Аена төп оклад күләме, сум** |
|---|---|
| «Урта буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 20862 |
| Костюмер бүлмәсе мөдире | |
| Культорганизатор | |
| «Әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Библиограф | 21362 |
| Китапханәче | |
| Әйдәп баручы китапханәче | |
| Тавыш операторы | |
| Фондларны саклаучы | |
| Рәссам-скульптор | |
| Куючы рәссам | |

| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмасының җитәкче составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
|---|---|
| Музейның бүлек (сектор) мөдире | 22562 |
| Китапханәнең бүлек (сектор) мөдире | |
| Кино һәм видеофильмнар прокаты бүлеге (пункты) мөдире | |
| Тавыш режиссеры | |
| Куючы режиссер | |
| Сәнгать җитәкчесе | |

## III. Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы ставкасы (төп оклады) өчен сәгатьләр нормасы

3.1. Эш вакытының озынлыгы (төп оклад өчен педагогик эш вакытының сәгатьләр нормасы) Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 22 декабрендәге 1601 номерлы «Педагогик хезмәткәрләрнең эш вакыты озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары) турында һәм хезмәт килешүендә игълан ителә торган педагогик хезмәткәрләрнең укыту йөкләнешен билгеләү тәртибе турында»гы боерыгы белән билгеләнгән.

Өстәмә белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре өчен эш вакыты озынлыгы (төп оклад өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы) атнага 36 сәгатьтән артмаган кыскартылган эш вакыты озынлыгыннан чыгып билгеләнә, ул үз эченә педагогика (укыту) эшен, тәрбия эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфаи бурычлар һәм эш вакыты режимында каралган башка педагогик эшне ала.

3.2. Мәдәният, авыл хуҗалыгы, медицина хезмәткәрләренең эш вакыты озынлыгы (төп оклад өчен эш сәгатьләре нормасы) Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

3.3. Хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә эш вакыты озынлыгы (хезмәт хакы ставкасы өчен эш сәгатьләре нормасы) федераль һәм региональ дәрәҗәдәге өч яклы тармак килешүләре белән билгеләнергә мөмкин.

## IV. Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең күләм күрсәткечләренең норматив саны

Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең төп оклады сәгате өчен күләм күрсәткечләренең норматив саны түбәндәгечә тәшкил итә:

4.1. Сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү

оешмаларыннан тыш, өстәмә белем бирү оешмаларының өстәмә белем бирү педагогларына:

– 15 кеше – укуның беренче елында;

– 12 кеше – укуның икенче елында;

– 10 кеше – өченче һәм аннан соңгы елларда.

4.2. Сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү педагогларына, концертмейстерларга:

– музыка мәктәпләре (сәнгать мәктәпләренең музыка бүлекләре) өчен:

– 1 кеше – индивидуаль дәресләрдә;

– 10 кеше – җидееллык уку чоры булган төркемле дәресләрдә;

– 6 кеше – биш еллык уку чоры булган төркемле дәресләрдә;

– 40 кеше – җидееллык уку чоры булган җыелма дәресләрдә;

– 18 кеше – биш еллык уку чоры белән җыелма дәресләрдә;

– 10 кеше – сәнгать мәктәпләре (сәнгать мәктәбе бүлекләре), сәнгать мәктәбенең гомуми эстетик белем бирү бүлекләре өчен;

– 8 кеше – сәнгать мәктәбенең башлангыч эстетик белем бирү бүлекләре өчен;

– сәнгать мәктәбенең фольклор бүлекләре өчен:

– 1 кеше – индивидуаль дәресләрдә;

– 6 кеше – фольклор хореографиясе дәресләрендә;

– 10 кеше – төркемле дәресләрдә;

– 20 кеше – җыелма дәресләрдә;

– хореография мәктәпләре (сәнгать мәктәбенең хореография бүлекләре), сәнгать мәктәбенең театр сәнгате бүлекләре өчен:

– 1 кеше – индивидуаль дәресләрдә;

– 5 кеше – белгечлек фәннәре буенча дәресләрдә;

– 10 кеше – төркемле дәресләрдә.

## V. Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладының ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_N} + P$$
,

биредә:

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган хезмәткәрләрнең төп оклады күләме;

$H_f$ – өстәмә белем бирү оешмаларында эшләнгән сәгатьләрнең факттагы саны;

$H_N$ – өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы ставкасы өчен әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән сәгатьләр нормасы;

Р – китап нәшрияты продукциясе һәм вакытлы матбугат белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмый.

## VI. Кызыксындыру характерындагы түләүләр

6.1. Кызыксындыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне хезмәтнең сыйфат нәтиҗәләренә этәргеч бирүгә, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

Кызыксындыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- квалификация категориясе өчен түләүләр;
- мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләүләр;
- профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;
- хезмәтнең интенсивлыгы өчен түләүләр;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре;
- башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр.

6.2. Өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләргә кызыксындыру характерындагы түләүләрнең күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе.

6.2.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) педагогик хезмәткәрләрнең һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә квалификация категориясенең гамәлдә булу срогы чикләрендә аларның гамәлдәге квалификация категориясе булганда бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмә күләме, ул 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмәләр күләмнәре**

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Квалификация категориясе** | **Өстәмә күләме, процент** |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче | 11,0 |
| | Югары | 13,0 |
| Икенче | Беренче | 11,0 |
| | Югары | 13,0 |
| Өченче | Беренче | 12,0 |
| | Югары | 15,5 |
| Дүртенче | Беренче | 13,0 |
| | Югары | 18,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче | 13,0 |
| | Югары | 18,0 |
| Икенче | Беренче | 13,0 |
| | Югары | 18,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән алып башкарыла.

6.2.2. Мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) беренче һәм икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре, структур бүлекчәләрнең педагогик хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф хезмәткәрләре вазыйфалары буенча бирелә  һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ – дәүләт бүләкләре өчен өстәмә күләме.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш

республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасы (Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы) мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең ведомство бүләкләре, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасының ведомство бүләкләре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның ведомство бүләкләре булган өчен өстәмәләр күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) Мактау грамотасы булган өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) Мактау грамотасы булган өчен өстәмә Россия Федерациясе мәгариф министры (Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министры, Россия Федерациясе мәгариф министры) боерыгы белән бүләкләнүче мәгариф хезмәткәрләренә Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының) ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә билгеләнә.

«Мәгарифтәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» аерымлык билгесе, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» аерымлык билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе булган өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. Татарстан Республикасының «Мәгарифтәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» аерымлык билгесе, «Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» аерымлык билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклап калган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе булган өчен өстәмә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 1 нче таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү мактаулы исем һәм ведомство бүләкләре бирелгән көннән

башлап башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәре һәм (яисә) ике һәм аннан да күбрәк ведомство бүләкләре булган мәгариф хезмәткәрләренә түләү, хезмәткәр ихтыярына карап, нигезләрнең берсе буенча билгеләнә.

6.2.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) профиль буенча эшләү дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри-квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә стаж буенча төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләр күләме**

| Һөнәри-квалификация төркеменең атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркеме | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | Беренче-икенче | 4 елдан 10 елга кадәр | 2,0 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,0 |
| | | 15 елдан артык | 4,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | Беренче-дүртенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 3,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |
| | | 15 елдан артык | 6,5 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары | Беренче-икенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 3,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |
| | | 15 елдан артык | 6,5 |

6.2.4. Профиль буенча эш стажы үзгәргәндә эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) эш стажы үзгәргәндә эш стажы өчен түләү күләмен арттыруга хокук бирә торган стажга ирешү көненнән алып, әгәр стажын раслый торган документлар оешмада булса, яисә стажын раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән башлап башкарыла.

6.2.5. 3 нче таблица нигезендә мәгариф оешмаларында һәм башка оешмаларда педагогик, җитәкчелек һәм методик эш педагогик эш стажына кертелә.

3 нче таблица

**Эш вакыты мәгариф хезмәткәрләренең педагогик стажына исәпләнә торган оешмалар һәм вазыйфалар исемлеге**

| Оешманың атамасы | Вазыйфа атамасы |
|---|---|
| Мәгариф оешмалары, шул исәптән югары белем бирү оешмалары, югары белем бирүнең хәрби мәгариф оешмалары һәм хәрби һөнәри белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү (белгечләрнең квалификациясен күтәрү) оешмалары;<br>медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары: балалар йортлары, балалар шифаханәләре, клиникалар, поликлиникалар, хастаханәләр һ.б. | Укытучылар, мөгаллимнәр, укытучы-дефектологлар, укытучы-логопедлар (логопедлар), тормыш иминлеге нигезләрен, хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр әзерлекне оештыручы укытучылар, физик тәрбия җитәкчеләре, өлкән мастерлар, производствода өйрәтү (шул исәптән транспорт чараларын йөртүгә, авыл хуҗалыгы машиналарында эшләргә, язу машиналарында эшләргә һәм башка оештыру техникасында эшләргә өйрәтү) осталары, өлкән методистлар, методистлар, өлкән инструктор-методистлар, инструктор-методистлар (шул исәптән физик культура һәм спорт, туризм буенча), концертмейстерлар, музыка җитәкчеләре, өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр, сыйныф тәрбиячеләре, социаль педагоглар, педагог-психологлар, педагог-оештыручылар, өстәмә белем бирү педагоглары, өлкән тренер-укытучылар, тренер-укытучылар, өлкән вожатыйлар (пионервожатыйлар), физкультура, укыту, укыту-тәрбия, укыту-җитештерү, тәрбия, мәдәни-тәрбия эше, производствода укыту (эш), чит тел, укыту-очу әзерлеге, гомуми белем бирү әзерлеге, режим буенча хезмәт буенча инструкторлар, практика, уку-укыту, укыту-җитештерү, тәрбия, мәдәни-тәрбия эше буенча эшчәнлекләре белем бирү (тәрбия) процессына, методик тәэмин итүгә бәйле булган консультация пунктлары, логопед пунктлары, интернатлар, бүлекчәләр, бүлекләр, лабораторияләр, кабинетлар, секцияләр, филиаллар, курслар һәм башка структур бүлекчәләр директорлары (башлыклары, |

| Оешманың атамасы | Вазыйфа атамасы |
|---|---|
| | мөдирләре), директорларның урынбасарлары (башлыклары, мөдирләре), уку-укыту бүлеге мөдирләре, мөдирләре (башлыклары); режим буенча өлкән дежурлар, режим буенча дежурлар, аккомпаниаторлар, культорганизаторлар, экскурсоводлар; профессор-укытучылар составы |
| Барлык исемдәге методик (укыту-методик) оешмалар (ведомство буйсынуына карамастан) | Җитәкчеләр, аларның урынбасарлары, секторлар, кабинетлар, лабораторияләр, бүлекләр мөдирләре; эшчәнлекләре методик тәэмин итү белән бәйле булган фәнни хезмәткәрләр; өлкән методистлар, методистлар |
| Мәгарифкә идарә итү органнары һәм мәгариф оешмаларына җитәкчелек итүче органнар (структур бүлекчәләр) | Җитәкче, инспектор, методик вазыйфалар, инструктор, шулай ук белгечләрнең башка вазыйфалары (икътисадый, финанс, хуҗалык эшчәнлегенә, төзелешкә, тәэмин итүгә, эш башкаруга бәйле вазыйфаларда эшләүдән тыш) |
| Җитештерүдә кадрлар әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмаларның, министрлыкларның (ведомстволарның) бүлекчәләренең техник укыту бүлекләре (бюролары), кадрлар бүлекләре | Эшчәнлекләре квалификация әзерләү һәм күтәрү мәсьәләләре белән бәйле булган штатлы укытучылар, производствода эшчеләрне производствода укыту осталары, җитәкче, инспектор, инженер, методик вазыйфалар |
| РОСТО (ДОСААФ) һәм гражданлык авиациясе мәгариф оешмалары | Җитәкче, команда-очу, команда-инструктор, инженер-инструктор, инструктор һәм укытучылар составы, производствода укыту осталары, инженер-инструктор-методистлар, инженер-очучы-методистлар |
| Оешмаларның тулай торaклары, торак-эксплуатация оешмалары, яшьләр торак комплекслары, балалар кинотеатрлары, яшь тамашачы театрлары, курчак театрлары, балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү буенча мәдәни-агарту оешмалары | Тәрбиячеләр, педагог-оештыручылар, педагог-психологлар (психологлар), укытучылар, балалар һәм яшүсмерләр өчен өстәмә белем бирү педагоглары (түгәрәк җитәкчеләре), инструкторлар һәм инструктор-методистлар, тренер-укытучылар һәм балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү буенча башка белгечләр, балалар бүлекләре, секторлар мөдирләре |
| Төзәтү колонияләре, тәрбия колонияләре, тикшерү изоляторлары һәм төрмәләре, дәвалау-төзәтү оешмалары | Педагогик белем булганда түбәндәге вазыйфаларда эшләү (хезмәт итү): тәрбия эше буенча җитәкче урынбасары, отряд башлыгы, өлкән инспектор, гомуми белем бирү эше (укыту) |

| Оешманың атамасы | Вазыйфа атамасы |
|---|---|
| | буенча инспектор, өлкән инспектор-методист һәм инспектор-методист, җитештерү-техник укыту буенча өлкән инженер һәм инженер, өлкән мастер һәм җитештерү укыту мастеры, саклау һәм режим буенча өлкән инспектор һәм инспектор, укыту-техник кабинет мөдире, психолог |

Педагогик эш стажына түбәндәгеләр кертелә:

- медицина оешмаларында һәм өлкәннәргә социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларда укытучы-дефектологлар, логопедлар, тәрбиячеләр, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау оешмаларының оештыру-методик бүлеге методистлары сыйфатында эшләү вакыты;

- башка оешмаларда эшләү, СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү, югары белем бирү мәгариф оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында урта буын белгечләрен әзерләү программалары буенча уку вакыты, түбәндәге тәртиптә:

- педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына бернинди шартлар һәм чикләүләрсез кертелә:

- контракт буенча хәрби хезмәттә булу вакыты – бер көн хәрби хезмәт өчен бер эш көне хисабыннан, ә хәрби хезмәткә чакырылу буенча хәрби хезмәттә булу вакыты – хәрби хезмәтнең бер көне өчен ике эш көне хисабыннан;

- фильмотека мөдире һәм фильмотека методисты вазыйфасында эшләү вакыты;

- педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына түбәндәге чорлар кертелә, әгәр аерым һәм тулаем алганда алынган бу чорларга педагогик эшчәнлек турыдан-туры алардан алда һәм аннан соң турыдан-туры гамәлгә ашырылган булса:

- СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә офицерлар, сержантлар, старшиналар составы, прапорщиклар һәм мичманнар (шул исәптән Эчке эшләр министрлыгы гаскәрләрендә, гаскәрләрдә һәм иминлек органнарында) вазыйфаларында хезмәт итү вакыты, контракт буенча һәм чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакытыннан тыш;

- Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре һөнәр берлегенең (мәгариф, югары мәктәп һәм фәнни оешмалар) территориаль оешмалары аппаратларында (комитетларында, советларында) җитәкче, инспектор, инструктор һәм башка белгечләр вазыйфаларында эшләү вакыты;

- профсоюз органнарында сайланулы вазыйфаларда эшләү вакыты

вакыты;

- педагогик җәмгыятьләрдә һәм балалар фонды идарәләрендә инструкторлык һәм методик вазыйфаларда эшләү вакыты;

- укытучы йорты директоры (мөдире) (халык мәгарифе, һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре) вазыйфасында; балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрендә яисә балигъ булмаганнарны социаль-хокукый яклау бүлекләрендә, эчке эшләр органнарының хокук бозуларны кисәтү бүлекчәләрендә (балигъ булмаганнар эшләре буенча инспекцияләрдә, милициянең балалар бүлмәләрендә) эшләү вакыты.

6.2.6. Аерым категория педагогик хезмәткәрләрнең педагогик эш стажына оешмаларда эшләү вакыты һәм СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә белем бирү оешмасында эшләү профиленә яисә укытыла торган предмет (курс, дисциплина, түгәрәк) профиленә туры килә торган белгечлек (һөнәр) буенча хезмәт итү вакыты кертелә:

- тормыш иминлеге нигезләрен, хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр әзерлекне оештыручы укытучыларга;

- физик тәрбия укытучыларына һәм мөгаллимнәренә, физик тәрбия җитәкчеләренә, физкультура буенча инструкторларга, инструктор-методистларга (өлкән инструктор-методистларга), тренер-укытучыларга (өлкән тренер-укытучыларга);

- укытучыларга, хезмәт (һөнәри) укыту, технология, сызым, сынлы сәнгать, информатика, махсус дисциплиналар, шул исәптән аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче гомуми белем бирү оешмаларының (сыйныфларның) махсус дисциплиналары укытучыларына, мөгаллимнәренә;

- производствода өйрәтү осталарына;

- өстәмә белем бирү педагогларына;

- экспериментал белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә;

- педагог-психологларга;

- методистларга;

- урта һөнәри белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә мәдәният һәм сәнгатьнең урта буын (бүлекләре) белгечләрен, музыкаль-педагогик, сәнгать-график, музыкаль белгечләр әзерләү программалары буенча;

- балаларга өстәмә белем бирү оешмалары (мәдәният һәм сәнгать, шул исәптән музыкаль һәм сәнгать) укытучыларына, музыка һәм сәнгать гомуми белем бирү оешмаларының махсус дисциплиналары укытучыларына, педагогика училищеларының (педагогика көллиятләренең) музыкаль

дисциплиналары укытучыларына, музыка укытучыларына, музыка җитәкчеләренә, концертмейстерларга.

6.2.7. Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының, бала йортлары тәрбиячеләренә (өлкән тәрбиячеләренә) педагогик стажга мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының ясле төркемендә шәфкать туташы, бала йортларында пост шәфкать туташы вазыйфасында эшләү вакыты, ә ясле төркемнәрендә тәрбиячеләргә медицина вазыйфаларында эшләү вакыты кертелә.

Тәрбияче ярдәмчесе һәм кече тәрбияче вазыйфаларында эшләү вакыты, әлеге вазыйфаларда эшләү чорында хезмәткәр педагогик белем алган яки югары белем бирү мәгариф оешмасында яки һөнәри белем бирү оешмасында белем алган очракта, педагогик эш стажына кертелә.

Оешма хезмәткәрләренә мәгариф оешмаларында сәгатьлек түләү шартларында төп эштән тыш башкарыла торган педагогик эш вакыты, әгәр аның күләме (бер яисә берничә мәгариф оешмасында) уку елында кимендә 180 сәгать тәшкил итсә, педагогик стажга кертелә.

Шул ук вакытта педагогик эш башкарылган айлар гына педагогик стажга кертелә.

Учреждениеләрдә, оешмаларда эшләүнең һәм СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итүнең эш профиленә, укытыла торган предметка (курс, дисциплина, түгәрәк) туры килүе турындагы конкрет мәсьәләләрне профсоюз органы белән килештереп, мәгариф оешмасы җитәкчесенә хәл итү хокукы бирелә.

6.3. Өстәмә белем бирү оешмаларында мәдәният хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләрнең күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе.

6.3.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри-квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләре бирүне күздә тоткан белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә күләме 4 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

4 нче таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмәләр күләмнәре**

| Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|
| «Әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 5,0 |
| Югары | 8,0 |

6.3.2. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ – дәүләт бүләкләре өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмәнең 2 нче таблицасында китерелде.

Дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү алар бирелгән көннән алып башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләге булган хезмәткәрләргә аларның булуы өчен түләү хезмәткәрнең ихтыяры буенча дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

6.3.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын үтәүне исәпкә алып, профиль

буенча эшләү дәвамлылыгына карап, һөнәри-квалификация төркемнәре киселешендә стаж буенча төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең вазыйфаи оклады;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме, ул 5 нче таблицада китерелгән.

5 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләр күләме**

| **Һөнәри-квалификация төркеменең атамасы** | **Стаж буенча төркеме** | **Өстәмә күләме, процент** |
|---|---|---|
| Урта буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 1,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,0 |
| | 15 елдан артык | 2,5 |
| Әйдәп баручы буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | 15 елдан артык | 4,0 |

Профиль буенча эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) эш стажы үзгәргәндә эш стажы өчен түләү күләмен арттыруга хокук бирә торган стажга ирешү көненнән алып, әгәр стажын раслый торган документлар учреждениедә булса, яисә стажын раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән башлап башкарыла.

6.4. Өстәмә белем бирү оешмаларында медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләрнең күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе.

6.4.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри-квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләре бирүне күздә тоткан белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация

категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_{\text{d}}$ – өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең вазыйфаи оклады;

$D_{\text{kk}}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә күләме, ул 6 нчы таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

6 нчы таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмәләр күләмнәре**

| Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | |
| Икенче | 3,0 |
| Беренче | 6,0 |
| Югары | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | |
| Икенче | 6,0 |
| Беренче | 10,0 |
| Югары | 20,0 |

6.4.2. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{\text{pz}}$) медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_{\text{d}}$ – өстәмә белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{\text{pz}}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә

күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмә кушымтасының 3 нче таблицасында китерелде.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемне алган хезмәткәрләргә аларның булуы өчен түләү, хезмәткәрнең ихтыярына карап, мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

6.4.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә стаж буенча төркемнәр буенча, профиль буенча эш озынлыгына бәйле рәвештә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме 7 нче таблицада китерелгән.

7 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Стаж буенча төркеме** | **Өстәмә күләме, процент** |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен

билгеләү (үзгәртү) стажны раслаучы документлар өстәмә белем бирү оешмасында булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән яисә стажны раслаучы кирәкле документ тапшырылган көннән башкарыла.

6.4.4. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр ($B_{sr}$) урта медицина һәм фармацевтика персоналы, табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә вазыйфалар буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr} = O_d \times \frac{D_{sr}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – өстәмә белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлы;

$D_{sr}$ – хезмәтнең интенсивлыгы өчен өстәмәләр күләме 8 нче таблицада китерелгән.

8 нче таблица

**Хезмәтнең интенсивлыгы өчен өстәмәләр күләмнәре**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Квалификация дәрәҗәсе** | **Өстәмәләр диапазоны, процент** |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | Икенче | 1,5 |
| | Өченче | 3,0 |
| | Дүртенче | 4,5 |
| | Бишенче | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар | Беренче-икенче | 3,0 |

6.5. Өстәмә белем бирү оешмаларының авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәре һәм аларны билгеләү тәртибе.

6.5.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләре бирүне күздә тоткан белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә күләме, ул 9 нчы таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

9 нчы таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмәләр күләмнәре**

| Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|
| «Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 5,0 |
| Югары | 8,0 |

6.5.2. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмә кушымтасының 5 нче

таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемне алган хезмәткәрләргә аларның булуы өчен түләү, хезмәткәрнең ихтыярына карап, мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

6.5.3. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын үтәүне исәпкә алып, профиль буенча эшләү дәвамлылыгына карап, авыл хуҗалыгы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә стаж буенча төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә күләме, ул 10 нчы таблицада күрсәтелгән.

10 нчы таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмәләр күләме**

| **Һөнәри квалификация төркеме исеме** | **Стаж буенча төркеме** | **Өстәмә күләме, процент** |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 5 елга кадәр | 3,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |
| | 15 елдан артык | 6,5 |

Профиль буенча эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) эш стажы үзгәргәндә эш стажы өчен түләү күләмен арттыруга хокук бирә торган стажга ирешү көненнән алып, әгәр стажын раслый торган документлар учреждениедә булса, яисә стажын раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән башлап башкарыла.

6.6. Премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә (укытучылар һәм укытучылар вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) юбилей даталарына, мактау билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алуга бәйле рәвештә билгеле бер вакыт аралыгында (ай, квартал, ел) һәм өстәмә белем бирү оешмасының локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнгән башка нигезләрдә бер мәртәбә билгеләнә.

6.6.1. Эш йомгаклары буенча премия һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләмнәре, тәртибе һәм шартлары өстәмә белем бирү оешмасының локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

6.6.2. Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә премия түләүләренә каралган хезмәт өчен түләү фондының күләме төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча хезмәткәрләргә (укытучылар вазыйфасын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) окладлар (хезмәт хакы ставкалары, вазыйфаи окладлар), кызыксындыру характерындагы түләүләрне түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фондының кимендә ике процентын тәшкил итә.

6.6.3. Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы «2012-2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең илкүләм стратегиясе турында»гы Указы белән билгеләнгән ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча, акчалар булган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү түләнә. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме өстәмә белем бирү мәгариф оешмасының тиешле боерыклары белән билгеләнә.

Премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре мәгариф һәм фәннең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны башкарганда Казан шәһәре муниципаль оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында бер мәртәбә билгеләнергә мөмкин. Премия һәм кызыксындыру түләүләре Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе боерыгы белән билгеләнә.

6.7. Өстәмә белем бирү оешмаларында башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр.

6.7.1. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр төп эш урыны буенча мәгариф хезмәткәрләренә, мәдәният хезмәткәрләренә, медицина хезмәткәрләренә, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә (укытучылар һәм

укытучылар вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) билгеле бер вакыт аралыгындагы хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләменә йогынты ясый торган төп критерий – оешмалар хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү.

6.7.2. Өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары, оешма белән идарә итүнең дәүләти-иҗтимагый характерын тәэмин итүче орган белән килештереп, оешма җитәкчесе тарафыннан раслана. Өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының әһәмияте һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары ел саен оешма алдына куелган бурычлар нигезендә билгеләнә.

6.7.3. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләме, тәртибе һәм шартлары өстәмә белем бирү оешмасының локаль норматив актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

6.7.4. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр ($B_{kj}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kj} = \frac{FOT_k}{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m}\left(I_{ij} \times K_i\right)} \times \sum_{i=1}^{n}\left(I_{ij} \times K_i\right),$$

биредә:

$FOT_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүгә каралган хезмәткә түләү фонды;

$I_{ij}$ – j-нче хезмәткәр буенча эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i-нче критерие;

$K_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең I нче критериесенең чагыштырма үлчәм коэффициенты;

n – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

m – өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләр саны.

6.7.5. Эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийларын нормалаштыру төрле зурлыктагы нәтиҗәлелек критерийларын чагыштыруны тәэмин итә. Нормалаштыру эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критерие (иң яхшысы һәм иң начары) күрсәткечләренең диапазонын сайлаудан гыйбарәт, шуларның берсе – нульгә тигезләнгән критерийга, икенчесе бердәй күрсәткечкә туры килә. Чын мәгънәсе булганда эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критерие күрсәткечләре диапазоны чикләрендә нәтиҗәлелек критерие ачыкланганда эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге

критерие нульдән алып берәмлекләргә кадәр билгеләнә. Нәтиҗәлелек критериеның факттагы кыйммәте иң начар күрсәткечтән түбән булганда, нормалаштырылган критерийның кыйммәте – нульгә, иң яхшысыннан югарырак булганда – берәмлеккә тигез итеп кабул ителә.

6.7.6. Эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген билгеләүдән чыгып, нормальләшкән критерий эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген билгеләүдән туры булырга мөмкин (уңай динамика критерийның мәгънәсен арттырып билгеләнә) һәм киресенчә (уңай динамика критерийның мәгънәсен киметеп билгеләнә).

6.7.7. Нормалаштырылган критерий, аның әһәмияте критерий кыйммәтенә турыдан-туры бәйле булганда, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

биредә:

$I_{\text{i}}$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i-нче критериесе;

$FI_{\text{i}}$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериеның фактик әһәмияте;

$M_{\text{i}}$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериеның иң яхшы билгесе;

$L_{\text{i}}$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериеның иң начар билгесе.

6.7.8. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие, аның әһәмияте критерий кыйммәтенә кире бәйләнгән очракта, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = 1 - \frac{FI_i - L_i}{L_i - M_i},$$

биредә:

$I_{\text{i}}$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i-нче критериесе;

$FI_{\text{i}}$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериеның фактик әһәмияте;

$M_{\text{i}}$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериеның иң яхшы билгесе;

$L_{\text{i}}$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелек критериеның иң начар билгесе.

6.7.9. Үлчәм коэффициентлары белән эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның өстенлеклек дәрәҗәсе билгеләнә. Иң өстенлекле критерийга иң зур коэффициент бирелә. Чагыштырма үлчәм коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_i = \frac{VK_i}{\sum_{i=1}^{n} VK_i},$$

биредә:

$K_{\text{i}}$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең I нче критериесенең чагыштырма үлчәм коэффициенты;

$VK_{\text{i}}$ – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләүнең i-нче критериясенең чагыштырма үләчмле коэффициенты.

6.7.10. Хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының гомуми иң чик күләме 11-14 нче таблицаларда күрсәтелгән.

11 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәм коэффициентла-рының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 1. Беренче дәрәҗә укыту-ярдәмче персонал вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | |
| 1.1 | Укыту бүлеге секретаре | Беренче | 5 |
| 2. Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | |
| 2.1 | Хезмәт буенча инструктор | Беренче | 45 |
| 2.2 | Физик культура инструкторы | Беренче | 45 |
| 2.3 | Музыка җитәкчесе | Беренче | 45 |
| 2.4 | Өлкән вожатый | Беренче | 45 |
| 2.5 | Инструктор-методист | Икенче | 50 |
| 2.6 | Концертмейстер | Икенче | 50 |
| 2.7 | Өстәмә белем бирү педагогы | Икенче | 50 |
| 2.8 | Педагог-оештыручы | Икенче | 50 |
| 2.9 | Социаль педагог | Икенче | 50 |
| 2.10 | Тренер-укытучы | Икенче | 50 |
| 2.11 | Тәрбияче | Өченче | 55 |
| 2.12 | Методист | Өченче | 55 |
| 2.13 | Педагог-психолог | Өченче | 55 |

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәм коэффициентла-рының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 2.14 | Өлкән инструктор-методист | Өченче | 55 |
| 2.15 | Өстәмә белем бирүнең өлкән педагогы | Өченче | 55 |
| 2.16 | Өлкән тренер-укытучы | Өченче | 55 |
| 2.17 | Укытучы (профессор-укытучылар составына кертелгән укытучылар вазыйфаларыннан тыш) | Дүртенче | 60 |
| 2.18 | Физик тәрбия җитәкчесе | Дүртенче | 60 |
| 2.19 | Өлкән тәрбияче | Дүртенче | 60 |
| 2.20 | Өлкән методист | Дүртенче | 60 |
| 2.21 | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьюторлардан тыш) | Дүртенче | 60 |
| 3. Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | |
| 3.1 | Балаларга өстәмә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы): кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, уку (уку-җитештерү) остаханәсе һәм башка структур бүлекчәләр (икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) | Беренче | 65 |
| 3.2 | Балаларга өстәмә белем бирүнең уку-укыту программасын һәм уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур | Икенче | 70 |

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәм коэффициентла-рының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| | бүлекчә мөдире (башлыгы) | | |

12 нче таблица

**Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының гомуми иң чик күләме**

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. Урта буын мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 1.1 | Костюмер бүлмәсе мөдире | 35 |
| 1.2 | Аккомпаниатор | 35 |
| 1.3 | Культорганизатор | 35 |
| 2. Әйдәп баручы буын мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 2.1 | Китапханәче | 40 |
| 2.2 | Әйдәп баручы китапханәче | 42 |
| 2.3 | Баш китапханәче | 45 |
| 2.4 | Аккомпаниатор-концертмейстер | 40 |
| 2.5 | Тавыш операторы | 40 |
| 2.6 | Рәссам-бизәүче | 45 |
| 3. Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләре составы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 3.1 | Музейның бүлек (сектор) мөдире | 50 |
| 3.2 | Китапханәнең бүлек (сектор) мөдире | 50 |
| 3.3 | Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | 55 |
| 3.4 | Балетмейстер-куючы | 55 |
| 3.5 | Сәнгать җитәкчесе | 55 |

13 нче таблица

**Медицина хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының гомуми иң чик күләме**

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.1 | Шәфкать туташы | 40 |
| 1.2 | Массаж буенча шәфкать туташы | 40 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.3 | Фельдшер | 45 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.4 | Өлкән шәфкать туташы | 50 |
| 2. Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | |
| 2.1 | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиблардан тыш) | 60 |

14 нче таблица

**Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме**

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1. «Икенче дәрәҗәдә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1 | Ветеринария фельдшеры | 45 |
| 1.2 | Үсемлекләрне саклау буенча агроном (урта квалификацияле) | 45 |
| 2. «Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.1 | Агроном | 55 |
| 2.2 | Ветеринария табибы | 55 |
| 2.3 | Зоотехник | 55 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.4 | Икенче категорияле агроном | 60 |
| 2.5 | Икенче категорияле ветеринария табибы | 60 |
| 2.6 | Икенче категорияле зоотехник | 60 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | | |

| № т/б | Вазыйфа атамасы | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 2.7 | Беренче категорияле агроном | 63 |
| 2.8 | Беренче категорияле ветеринария табибы | 63 |
| 2.9 | Беренче категорияле зоотехник | 63 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 2.10 | Әйдәп баручы агроном | 65 |
| 2.11 | Әйдәп баручы ветеринария табибы | 65 |
| 2.12 | Әйдәп баручы зоотехник | 65 |
| 3. «Дүртенче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| 3.1 | Баш агроном | 70 |

6.7.11. Оешма эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең бер төр критерийлары һәм аларның үлчәм коэффициентлары белем бирү оешмалары төрләре киселешендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан раслана.

6.7.12. Өстәмә белем бирү оешмаларында башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр фонды төзелә ($FOT_k$), аның күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_k = FOT_{do} \times \frac{D_k}{100\%},$$

биредә:

$FOT_{do}$ – төп эш урыны буенча хезмәткәрләрнең (укытучылар һәм укытучылар вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) вазыйфаи окладлары (хезмәт хакы окладлары, ставкалары) буенча өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фонды;

$D_k$ – башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелә торган хезмәткә түләү фонды күләме.

Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләргә хезмәткә түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме 15 процент күләмендә кабул ителә.

## VII. Компенсация характерындагы түләүләр

7.1. Оешмаларда компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче

хезмәткәрләргә түләүләр;

- нормаль шартлардан читләшкән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификацияле эшләрне башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) бергә алып барганда, эштән тыш эшләгәндә, төнге вакытта эшләгәндә һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләгәндә) түләүләр;

- эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр.

7.2. Аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, локаль норматив актлар, хезмәт шартнамәсе белән билгеләнә торган компенсация характерындагы түләүләр.

7.3. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = \left( O_b \times \frac{H_{fk}}{H_N} + P \right) \times \frac{D_{kh}}{100\%},$$

биредә:

$O_b$ – өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлегендә билгеләнгән төп оклады күләме;

$H_{fk}$ – законнарда компенсация характерындагы түләү каралган фактта эшләнгән вакыт;

$H_N$ – өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы ставкасы өчен әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән сәгатьләр нормасы;

P – китап нәшрияты продукциясе һәм вакытлы матбугат белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация педагогик хезмәткәрләргә укыту йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмый;

$D_{kh}$ – Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә торган зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләү өчен өстәмә күләме.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү, нормаль хезмәт шартлары булган төрле эш төрләре өчен билгеләнгән хезмәт өчен түләү белән чагыштырганда, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә арттырып билгеләнә.

7.4. Нормаль шартлардан читкә тайпылучы шартларда эшләгән өчен (төрле квалификацияле эшләр башкарганда, һөнәрләр (вазыйфалар) берләштергәндә, эштән тыш эшләгәндә, төнге вакытта эшләгәндә һәм нормаль шартлардан читкә тайпылучы башка шартларда эшләгәндә) компенсация

характерындагы түләүләр төнге вакытта эшләгән һәр сәгать өчен нормаль шартлардагы эш белән чагыштырганда югарырак күләмдә, әмма законнарда һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә билгеләнгән күләмнәрдән ким булмаган күләмдә билгеләнә.

Хезмәткәрне аңа билгеләнгән ял көнендә яисә эшләми торган бәйрәм көнендә эшкә җәлеп иткән очракта, эш өчен, әгәр ял көнендә яисә эшләми торган бәйрәм көнендә эш айлык эш вакыты нормасы чикләрендә башкарылса, хезмәт хакы алучы хезмәткәрләргә карата икеләтә күләмдә, шул ук вакытта кимендә бер көн яисә сәгатьле төп ставкадан ким булмаган күләмдә окладтан югарырак күләмдә һәм, әгәр эш айлык нормадан арттырып башкарылганда, кимендә сәгатьле яки көнлек ставканың икеләтелгән күләмдә төп окладтан югарырак түләнә.

Ял көнендә яки эшләми торган бәйрәм көнендә эшләгән хезмәткәр теләге белән аңа икенче ял көне бирелергә мөмкин. Бу очракта ял көнендә яки эшләми торган бәйрәм көнендә эш өчен бер генә күләмдә түләнә, ә ял көне өчен түләү тиешле түгел.

7.5. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{\mathrm{sd}}$) аерым учреждениеләрдә медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%},$$

биредә:

$O_{\mathrm{d}}$ – өстәмә белем бирү оешмаларының медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{\mathrm{sd}}$ – эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә күләме 16,2 процентка тигез дип кабул ителә.

7.6. Әлеге өстәмә белем бирү оешмасында, бүлекчәдә һәм вазыйфада эшләүнең конкрет шартларын исәпкә алып, эшчәнлек үзенчәлегенә өстәмәләр билгеләнә торган хезмәткәрләрнең вазыйфалары исемлеге, сайланулы профсоюз органы яисә эш мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтле башка орган белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

## VIII. Оешма җитәкчесе, оешма җитәкчесе урынбасарының хезмәт хакын билгеләү тәртибе

8.1. Оешма җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының хезмәт хакы

вазыйфаи окладлардан, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрдән гыйбарәт.

8.2. Өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесенең вазыйфаи окладı ($O_d$) гамәлгә куючы тарафыннан уку елы башына елга бер тапкыр хезмәт өчен түләү төркеменә бәйле рәвештә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_N},$$

биредә:

$O_b$ – җитәкченең төп окладı күләме;

$H_f$ – факттагы эш сәгатьләре саны;

$H_N$ – өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы ставкасы өчен әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән сәгатьләр нормасы.

8.3. Өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләре урынбасарларының вазыйфаи окладлары әлеге оешмалар җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20-30 процентка түбәнрәк билгеләнә.

8.4. Өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренә җитәкчеләрнең хезмәтенә түләү төркеме, башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен төп оклад һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләме 15 нче таблицада күрсәтелгән.

8.5. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне билгели.

Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе боерыгы нигезендә билгеләнә. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен түләнә.

Өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесенә премия түләүләре ай саен, квартал, ел өчен эш йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен түләнергә мөмкин. Җитәкчеләргә премия түләүләре Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе боерыгы нигезендә түләнә.

Финанс яктан тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына төзелә торган һәм календарь ел өчен исәпләнә торган мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы һәм мондый оешмалар хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакы (тиешле җитәкченең, аның урынбасарларының, баш бухгалтерның хезмәт хакын исәпкә алмыйча) нисбәтенең иң чик дәрәҗәсе өч тапкыр күләмендә билгеләнә.

Мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм

баш бухгалтерларының календарь елда исәпләнә торган уртача айлык хезмәт хакы турындагы мәгълүмат Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе битләрендә урнаштырыла.

Урнаштырылырга тиешле мәгълүмат составында шул исәптән учреждениенең тулы исеме, биләгән вазыйфа, шулай ук фамилия, исем һәм ата исеме күрсәтелә.

Урнаштырыла торган мәгълүмат составында күрсәтелгән затларның яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка индивидуаль коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган белешмәләрне, шулай ук дәүләт серенә яисә конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән белешмәләрне күрсәтү тыела.

Мәгълүматны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында урнаштыру (www.kzn.ru) Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе тарафыннан «Бухгалтерлык хезмәте күрсәтү үзәге» МКУ биргән белешмәләр нигезендә хисап елыннан соң килүче елның беренче мартына кадәр гамәлгә ашырыла.

8.6. Өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесе, локаль норматив актларда билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесе урынбасарларына башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне билгели. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен җитәкче урынбасарларына кызыксындыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, еллык эш йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен түләнергә мөмкин. Җитәкче урынбасарларына кызыксындыру характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесе башкарган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрнең 70 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.

15 нче таблица

**Җитәкчеләрнең хезмәтенә түләү төркеме, өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчеләренә башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен төп оклад һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрнең күләмнәре**

| Җитәк-ченең хезмәте | Күләмле күрсәткечнең әһәмияте (уку елы башына дәүләт биреме нигезендә | Төп оклад, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен |
|---|---|---|---|

| өчен түләү төркеме | укучылар саны), кеше | | кызыксындыру характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 1-200 | 28000 | 3000 |
| 2 | 201-400 | 30000 | 4000 |
| 3 | 401-700 | 34000 | 4000 |
| 4 | 701-1200 | 35000 | 5000 |
| 5 | 1201-1800 | 38000 | 6000 |
| 6 | 1801 һәм аннан югарырак | 40000 | 7000 |

8.7. Өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчеләре, җитәкчеләр урынбасарлары, баш бухгалтерлары эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең бер төр критерийлары һәм аларның үлчәм коэффициентлары өстәмә белем бирү оешмаларын алып баручы Татарстан Республикасы тармак министрлыклары тарафыннан раслана.

8.8. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыручы түләүләр ($B_k$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_C \times K_{VK},$$

биредә:

$B_C$ – башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр күләме, ул 15 нче таблицада китерелгән;

$K_{VK}$ – сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

8.9. Учреждение җитәкчесе, аның урынбасарлары, өстәмә белем бирү оешмасының баш бухгалтеры өчен компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

## IX. Өстәмә белем бирү оешмаларының хезмәткә түләү фондын булдыру һәм аннан файдалану тәртибе

9.1. Өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткә түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына өстәмә белем бирү оешмасының норматив чыгымнар, күләм күрсәткечләре саны нигезендә билгеләнгән акчалары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм өстәмә белем бирү оешмаларында финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

9.2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны исәпләү, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр өстәмә белем бирү оешмасы хезмәткәрләренә (эшче, эшче мәдәният, сәнгать һәм кинематография гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең

гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләрен дә кертеп) агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә өстәмә белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган акчалар хисабына башкарыла.

9.3. Өстәмә белем бирү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләү, төркемнәр санын кыскартудан, төркемнәр санын үзгәртүдән, контроль органнары күрсәтмәләре буенча учреждениене капиталь ремонтка ябудан тыш, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, тиешле чорда (елда) әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән өстәмә белем бирү оешмасының локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фонды экономиясе булганда, кызыксындыру түләүләре алар буенча хезмәт өчен түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә (эшче, эшче мәдәният, сәнгать һәм кинематография гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен дә кертеп).

Хезмәт өчен түләү фондын тиешле чорда экономияләү хисабына башкарылган кызыксындыру түләвенең күләме, шул чорда хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, өстәмә белем бирү оешмасы хезмәткәренә тиешле чорда башкарылган хезмәт өчен түләүнең агымдагы елның 1 гыйнварына 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән өч тапкырга артык була алмый (педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәрен биләгән хезмәткәрләрдән, өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесеннән тыш).

Хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабыннан өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесенә кызыксындыру түләвенең күләме өстәмә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Өстәмә белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабыннан, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәткә түләү фонды экономиясеннән файдалану өчен җаваплылык өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.

Казан шәһәренең өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә кушымта

1 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исем һәм ведомство бүләге исеме |
|---|---|
| Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикалар дәүләт бүләкләре | |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Халык укытучысы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Атказанган укытучысы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең Атказанган фән эшлеклесе |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган җитештерү белеме бирү мастеры |
| 1.6 | Россия Федерациясенең Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.7 | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.8 | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 1.9 | Россия Федерациясенең Атказанган икътисадчысы |
| 2. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | СССР Халык укытучысы |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 3.2 | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 3.3 | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 3.4 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 3.5 | РСФСР Атказанган тренеры |
| 3.6 | РСФСР Атказанган мәктәп укытучысы |
| 3.7 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 3.8 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 3.9 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 3.10 | Атказанган укытучы |
| 3.11 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 3.12 | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |

| № т/б | Мактаулы исем һәм ведомство бүләге исеме |
|---|---|
| 3.13 | Атказанган югары мәктәп эшлеклесе |
| 3.14 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 3.15 | Атказанган фән эшлеклесе |
| | 3. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикаларның мактаулы исемнәре |
| 4.1 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.3 | Атказанган мәктәп эшлеклесе |
| 4.4 | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 4.5 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 4.6 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 4.7 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 4.8 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 4.9 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 4.10 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.11 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.12 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 4.13 | Атказанган тренер |
| | 5. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре |
| 5.1 | Татарстан Республикасының Халык укытучысы |
| 5.2 | Татарстан Республикасының Атказанган мәктәп укытучысы |
| 5.3 | Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы |
| 5.4 | Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе |
| 5.5 | Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 5.6 | Татарстан Республикасының Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 5.7 | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.8 | Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы |
| 5.9 | Татарстан Республикасының Атказанган тренеры |
| | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы (Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы) ведомство (тармак) бүләкләре |
| | 1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) |
| 1.1 | Россия Федерациясе гомуми мәгарифенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.2 | Россия Федерациясе башлангыч һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.3 | Россия Федерациясе урта һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.4 | Россия Федерациясе югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясе фән һәм техника мактаулы хезмәткәре |
| 1.6 | Россия Федерациясе яшьләр сәясәте өлкәсендә мактаулы хезмәткәре |
| 1.7 | «Студентларның фәнни-тикшеренү эшен үстергән өчен» күкрәк билгесе |
| 1.8 | Россия Федерациясе мәгариф өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |

| № т/б | Мактаулы исем һәм ведомство бүләге исеме |
|---|---|
| 1.9 | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләр тәрбиясе өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 1.10 | «Мәгариф отличнигы» аерымлык билгесе |
| 1.11 | Россия Федерациясенең тәрбия һәм мәгарифнең мактаулы хезмәткәре |
| 1.12 | Тәрбия һәм мәгариф өлкәсе ветераны |
| 1.13 | Л.С.Выготский медале |
| 1.14 | «Россия Федерациясе һөнәри-техник белем отличнигы» билгесе |
| 1.15 | «Шәфкатьлелек һәм хәйриячелек өчен» күкрәк билгесе |
| 1.16 | «Профессиягә тугрылык өчен» күкрәк билгесе |
| 1.17 | «Яшьлек һәм Профессиональлек» күкрәк билгесе |
| 1.18 | «Мактаулы остаз» күкрәк билгесе |
| 1.19 | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Ветеран» күкрәк билгесе |
| 1.20 | «Мактауга лаек хезмәт һәм аерымлык өчен» медале |
| 1.21 | «Мәгариф һәм фәнни-технологик үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга өлеш керткән өчен» медале |
| 1.22 | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Мактаулы хезмәткәр» исеме |
| 1.23 | «Яшь галим» күкрәк билгесе |
| 1.24 | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының Мактау грамотасы |
| 2. СССР (РСФСР) Халык мәгарифе министрлыгы, Мәгариф министрлыгы | |
| 2.1 | «СССР мәгариф отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.2 | «Халык мәгарифе отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.3 | «СССР һөнәри-техник белем отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.4 | «РСФСР һөнәри-техник белем отличнигы» күкрәк билгесе |
| 2.5 | «Физик культура һәм спорт отличнигы» күкрәк билгесе |

2 нче таблица

**Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның мәдәният хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Халык артисты |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Халык рәссамы |

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 1.3 | Россия Федерациясе Атказанган артисты |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Халык артисты |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Халык язучысы |
| 2.3 | Татарстан Республикасының Халык шагыйре |
| 2.4 | Татарстан Республикасының Халык рәссамы |
| 2.5 | Татарстан Республикасының Атказанган артисты |
| 2.6 | Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.7 | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССР Халык артисты |
| 3.2 | СССР Халык рәссамы |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган пропагандачы |
| 4.2 | Халык артисты |
| 4.3 | Атказанган артист |
| 4.4 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.5 | Халык рәссамы |
| 4.6 | Атказанган рәссам |
| 4.7 | Халык язучысы |
| 4.8 | Атказанган язучы |
| 4.9 | Халык шагыйре |
| 4.10 | Халык җырчысы |
| 4.11 | Халык акыны |
| 4.12 | Атказанган журналист |
| 4.13 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.14 | Атказанган мәдәни-агарту эше хезмәткәре |
| 4.15 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.16 | Атказанган китапханәче |
| 4.17 | Кулланма сәнгать мастеры |
| 4.18 | Атказанган халык иҗаты мастеры |
| 4.19 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган төзүче |
| 5.2 | Халык артисты |
| 5.3 | Атказанган артист |
| 5.4 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.5 | Халык рәссамы |

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 5.6 | Атказанган рәссам |
| 5.7 | Халык язучысы |
| 5.8 | Атказанган язучы |
| 5.9 | Халык шагыйре |
| 5.10 | Атказанган журналист |
| 5.11 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 5.12 | Атказанган китапханәче |
| 5.13 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.14 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.15 | Атказанган фән эшлеклесе |

3 нче таблица

**Медицина хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Атказанган табибы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 1.3 | Россия Федерациясенең сәламәтлек саклау отличнигы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Атказанган табибы |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |

4 нче таблица

**Физик культура хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәре, спорт исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исем, спорт исеменең атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.2 | Россиянең Атказанган спорт мастеры |
| 1.3 | Россиянең Атказанган тренеры |
| 1.4 | Россиянең мактаулы спорт хөкемдары |

| № т/б | Мактаулы исем, спорт исеменең атамасы |
|---|---|
| 1.5 | Россиянең Атказанган халыкара класслы спорт мастеры |
| 1.6 | Россиянең халыкара класслы спорт мастеры |
| 1.7 | Россиянең спорт мастеры |
| 1.8 | Россия гроссмейстеры |
| 1.9 | Россиянең мактаулы спорт хөкемдары |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Атказанган тренеры |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССР Атказанган спорт мастеры |
| 3.2 | СССР Атказанган тренеры |
| 3.3 | СССР спорт мастеры |
| 3.4 | СССР халыкара класслы спорт мастеры |
| 3.5 | РСФСР Атказанган тренеры |
| 3.6 | СССР гроссмейстеры |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2 | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 4.3 | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 4.4 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.5 | Атказанган тренер |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 5.2 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |

5 нче таблица

**Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Атказанган агрономы |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Атказанган ветеринария табибы |

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 1.3 | Россия Федерациясенең Атказанган зоотехнигы |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган мелиораторы |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 1.6 | Россия Федерациясенең Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Атказанган агрономы |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы |
| 2.3 | Татарстан Республикасының Атказанган терлекчесе |
| 2.4 | Татарстан Республикасының Атказанган зоотехнигы |
| 2.5 | Татарстан Республикасының Атказанган мелиораторы |
| 2.6 | Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 2.7 | Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССР Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 4.2 | Атказанган агроном |
| 4.3 | Атказанган авыл хуҗалыгы инженеры |
| 4.4 | Атказанган зоотехник |
| 4.5 | Атказанган терлекчелек хезмәткәре |
| 4.6 | Атказанган терлекче |
| 4.7 | Атказанган терлекчелек мастеры |
| 4.8 | Терлекчелек мастеры |
| 4.9 | Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 4.10 | Атказанган механизатор |
| 4.11 | Атказанган мелиоратор |
| 4.12 | Атказанган ветеринария табибы |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 5.2 | Атказанган агроном |
| 5.3 | Атказанган зоотехник |
| 5.4 | Атказанган терлекче |
| 5.5 | Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 5.6 | Атказанган механизатор |
| 5.7 | Атказанган ветеринария табибы |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 16 сентябрендәге
3906 номерлы карарына
4 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларын башкаручы эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмаларының гомумтармак эшчеләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең окладларын, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

- хезмәт өчен түләү системасы – федераль законнар, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен, хезмәт хакының төп окладлары, база ставкалары, вазыйфаи окладлар күләмнәрен, шулай ук оешмалар хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

- төп оклад – эшче һөнәре яисә тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы мәгариф оешмасы хезмәткәренең кызыксындыру, компенсация һәм социаль характердагы түләүләрне исәпкә алмаган оклады;

- вазыйфаи оклад – билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен календарь ай өчен фактта эшләнгән вакытка хезмәткәргә хезмәт өчен түләүнең компенсация, кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча билгеләнгән күләме;

- хезмәт хакы (хезмәткә түләү) – башкарыла торган эшнең квалификациясенә, катлаулылыгына, санына, сыйфатына һәм шартларына карап, компенсация һәм кызыксындыру түләүләрен дә кертеп, хезмәт өчен түләү;

- компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр, шул исәптән нормаль шартлардагы эш өчен һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

- кызыксындыру характерындагы түләүләр – кызыксындыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.3. Хезмәткәрнең хезмәт хакы (хезмәт өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

- вазыйфаи окладлар;
- компенсация характерындагы түләүләр;
- кызыксындыру характерындагы түләүләр.

## II. Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларын башкаручы эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмаларының эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Аена төп оклад күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре»<br>һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19242 |
| Икенче | 19440 |
| «Икенче дәрәҗә эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре»<br>һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19581 |
| Икенче | 19755 |
| Өченче | 19933 |
| Дүртенче | 20464 |

2.2. Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Аена төп оклад күләме, сум** |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19242 |
| Икенче | 19440 |
| «Икенче дәрәҗә хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 19581 |
| Икенче | 19755 |
| Өченче | 19933 |
| Дүртенче | 20160 |
| Бишенче | 20346 |
| «Өченче дәрәҗә хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 20536 |
| Икенче | 20729 |
| Өченче | 20926 |
| Дүртенче | 21127 |
| Бишенче | 21353 |
| «Дүртенче дәрәҗә хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 22265 |
| Икенче | 22465 |
| Өченче | 22665 |

2.3. Хезмәткәр вазыйфасының һәм һөнәренең эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларының квалификация дәрәҗәсенә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителә.

2.4. Берьюлы берничә эштә эшләүче, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яисә башкарылган эш күләменә бәйле рәвештә башкарыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук берьюлы берничә эштә эшләү

тәртибендә билгән вазыйфа буенча хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазыйфа буенча аерым башкарыла.

## III. Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларын башкаручы эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O \times \frac{H_f}{H_N},$$

биредә:

$H_f$ – Казан шәһәренең муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәткәр өчен билгеләнгән эш вакыты озынлыгы чикләрендә эш сәгатьләренең факттагы саны;

$H_N$ – эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларының хезмәт хакы ставкасы (төп оклады) өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган сәгатьләр нормасы;

О – эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларының әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп оклады күләме.

## IV. Кызыксындыру характерындагы түләүләр

4.1. Кызыксындыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне хезмәтнең сыйфат нәтиҗәләренә этәргеч бирүгә, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Кызыксындыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- хезмәтнең интенсивлыгы өчен түләүләр;

- мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;
- вазыйфа буенча эш стажы өчен түләүләр;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

4.3. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр ($B_{sd}$) Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмаларының эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең гомумтармак һөнәри квалификация төркемнәренә, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларына керүче хезмәткәрләргә хезмәт алучыларның аерым категорияләре белән эшләгән өчен бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларын башкаручы эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sd}$ – хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә күләме.

«Пешекче», «ярдәмче эшче» вазыйфалары буенча гомумтармак эшчеләре һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче һәм «җитештерү мөдире (шеф-пешекче)», мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының, интернаты, мәктәпкәчә бүлекчәсе булган гомуми белем бирү оешмаларының «ашханә мөдире» вазыйфалары буенча җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларына керүче хезмәткәрләргә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр, тиешенчә, 40, 25 һәм 50 процент күләмендә бирелә.

Медицина бәяләмәләре (аллергия, тубинтоксикация, шикәр диабеты) булган балалар төркемнәрен өстәмә тукландыруны оештырган өчен мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә, мәктәпкәчә бүлекчәсе булган гомуми белем бирү оешмаларында шеф-пешекчеләргә һәм пешекчеләргә 5 процент күләмендә өстәмә түләүләр кертергә. Медицина бәяләмәсе булган балалар-фенилкетонурия һәм целиакия өчен ризык әзерләгән өчен шеф-пешекчеләргә һәм пешекчеләргә 5 процент күләмендә өстәмә түләүләр билгеләргә.

Гомуми белем бирү оешмаларының «пешекче», «ярдәмче эшче» вазыйфалары буенча гомумтармак эшчеләре һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә һәм «җитештерү мөдире (шеф-пешекче)», «ашханә

мөдире» вазыйфалары буенча җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларына керүче хезмәткәрләргә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр, тиешенчә, 60, 40 һәм 85 процент күләмендә бирелә.

4.4. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларын башкаручы эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ – мактаулы исемнәр өчен өстәмә күләме, ул 3 процент тәшкил итә.

4.4.1. Хезмәткәрләргә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада китерелгән.

4.4.2. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән алып башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемне алган хезмәткәрләргә аларның булуы өчен түләү, хезмәткәрнең ихтыярына карап, мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

4.5. Эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә вазыйфа (белгечлек) буенча эш озынлыгына карап, һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә стаж буенча төркемнәр буенча вазыйфасы (белгечлеге) буенча эш стажы өчен түләүләр ($B_s$) билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ – Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләре,

белгечләре һәм хезмәткәрләре гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазыйфаи окладары;

$D_s$ – вазыйфасы (белгечлеге) буенча эш стажы өчен өстәмә күләме.

4.5.1. Вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажы өчен өстәмә күләмен түбәндәгеләр тәшкил итә:

- вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажы 2 елдан 5 елга кадәр булганда – 2,5 процент;

- вазыйфа (белгечлек) буенча 5 елдан 10 елга кадәр эш стажы булганда – 4 процент;

- вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажы 10 елдан 15 елга кадәр булганда – 5 процент;

- вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажы 15 елдан арткан очракта – 6 процент.

4.5.2. Вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажы үзгәргәндә эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү) эш стажы үзгәргәндә эш стажы өчен түләү күләмен арттыруга хокук бирә торган стажга ирешү көненнән алып, әгәр стажын раслый торган документлар оешмада булса, яисә стажын раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән башлап башкарыла.

4.5.3. Вазыйфа (белгечлек) буенча эш стажына вазыйфалар (һөнәрләр) буенча эш вакыты таблица нигезендә кертелә.

Таблица

**Вазыйфа (белгечлек) буенча алар буенча эш вакыты эш стажына исәпләнә торган вазыйфалар (һөнәрләр) исемлеге**

| № т/б | Гомумтармак вазыйфалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең («баш», «өлкән» вазыйфа атамаларын да кертеп, вазыйфа эчендәге барлык категорияләрнең) һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазыйфалары атамалары | Эш чорлары кызыксындыру түләүләрен билгеләү өчен белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) атамалары |
|---|---|---|
| 1 | Финанс бүлеге башлыгы, план-икътисад бүлеге башлыгы, баш бухгалтер урынбасары, бухгалтер, бухгалтер-ревизор, икътисадчы, бухгалтерлык | Финанс бүлеге башлыгы, план-икътисад бүлеге башлыгы, баш бухгалтер урынбасары, бухгалтер, бухгалтер-ревизор, икътисадчы, бухгалтерлык хисабы һәм хуҗалык эшчәнлеге анализы буенча |

| № т/б | Гомумтармак вазыйфалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең («баш», «өлкән» вазыйфа атамаларын да кертеп, вазыйфа эчендәге барлык категорияләрнең) һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазыйфалары атамалары | Эш чорлары кызыксындыру түләүләрен билгеләү өчен белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) атамалары |
|---|---|---|
| | хисабы һәм хуҗалык эшчәнлеге анализы буенча икътисадчы, исәпләү (мәгълүмат-исәп) үзәге икътисадчысы, шартнамә һәм претензия эше буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, планлаштыру буенча техник, хисапчы, калькулятор, кассир, таксировщик, статистик, исәпкә алучы | икътисадчы, исәпләү (мәгълүмат-исәп) үзәге икътисадчысы, шартнамә һәм претензия эше буенча икътисадчы, матди-техник тәэминат буенча икътисадчы, планлаштыру буенча икътисадчы, сату буенча икътисадчы, хезмәт буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, планлаштыру буенча икътисадчы, хисапчы, калькулятор, кассир, таксировщик, статистик, исәпкә алучы, салымнар һәм җыемнар буенча консультант, аудитор |
| 2 | Матди-техник тәэминат буенча икътисадчы | Матди-техник тәэминат буенча икътисадчы, материал-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы, склад мөдире, бухгалтер, бухгалтер-ревизор, икътисадчы, бухгалтерлык хисабы һәм хуҗалык эшчәнлеге анализы буенча икътисадчы, хисаплау (мәгълүмат-хисап) үзәге икътисадчысы, шартнамә һәм претензия эше буенча икътисадчы, планлаштыру буенча икътисадчы, сату буенча икътисадчы, финанс эше буенча икътисадчы, товаровед, планлаштыру буенча техник, хисапчы, таксировщик, исәпкә алучы |
| 3 | Хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы | Хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү лабораториясе (бюросы) башлыгы, хезмәт буенча норматив-тикшеренү лабораториясе башлыгы, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы, социаль үсеш бүлеге башлыгы, хезмәт буенча |

| № т/б | Гомумтармак вазыйфалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең («баш», «өлкән» вазыйфа атамаларын да кертеп, вазыйфа эчендәге барлык категорияләрнең) һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазыйфалары атамалары | Эш чорлары кызыксындыру түләүләрен билгеләү өчен белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) атамалары |
|---|---|---|
| | | икътисадчы, хезмәтне нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру буенча инженер, инструктор-дактилолог, хезмәт буенча техник, социолог, нарядчы, хронометражист |
| 4 | Хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы буенча инженер | Хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү буенча лаборатория (бюро) башлыгы, хезмәт буенча норматив-тикшеренү лабораториясе башлыгы, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы инженеры, инженер |
| 5 | Кадрлар бүлеге (махсус бүлек һәм башкалар) башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, кадрлар әзерләү буенча инженер | Кадрлар бүлеге (махсус бүлек һәм башкалар) башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, персонал буенча менеджер, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, кадрлар әзерләү буенча инженер, инструктор-дактилолог, профконсультант, юрисконсульт, табельче |
| 6 | Социаль үсеш бүлеге башлыгы | Социаль үсеш бүлеге башлыгы, кадрлар бүлеге башлыгы, кадрлар әзерләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм түләү бүлеге башлыгы, хезмәтне оештыру һәм җитештерү белән идарә итү лабораториясе (бюро) башлыгы, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы, хезмәтне саклау бүлеге башлыгы, персонал буенча инженер, кадрлар буенча белгеч, инструктор-дактилолог, кадрлар буенча |

| № т/б | Гомумтармак вазыйфалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең («баш», «өлкән» вазыйфа атамаларын да кертеп, вазыйфа эчендәге барлык категорияләрнең) һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазыйфалары атамалары | Эш чорлары кызыксындыру түләүләрен билгеләү өчен белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) атамалары |
|---|---|---|
| | | инспектор, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы инженеры, хезмәтне нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру һәм нормалаштыру буенча инженер, хезмәтне оештыру буенча инженер, хезмәт буенча техник, социолог |
| 7 | Профконсультант | Профконсультант, кадрлар бүлеге башлыгы, кадрлар буенча белгеч, кадрлар буенча инспектор, персонал буенча менеджер, психолог, социолог, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге инспекторы, инструктор-дактилолог |
| 8 | Юридик бүлек башлыгы, юрисконсульт | Юридик бүлек башлыгы, юрисконсульт |
| 9 | Архив мөдире, канцелярия мөдире, документовед, архивариус, эш башкаручы, йөкләмәләр үтәлешен контрольдә тоту буенча инспектор, секретарь, секретарь-машинистка, секретарьстенографистка, стенографистка, машинистка, күрмәүче белгеч секретаре, җитәкче секретаре, паспортист, кодификатор, экспедитор | Архив мөдире, канцелярия мөдире, документовед, архивариус, эш башкаручы, йөкләмәләр үтәлешен контрольдә тоту инспекторы, секретарь, секретарь-машинистка, секретарьстенографистка, стенографистка, машинистка, күрмәүче белгеч секретаре, җитәкче секретаре, паспортист, кодификатор, экспедитор |
| 10 | Машинкада басу бюросы мөдире, күчермә-күбәйткеч бюро мөдире, машинистка | Машинкада басу бюросы мөдире, күчермә-күбәйткеч бюро мөдире, машинистка, секретарь-машинистка, күчермәче |
| 11 | Матди-техник тәэминат бүлеге башлыгы, хуҗалык бүлеге башлыгы, склад мөдире, хуҗалык мөдире | Матди-техник тәэминат бүлеге башлыгы, хуҗалык бүлеге башлыгы, склад мөдире, хуҗалык мөдире, товаровед, агент, сатып алулар агенты, тәэмин итү буенча агент, |

| № т/б | Гомумтармак вазыйфалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең («баш», «өлкән» вазыйфа атамаларын да кертеп, вазыйфа эчендәге барлык категорияләрнең) һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазыйфалары атамалары | Эш чорлары кызыксындыру түләүләрен билгеләү өчен белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) атамалары |
|---|---|---|
| | | тәэмин итү буенча икътисадчы, товаровед, йөкләр ташу буенча экспедитор |
| 12 | Тулай торак мөдире, пропусклар бюросы дежуры, комендант, администратор | Пансионатның (кунакханәнең) торак корпусы мөдире, тулай торак мөдире, пропусклар бюросы мөдире, ял бүлмәсе мөдире, хуҗалык мөдире, пропусклар бюросы дежуры, белешмәләр бирү, кунакханә залы, автомобиль йөртүчеләрнең ял итү бүлмәсе, тулай торак һәм башкалар буенча дежур, комендант, администратор, саклау камерасы мөдире |
| 13 | Гараж башлыгы | Гараж башлыгы, автоколонна башлыгы, пассажир транспорты контролеры, диспетчерлык хәрәкәте һәм төяү-бушату эшләре операторы, автотехник экспертиза буенча белгеч (эксперт-автотехник), юл хуҗалыгы эксперты, автотранспорт йөртүчесе |
| 14 | Җитештерү мөдире, ашханә мөдире | Җитештерү мөдире, ашханә мөдире, пешекче |
| 15 | Диспетчер, диспетчерлык хезмәте операторы | Диспетчер, диспетчерлык хезмәте операторы, диспетчерлык хәрәкәте һәм төяү-бушату эшләре операторы |
| 16 | Фотолаборатория мөдире | Фотолаборатория мөдире, фотограф, рәссам-фотограф |
| 17 | Механик, ремонт буенча инженер, инженер-энергетик (энергетик) | Ремонт цехы башлыгы, остаханә башлыгы (мөдире), механик, ремонт буенча инженер, инженер-энергетик (энергетик), инженер |
| 18 | Инженер-программист (программист), техник-программист, математик, фонд инспекторы, фонд инспекторы ассистенты | Җитештерү белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы бүлеге башлыгы, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру бүлеге башлыгы, инженер-программист |

| № т/б | Гомумтармак вазыйфалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең («баш», «өлкән» вазыйфа атамаларын да кертеп, вазыйфа эчендәге барлык категорияләрнең) һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазыйфалары атамалары | Эш чорлары кызыксындыру түләүләрен билгеләү өчен белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) атамалары |
|---|---|---|
| | | (программист), җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру буенча инженер, җитештерү белән идарә итүнең автоматлаштырылган системалары буенча инженер, инженер, математик, техник-программист, техник, фонд инспекторы, фонд инспекторы ассистенты |
| 19 | Фәнни-техник китапханә мөдире, мәгълүмат бүлеге башлыгы, мәгълүматны саклау бүлеге (лаборатория, сектор) башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат буенча инженер, мәгълүматны саклау буенча инженер, мәгълүматны саклау буенча белгеч, мәгълүматны саклау буенча техник | Фәнни-техник китапханә мөдире, мәгълүмат бүлеге башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат бүлеге башлыгы, мәгълүматны саклау бүлеге (лаборатория, сектор) башлыгы, фәннитехник мәгълүмат буенча инженер, мәгълүматны саклау буенча инженер, патент һәм уйлап табу эше буенча инженер, инженер, мәгълүматны саклау буенча белгеч, мәгълүматны саклау буенча техник, техник |
| 20 | Техник-икътисади тикшеренүләр лабораториясе (бюросы) башлыгы, тикшеренү лабораториясе башлыгы, мәгълүмат бүлеге башлыгы, аналитик | Техник-икътисади тикшеренүләр лабораториясе (бюросы) башлыгы, тикшеренү лабораториясе башлыгы, мәгълүмат бүлеге башлыгы, фәнни-техник мәгълүмат бүлеге башлыгы, аналитик |
| 21 | Инженер-лаборант, техник-лаборант, лаборант | Заводның үзәк лабораториясе башлыгы, җитештерү лабораториясе (җитештерүне контрольдә тоту буенча) башлыгы, инженер-лаборант, инженер, техник-лаборант, техник, лаборант |
| 22 | Инструмент буенча техник, техник-технолог | Җитештерү бүлеге башлыгы, техник бүлек башлыгы, сынаулы җитештерү цехы башлыгы, инструменталь бүлек башлыгы, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру бүлеге башлыгы, җиһазларны туплау бүлеге башлыгы, цех |

| № т/б | Гомумтармак вазыйфалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең («баш», «өлкән» вазыйфа атамаларын да кертеп, вазыйфа эчендәге барлык категорияләрнең) һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазыйфалары атамалары | Эш чорлары кызыксындыру түләүләрен билгеләү өчен белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) атамалары |
|---|---|---|
| | | (участок) башлыгы, (участок, цех) контроль мастеры, участок мастеры, инженер, җитештерүне әзерләү буенча инженер, инженер-технолог, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру буенча инженер, инструмент буенча инженер, җиһазларны туплау буенча инженер, инженер-конструктор, җитештерү белән идарә итүне оештыру буенча инженер, патент һәм уйлап табу эше буенча инженер, фәнни-техник мәгълүмат буенча инженер, механик, техник, техник-конструктор, инструмент буенча техник, техник-технолог |
| 23 | Инженер | Барлык атамалар инженеры, җитештерү бүлеге башлыгы, техник бүлек башлыгы, сынаулы җитештерү цехы башлыгы, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм механикалаштыру бүлеге башлыгы, цех (участок) башлыгы, капиталь төзелеш бүлеге башлыгы, участок мастеры, механик, техник, техник-конструктор, инструмент буенча техник, техник-технолог |
| 24 | Инженер-электроник (электроник), исәпләү (мәгълүмат-исәп) үзәге техникы | Инженер-электроник (электроник), исәпләү (мәгълүмат-хисап) үзәге техникы, инженер, инженер-программист (программист), техник-программист, техник |
| 25 | Күчермәче | Сызымчы, сызымчы-конструктор, күчермәче, рәссам |
| 26 | Психолог | Психолог, медицина психологы, педагог-психолог, профконсультант |
| 27 | Физиолог | Физиолог, биолог |

| № т/б | Гомумтармак вазыйфалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең («баш», «өлкән» вазыйфа атамаларын да кертеп, вазыйфа эчендәге барлык категорияләрнең) һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре вазыйфалары атамалары | Эш чорлары кызыксындыру түләүләрен билгеләү өчен белгечлек буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) атамалары |
|---|---|---|
| 28 | Социолог | Социолог, хезмәт социологиясе лабораториясе (бюросы) башлыгы |
| 29 | Рәссам | Барлык атама рәссамнары, архитектор, сызымчы |
| 30 | Архитектор | Рәссам-конструктор (дизайнер), сызымчы-конструктор, сызымчы |
| 31 | Тәрҗемәче-дактилолог, сурдотәрҗемәче | Тәрҗемәче-дактилолог, сурдотәрҗемәче |
| 32 | Бүлек (ферма, авыл хуҗалыгы участогы) идарәчесе | Бүлек (ферма, авыл хуҗалыгы участогы) белән идарә итүче, агроном, зоотехник |
| 33 | Башка аерымланган структур бүлекчә филиалы директоры (башлыгы, мөдире) | Тиешле төрдәге икътисади эшчәнлек хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә кертелгән вазыйфалар |

4.6. Хезмәткәрләргә премия һәм башка бүләкләү түләүләре билгеле бер вакыт аралыгы (ай, квартал, ел) өчен, шулай ук юбилей даталары, аерым хөрмәт билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, бүләкләр алуга бәйле рәвештә берьюлы һәм учреждениенең локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрендә күрсәтелгән башка нигезләрдә билгеләнә.

4.6.1. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләмнәре, тәртибе һәм шартлары оешманың билгеләнгән локаль актлары һәм күмәк шартнамәләре белән билгеләнә.

4.6.2. Эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренә премия түләүләренә каралган тәкъдим ителә торган хезмәткә түләү фонды күләме төп вазыйфасы һәм төп эш урыны буенча хезмәткәрләргә окладларны (хезмәт хакы ставкаларын, вазыйфаи окладларны) һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләрне түләүгә каралган хезмәткә түләү фондының

кимендә ике процентын тәшкил итә.

## V. Компенсация характерындагы түләүләр

5.1. Казан шәһәре мәгариф оешмаларында компенсация характерындагы түләүгә түбәндәгеләр керә:

- зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр;

- нормаль шартлардан читләшкән шартларда (төрле квалификация, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә), артык хезмәт башкарганда, төнлә эшләгәндә һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда) эшләр башкарган өчен компенсация характерындагы түләүләр.

5.2. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә һәм нормаль шартлардан читкә тайпылучы шартларда эшләгән өчен (һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштерү, эштән тыш эшләү, төнге вакытта эшләү, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү, эш күләмен арттыру яки вакытлыча югалган хезмәткәр вазыйфаларын хезмәт шартнамәсендә билгеләнгән эштән азат ителмичә башкарган өчен, ял көннәрендә һәм эшләми торган бәйрәм көннәре вакытында эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр), законнар нигезендә һәм тиешле финанс елына Казан шәһәре мәгариф оешмаларының хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә билгеләнә.

Компенсация характерындагы түләүләр, аларны түләү күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар, әлеге Нигезләмә нигезендә күмәк шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән билгеләнә.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр ($B_{\mathrm{kh}}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_N},$$

биредә:

O – эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, Казан шәһәренең мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларының әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп оклады күләме;

$D_{\mathrm{kh}}$ – Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә торган

зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә компенсация характерындагы өстәмә күләме;

$H_{fk}$ – аның буенча законнарда компенсация характерындагы түләүләр каралган хакыйкый эшләнгән вакыт;

$H_{N}$ – эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларының хезмәт хакы ставкасы (төп оклады) өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган сәгатьләр нормасы.

Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә хезмәт хакы, нормаль хезмәт шартлары белән эшләүнең төрле төрләре өчен билгеләнгән хезмәт хакы ставкалары окладлары (вазыйфаи окладлары) белән чагыштырганда, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә төп окладның кимендә дүрт проценты күләмендә билгеләнә.

5.3. Нормалдан читкә тайпылган шартларда эш өчен түләүләр түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

- төнлә эшләү сәгате нормаль шартларда эшләү белән чагыштырганда артыграк күләмдә түләнә, әмма хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән күләмнәрдән ким түгел;

- хезмәткәрне аңа билгеләнгән ял көнендә яисә эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшкә җәлеп иткән очракта, эш өчен кимендә икеләтә күләмдә түләнә;

- вазыйфаи оклад алучы хезмәткәрләргә, әгәр ял көнендә һәм эшләми торган бәйрәм көнендә эш вакытының айлык нормасы чикләрендә эш башкарылса, окладка өстәмә рәвештә кимендә бер көнлек яисә бер сәгатьлек төп ставкасы күләмендә һәм, әгәр эш айлык нормадан тыш башкарылса, төп окладка өстәмә рәвештә кимендә көнлек яисә сәгатьлек ставканың икеләтелгән күләмендә;

- ял көнендә яки эшләми торган бәйрәм көнендә эшләгән хезмәткәр теләге белән аңа икенче ял көне бирелергә мөмкин. Бу очракта эш көне булмаган бәйрәм көнендә бер мәртәбә түләнә, ә ял көне өчен түләү түләнми;

- берьюлы берничә һөнәрне (вазыйфаны) башкарганда, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткәндә, эш күләмен арттырганда яисә, хезмәт шартнамәсе белән билгеләнгән эштән азат итмичә, вакытлыча юкка чыккан хезмәткәрнең вазыйфаларын үтәгәндә, хезмәткәргә өстәмә түләү түләнә, аның күләме, өстәмә эшнең эчтәлеген һәм (яисә) күләмен исәпкә алып, хезмәт шартнамәсендәге яклар килешүе буенча билгеләнә.

______________________

Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларын башкаручы эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымта

**Кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге**

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1 | Россия Федерациясенең Халык артисты |
| 1.2 | Россия Федерациясенең Халык рәссамы |
| 1.3 | Россия Федерациясенең Атказанган агрономы |
| 1.4 | Россия Федерациясенең Атказанган артисты |
| 1.5 | Россия Федерациясенең Атказанган архитекторы |
| 1.6 | Россия Федерациясенең Атказанган ветеринария табибы |
| 1.7 | Россия Федерациясенең Атказанган табибы |
| 1.8 | Россия Федерациясенең Атказанган геологы |
| 1.9 | Россия Федерациясенең Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 1.10 | Россия Федерациясенең Атказанган фән эшлеклесе |
| 1.11 | Россия Федерациясенең Атказанган җир төзүчесе |
| 1.12 | Россия Федерациясенең Атказанган зоотехнигы |
| 1.13 | Россия Федерациясенең Атказанган уйлап табучысы |
| 1.14 | Россия Федерациясенең Атказанган конструкторы |
| 1.15 | Россия Федерациясенең Атказанган урманчысы |
| 1.16 | Россия Федерациясенең Атказанган җитештерү белеме бирү мастеры |
| 1.17 | Россия Федерациясенең Атказанган машина төзүчесе |
| 1.18 | Россия Федерациясенең Атказанган мелиораторы |
| 1.19 | Россия Федерациясенең Атказанган металлургы |
| 1.20 | Россия Федерациясенең Атказанган метеорологы |
| 1.21 | Россия Федерациясенең Атказанган метрологы |

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 1.22 | Россия Федерациясенең Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 1.23 | Россия Федерациясенең Атказанган пилоты |
| 1.24 | Россия Федерациясенең Атказанган халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 1.25 | Россия Федерациясенең Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 1.26 | Россия Федерациясенең Атказанган геодезия һәм картография хезмәткәре |
| 1.27 | Россия Федерациясенең Атказанган дипломатик хезмәт хезмәткәре |
| 1.28 | Россия Федерациясенең Атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 1.29 | Россия Федерациясенең Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 1.30 | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.31 | Россия Федерациясенең Атказанган урман сәнәгате хезмәткәре |
| 1.32 | Россия Федерациясенең Атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре |
| 1.33 | Россия Федерациясенең Атказанган азык-төлек индустриясе хезмәткәре |
| 1.34 | Россия Федерациясенең Атказанган балык хуҗалыгы хезмәткәре |
| 1.35 | Россия Федерациясенең Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 1.36 | Россия Федерациясенең Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 1.37 | Россия Федерациясенең Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре |
| 1.38 | Россия Федерациясенең Атказанган текстиль һәм җиңел сәнәгать хезмәткәре |
| 1.39 | Россия Федерациясенең Атказанган сәүдә хезмәткәре |
| 1.40 | Россия Федерациясенең Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 1.41 | Россия Федерациясенең Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.42 | Россия Федерациясенең Атказанган рационализаторы |
| 1.43 | Россия Федерациясенең Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре |
| 1.44 | Россия Федерациясенең Атказанган коткаручысы |
| 1.45 | Россия Федерациясенең Атказанган төзүчесе |
| 1.46 | Россия Федерациясенең Атказанган укытучысы |
| 1.47 | Россия Федерациясенең Атказанган химигы |
| 1.48 | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 1.49 | Россия Федерациясенең Атказанган шахтеры |
| 1.50 | Россия Федерациясенең Атказанган штурманы |
| 1.51 | Россия Федерациясенең Атказанган штурман-сынаучысы |
| 1.52 | Россия Федерациясенең Атказанган экологы |
| 1.53 | Россия Федерациясенең Атказанган икътисадчысы |
| 1.54 | Россия Федерациясенең Атказанган энергертигы |
| 1.55 | Россия Федерациясенең Атказанган юристы |
| 2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре | |
| 2.1 | Татарстан Республикасының Мактау грамотасы |
| 2.2 | Татарстан Республикасының Халык артисты |
| 2.3 | Татарстан Республикасының Халык язучысы |
| 2.4 | Татарстан Республикасының Халык шагыйре |
| 2.5 | Татарстан Республикасының Халык укытучысы |

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 2.6 | Татарстан Республикасының Халык рәссамы |
| 2.7 | Татарстан Республикасының Атказанган агрономы |
| 2.8 | Татарстан Республикасының Атказанган артисты |
| 2.9 | Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы |
| 2.10 | Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы |
| 2.11 | Татарстан Республикасының Атказанган табибы |
| 2.12 | Татарстан Республикасының Атказанган геологы |
| 2.13 | Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.14 | Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе |
| 2.15 | Татарстан Республикасының Атказанган терлекчесе |
| 2.16 | Татарстан Республикасының Атказанган җир төзүчесе |
| 2.17 | Татарстан Республикасының Атказанган зоотехнигы |
| 2.18 | Татарстан Республикасының Атказанган уйлап табучысы |
| 2.19 | Татарстан Республикасының Атказанган урманчысы |
| 2.20 | Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе |
| 2.21 | Татарстан Республикасының Атказанган мелиораторы |
| 2.22 | Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 2.23 | Татарстан Республикасының Атказанган нефтьчесе |
| 2.24 | Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 2.25 | Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 2.26 | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 2.27 | Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 2.28 | Татарстан Республикасының Атказанган җиңел сәнәгать хезмәткәре |
| 2.29 | Татарстан Республикасының Атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре |
| 2.30 | Татарстан Республикасының Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 2.31 | Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 2.32 | Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре |
| 2.33 | Татарстан Республикасының Атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре |
| 2.34 | Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 2.35 | Татарстан Республикасының Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 2.36 | Татарстан Республикасының Атказанган рационализаторы |
| 2.37 | Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре |
| 2.38 | Татарстан Республикасының Атказанган коткаручысы |
| 2.39 | Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе |
| 2.40 | Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы |
| 2.41 | Татарстан Республикасының Атказанган химигы |
| 2.42 | Татарстан Республикасының Атказанган экологы |
| 2.43 | Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы |

| № т/б | **Мактаулы исемнең атамасы** |
|---|---|
| 2.44 | Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы |
| 2.45 | Татарстан Республикасының Атказанган юристы |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1 | СССР Халык артисты |
| 3.2 | СССР Халык рәссамы |
| 3.3 | СССР Халык архитекторы |
| 3.4 | СССР Атказанган очучы-сынаучысы |
| 3.5 | СССР Атказанган штурман-сынаучысы |
| 3.6 | СССРның Халык табибы |
| 3.7 | СССР Халык укытучысы |
| 3.8 | СССР Атказанган спорт мастеры |
| 3.9 | СССР Атказанган тренеры |
| 3.10 | СССР Атказанган уйлап табучысы |
| 3.11 | СССР Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 3.12 | СССР Атказанган сәнәгать хезмәткәре |
| 3.13 | СССР Атказанган төзүчесесе |
| 3.14 | СССР Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 3.15 | СССР Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 3.16 | СССР Кораллы Көчләренең Атказанган белгече |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1 | Атказанган сәнәгать хезмәткәре |
| 4.2 | Атказанган энергетик |
| 4.3 | Атказанган нефтьче |
| 4.4 | Нефть остасы |
| 4.5 | Атказанган газ сәнәгате хезмәткәре |
| 4.6 | Атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре |
| 4.7 | Атказанган шахтер |
| 4.8 | Атказанган химик |
| 4.9 | Атказанган машина төзүче |
| 4.10 | Атказанган урман сәнәгате хезмәткәре |
| 4.11 | Атказанган азык-төлек индустриясе хезмәткәре |
| 4.12 | Атказанган балык хуҗалыгы хезмәткәре |
| 4.13 | Атказанган балыкчы |
| 4.14 | Атказанган балык белгече |
| 4.15 | Атказанган полиграфист |
| 4.16 | Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 4.17 | Атказанган игенчелек остасы |
| 4.18 | Атказанган агроном |
| 4.19 | Атказанган авыл хуҗалыгы инженеры |
| 4.20 | Атказанган зоотехник |

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 4.21 | Атказанган терлекчелек хезмәткәре |
| 4.22 | Атказанган терлекче |
| 4.23 | Атказанган терлекчелек мастеры |
| 4.24 | Терлекчелек мастеры |
| 4.25 | Атказанган җир төзүче |
| 4.26 | Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 4.27 | Атказанган механизатор |
| 4.28 | Машина белән икмәк җыю остасы |
| 4.29 | Атказанган ирригатор |
| 4.30 | Атказанган мелиоратор |
| 4.31 | Атказанган гидротехник |
| 4.32 | Атказанган ветеринария табибы |
| 4.33 | Атказанган урманчы |
| 4.34 | Атказанган табигать саклау хезмәткәре |
| 4.35 | Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 4.36 | Атказанган автотранспорт хезмәткәре |
| 4.37 | Атказанган элемтәче |
| 4.38 | Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 4.39 | Атказанган төзүче |
| 4.40 | Атказанган сәүдә һәм гомуми туклану хезмәткәре |
| 4.41 | Атказанган сәүдә хезмәткәре |
| 4.42 | Атказанган сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 4.43 | Атказанган халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 4.44 | Атказанган көнкүреш хезмәте хезмәткәре |
| 4.45 | Атказанган коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 4.46 | Атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 4.47 | Атказанган халыкка коммуналь һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 4.48 | Атказанган коммуналь-көнкүреш хезмәте хезмәткәре |
| 4.49 | Халык табибы |
| 4.50 | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 4.51 | Атказанган табиб |
| 4.52 | Атказанган провизор |
| 4.53 | Атказанган фармацевт |
| 4.54 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.55 | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 4.56 | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 4.57 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.58 | Атказанган тренер |
| 4.59 | Атказанган социаль тәэмин итү хезмәткәре |
| 4.60 | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 4.61 | Атказанган укытучы |

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 4.62 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 4.63 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 4.64 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 4.65 | Атказанган укытучы |
| 4.66 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 4.67 | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 4.68 | Атказанган югары мәктәп эшлеклесе |
| 4.69 | Атказанган пропагандачы |
| 4.70 | Халык артисты |
| 4.71 | Атказанган артист |
| 4.72 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.73 | Халык рәссамы |
| 4.74 | Атказанган рәссам |
| 4.75 | Халык язучысы |
| 4.76 | Атказанган язучы |
| 4.77 | Халык шагыйре |
| 4.78 | Халык җырчысы |
| 4.79 | Халык акыны |
| 4.80 | Атказанган журналист |
| 4.81 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.82 | Атказанган мәдәни-агарту эше хезмәткәре |
| 4.83 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.84 | Атказанган архитектор |
| 4.85 | Атказанган китапханәче |
| 4.86 | Атказанган келәмче |
| 4.87 | Кулланма сәнгать мастеры |
| 4.88 | Атказанган халык иҗаты мастеры |
| 4.89 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.90 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 4.91 | Атказанган геолог |
| 4.92 | Атказанган геолог-разведчик |
| 4.93 | Атказанган геология хезмәткәре |
| 4.94 | Атказанган геология хезмәте хезмәткәре |
| 4.95 | Атказанган геодезия һәм картография хезмәткәре |
| 4.96 | Атказанган юрист |
| 4.97 | Атказанган инженер |
| 4.98 | Атказанган уйлап табучы |
| 4.99 | Атказанган рационализатор |
| 4.100 | Атказанган мастер |
| 4.101 | Атказанган икътисадчы |
| 4.102 | Атказанган бухгалтер |

| № т/б | **Мактаулы исемнең атамасы** |
|---|---|
| 4.103 | Атказанган (эшләүче, эшче) яшьләр остазы |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1 | Атказанган сәнәгать хезмәткәре |
| 5.2 | Атказанган химик |
| 5.3 | Атказанган машина төзүче |
| 5.4 | Атказанган целлюлоза-кәгазь һәм агач эшкәртү сәнәгате хезмәткәре |
| 5.5 | Атказанган урман сәнәгате хезмәткәре |
| 5.6 | Атказанган медицина сәнәгате хезмәткәре |
| 5.7 | Атказанган медицина хезмәткәре |
| 5.8 | Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |
| 5.9 | Атказанган агроном |
| 5.10 | Атказанган кыр белгече |
| 5.11 | Атказанган зоотехник |
| 5.12 | Атказанган терлекче |
| 5.13 | Атказанган җир төзүче |
| 5.14 | Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы |
| 5.15 | Атказанган механизатор |
| 5.16 | Машина белән икмәк җыю остасы |
| 5.17 | Атказанган мелиоратор |
| 5.18 | Атказанган ветеринария табибы |
| 5.19 | Атказанган урманчы |
| 5.20 | Атказанган транспорт хезмәткәре |
| 5.21 | Атказанган шофер |
| 5.22 | Атказанган йөртүче |
| 5.23 | Атказанган элемтәче |
| 5.24 | Атказанган элемтә хезмәткәре |
| 5.25 | Атказанган төзүче |
| 5.26 | Атказанган сәүдә һәм гомуми туклану хезмәткәре |
| 5.27 | Атказанган сәүдә хезмәткәре |
| 5.28 | Атказанган халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре |
| 5.29 | Атказанган көнкүреш хезмәте хезмәткәре |
| 5.30 | Атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре |
| 5.31 | Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 5.32 | Атказанган табиб |
| 5.33 | Атказанган провизор |
| 5.34 | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 5.35 | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 5.36 | Атказанган мәктәп эшлеклесе |
| 5.37 | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 5.38 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |

| № т/б | Мактаулы исемнең атамасы |
|---|---|
| 5.39 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 5.40 | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 5.41 | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 5.42 | Халык артисты |
| 5.43 | Атказанган артист |
| 5.44 | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.45 | Халык рәссамы |
| 5.46 | Атказанган рәссам |
| 5.47 | Халык язучысы |
| 5.48 | Атказанган язучы |
| 5.49 | Халык шагыйре |
| 5.50 | Атказанган журналист |
| 5.51 | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 5.52 | Атказанган китапханәче |
| 5.53 | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.54 | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.55 | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5.56 | Атказанган геолог |
| 5.57 | Атказанган юрист |
| 5.58 | Атказанган милиция хезмәткәре |
| 5.59 | Атказанган техник |
| 5.60 | Атказанган инженер |
| 5.61 | Атказанган уйлап табучы |
| 5.62 | Атказанган рационализатор |
| 5.63 | Атказанган икътисадчы |
| 5.64 | Атказанган бухгалтер |
| 5.65 | Атказанган халык хуҗалыгы хезмәткәре |
| 5.66 | Атказанган рационализатор һәм уйлап табучы |